*Хәсән (Хизбулла) Фәхри улы*

**шагыйрь**

*27(10).11(12).1900, Казан губернасының Чистай өязе Иске Кармәт авылы – 10.6.1981, Казан шәһәре*

1914–1916 елларда «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа шәһәре) укый. 1918 елдан Урал һәм Себер мәктәпләрендә укыта. 1924–1928 елларда Казанның 17 нче мәктәбендә эшли, 1930–1934 елларда — Татарстан радиокомитеты редакторы, 1934–1937 елларда — «Совет әдәбияты» журналының җаваплы сәркатибе. 1940 елда кулга алына, 1942 елда үлем җәзасына хөкем ителә, соңрак хөкем карары 10 елга иреген-нән мәхрүм ителү белән алыштырыла, 1950 елда Себергә сөргенгә җибәрелә. Казанга 1956 елда акланганнан соң әйләнеп кайта.

Татар әдәбияты классигы. Поэзиягә беренче булып эшче темасын кертә, татар милләте язмышы фаҗигасе турында сөйли, поэтик телне җыр гадилеге дәрәҗәсенә җиткерә. Дәүләт бүләге 1966 елда «Сайланма әсәрләр» шигырьләр җыентыгы өчен бирелә.

1966



# ФАЙЗИ (ФАЙЗУЛЛИН)
*Джаудат Харисович*

**композитор, фольклорист,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1944 г.),**
**РСФСР (1957 г.),**
**народный артист ТАССР (1964 г.)**

*4(17).1.1910, г. Оренбург – 30.4.1973, г. Казань*

В 1933 г. окончил Казанский юридический институт, в 1938 г. — Татарскую оперную студию при Московской консерватории. В 1939–1941 гг. заведующий музыкальной частью и дирижер Татарского академического театра им. Г. Камала, в 1944–1947 и 1952–1957 гг. директор и художественный руководитель Татарской филармонии им. Г. Тукая.
Внес большой вклад в развитие жанра музыкальной комедии. Его музыкальная комедия «Башмагым» («Башмачки», 1942 г.) остается в репертуаре Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля много лет и ставится на сценах многих театров России. Автор более 200 песен и романсов. Премию получил в 1966 г. за цикл новых песен.

# ФӘЙЗИ (ФӘЙЗУЛЛИН)
*Җәүдәт Харис улы*

**композитор, фольклорчы,**
**ТАССРның (1944), РСФСРның атказанган**
**сәнгать эшлеклесе (1957),**
**ТАССРның халык артисты (1964)**

*4(17).1.1910, Оренбург шәһәре – 30.4.1973, Казан шәһәре*

1933 елда — Казан юридик институтын, 1938 елда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлый. 1939–1941 елларда — Татар академия театрының музыка бүлеге мөдире һәм дирижеры, 1944–1947 һәм 1952–1957 елларда — Г. Тукай исемендәге Татар филармониясе директоры һәм сәнгать җитәкчесе.
Музыкаль комедия жанры үсешенә зур өлеш кертә. Аның «Башмагым» музыкаль комедиясе (1942) М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры репертуарыннан озак еллар төшми һәм Россиянең күпләгән театр сәхнәләрендә куела. 200 дән артык җыр һәм романс авторы. Дәүләт бүләге 1966 елда яңа җырлар циклы өчен бирелә.

1967



# УРМАНЧЕ
*Баки (Габдельбаки) Идрисович*

**живописец, скульптор, график, заслуженный художник РСФСР (1972 г.), народный художник ТАССР (1960 г.), РСФСР (1982 г.)**

*10(22).2.1897, с. Черки-Гришино Тетюшского уезда Казанской губернии – 6.8.1990, г. Казань*

В 1920 г. окончил Казанские свободные художественные мастерские, в 1926 г. — Московские Высшие художественно-технические мастерские. В 1933–1958 гг. жил в Москве, Алма-Ате, Самарканде, Ташкенте. С 1958 г. в Казани. Репрессирован, в 1930–1933 гг. отбывал заключение на Соловецких островах. Реабилитирован в 1990 г. Один из основоположников профессиональной татарской живописи. Среди его работ около 300 произведений станковой живописи, более 100 скульптур, галерея портретов и бюстов деятелей татарской культуры. Отдельной темой творчества художника были произведения Г. Тукая. Премию получил в 1967 г. за серию портретов деятелей культуры Татарии.

# УРМАНЧЕ
*Бакый (Габделбакый) Идрис улы*

**нәкышьче, скульптор, график, РСФСРның атказанган рәссамы (1972), ТАССРның (1960), РСФСРның (1982) халык рәссамы**

*10(22).2.1897, Казан губернасының Тәтеш өязе Күл Черкене авылы – 6.8.1990, Казан шәһәре*

1920 елда — Казан ирекле сәнгать остаханәләрен, 1926 елда Мәскәү Югары сәнгать-техника остаханәләрен тәмамлый. 1933–1958 елларда Мәскәү, Алма-Ата, Сәмәрканд, Ташкент шәһәрләрендә яши. 1958 елдан — Казанда. Репрессияләнә, 1930–1933 елларда Соловки утрауларында сөргендә була. 1990 елда аклана.

Татар профессиональ нәкышь сәнгатенә нигез салучыларның берсе. Аның эшләре арасында 300 гә якын станлы нәкышь әсәре, 100 дән артык скульптура, шулай ук татар мәдәнияте эшлеклеләренең портретлар һәм бюстлар галереясы бар. Рәссам иҗатында Г. Тукай әсәрләре аерым тема тәшкил итә. Дәүләт бүләге 1967 елда Татарстан мәдәният эшлеклеләренең портретлары сериясе өчен бирелә.

1967



# ХОДЖАЕВ (ХУЖАЕВ) *Ташходжа Умарович*

**режиссер, педагог, народный артист Узбекской ССР (1959 г.)**

*1.9.1922, г. Ташкент – 22.5.1975, там же*

В 1941 г. окончил Ташкентскую балетную школу, в 1951 г. — режиссерский факультет Ташкентского театрально-художественного института. С 1950 г. в Узбекском академическом театре драмы им. Хамзы (в 1958–1960 и с 1966 г. — главный режиссер).
Премию получил в 1967 г. за постановку на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала спектакля «Гүзәлем Әсәл» («Тополек мой в красной косынке, 1966 г.) по повести Ч. Айтматова.


# ХОДЖАЕВ (ХУҖАЕВ) *Ташхуҗа Умар (Гомәр) улы*

**режиссер, педагог, Үзбәкстан ССРның халык артисты (1959)**

*01.09.1922, Ташкент шәһәре – 22.05.1975, шунда ук*

1941 елда — Ташкент балет мәктәбен, 1951 елда Ташкент театр-сәнгать институтының режиссерлык факультетын тәмамлый. 1950 елдан — Хәмзә исемендәге Үзбәк академия драма театрында (1958–1960 һәм 1966 –1971 елларда — баш режиссер). Дәүләт бүләге 1967 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театрында Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повестен сәхнәләштергән (1966) өчен бирелә.

1967



# ГЕЛЬМС
## *Эрнст Брунович*

**театральный художник, график,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1956 г.),**
**народный художник ТАССР (1960 г.),**
**заслуженный художник РСФСР (1974 г.)**

*15.8.1912, г. Москва – 2.2.1992, г. Казань*

В 1933–1942 гг. работал художником в Москве и Иркутске. С 1942 г. в Казани: с 1947 г. сотрудничал с Татарским книжным издательством, с 1951 г. — с журналом «Чаян» («Скорпион»), одновременно с 1945 г. художник-постановщик, в 1964–1981 гг. главный художник Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.
Внес большой вклад в развитие газетной, журнальной, станковой графики, искусства плаката в ТАССР. Оформил около 300 спектаклей на сценах театров Казани и других городов страны. Премию получил в 1967 г. за художественное оформление спектакля «Гүзәлем Әсәл» («Тополек мой в красной косынке», 1966 г.), поставленного по повести Ч. Айтматова на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала.

# ГЕЛЬМС
## *Эрнст Брунович*

**театр рәссамы, график,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1956),**
**ТАССРның халык рәссамы (1960),**
**РСФСРның атказанган рәссамы (1974)**

*15.8.1912, Мәскәү шәһәре – 2.2.1992, Казан шәһәре*

1933–1942 елларда Мәскәү һәм Иркутскида рәссам булып эшли. 1942 елдан Казанда: 1947 елдан — Татарстан китап нәшрияты, 1951 елдан «Чаян» журналы белән хезмәттәшлек итә, бер үк вакытта, 1945 елдан, сәхнәгә куючы-рәссам, 1964–1981 елларда — В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрының баш рәссамы.
ТАССРның газета-журнал графикасы һәм станлы графика, плакат сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Казан шәһәре һәм илнең башка шәһәр театрлары сәхнәләрендә 300 якын спектакльне бизәү эшләрен башкара. Дәүләт бүләге 1967 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театрында Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повесте буенча куелган спектакльнең (1966) сәхнә бизәлешен башкарган өчен бирелә.

1967



## ГАРЕЕВА
*Наиля (Нелли) Хакимовна*

драматическая актриса,
народная артистка ТАССР (1976 г.),
заслуженная артистка РФ (2010 г.)

*18.11.1940, г. Казань – 28.11.2023, там же*

В 1961 г. окончила студию при Казанском академическом русском Большом драматическом театре им. В. И. Качалова, работала в Татарском академическом театре им. Г. Камала.
Актриса характерных ролей, дарованию которой присущ нервный, импульсивный, беспокойный драматизм, граничащий с трагизмом. Премию получила в 1967 г. за роль Асель в спектакле «Гүзәлем Әсәл» («Тополек мой в красной косынке», 1966 г.), поставленном по повести Ч. Айтматова на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала.

## ГӘРӘЕВА
*Наилә (Нелли) Хәким кызы*

драма актрисасы,
ТАССРның халык артисты (1976),
РФнең атказанган артисты (2010)

*18.11.1940, Казан шәһәре – 28.11.2023, шунда ук*

1961 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлый, Г. Камал исемендәге Татар академия театрында эшли.
Характерлы рольләр актрисасы, аның талантына трагизм белән чиктәш киеренке, импульсив, тынгысыз драматизм хас.
Дәүләт бүләге 1967 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повесте буенча куелган спектакльдә (1966) Әсәл ролен башкарган өчен бирелә.

1967



# АСФАНДИЯРОВА
*Шахсанем Ибрагимбековна*

**драматическая актриса, педагог, народная артистка ТАССР (1970 г.), заслуженная артистка РСФСР (1977 г.)**

*8.2.1926, г. Термез, Узбекская ССР – 27.10.1996, г. Казань*

В 1940 г. окончила Ташкентское хореографическое, в 1943 г. — Казанское музыкальное училища, в 1949 г. — татарскую студию Государственного института театрального искусства (г. Москва). С 1949 г. в Казанском ТЮЗе, с 1950 г. в Татарском академическом театре им. Г. Камала. Ведущая актриса театра. Среди ее ролей как сентиментальные, так и остросатирические образы.
Премию получила в 1967 г. за роль Хадичи в спектакле «Гүзәлем Әсәл» («Тополек мой в красной косынке», 1966 г.), поставленном по повести Ч. Айтматова на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала, в которой воплотила образ надломленной, но не сдавшейся тонкой женской души.

# ӘСФӘНДИЯРОВА
*Шаһсәнәм Ибраһимбәк кызы*

**драма актрисасы, педагог, ТАССРның халык артисты (1970), РСФСРның атказанган артисты (1977)**

*8.2.1926, Үзбәкстан ССРның Тәрмез шәһәре – 27.10.1996, Казан шәһәре*

1940 елда — Ташкент хореография, 1943 елда Казан музыка училищеларын, 1949 елда Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) (Мәскәү шәһәре) татар студиясен тәмамлый. 1949 елдан — Казан Яшь тамашачылар театрында, 1950 елдан — Г. Камал исемендәге Татар академия театрында. Театрның әйдәп баручы актрисасы. Башкарган рольләре арасында хисси характердагы, шулай ук кискен сатирик образлар да бар.
Дәүләт бүләге 1967 елда Ч. Айтматовның «Кызыл яулыклы гүзәлкәем» повесте буенча Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә Хәдичә роле өчен бирелә. Актриса әлеге образда рухы сындырылган, ләкин бирешмәгән хатын-кызның нечкә күңелен ачып бирә.

1967



# БИКТЕМИРОВ
*Шаукат Хасанович*

драматический актер,
народный артист ТАССР (1968 г.),
РСФСР (1970 г.), СССР (1977 г.)

*28.10.1928, г. Казань – 28.5.2012, там же*

После окончания Татарского театрального техникума в 1949 г. работал в Татарском академическом театре им. Г. Камала.
Признанный мастер современной сцены татарского театра. Наиболее запоминающейся из его ролей стал образ Альмандара в спектакле по пьесе Т. Миннуллина «Әлдермештән Әлмәндәр» («Альмандар из Альдермеша», 1976 г.). Актер воплотил в нем подлинно народный тип, которому свойственны душевное здоровье, гордость, патриотизм, любовь к шутке и юмору. Премию получил в 1967 г. за роль Байтимера в спектакле «Гүзәлем Әсәл» («Тополек мой в красной косынке», 1966 г.), поставленном по повести Ч. Айтматова на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала.

# БИКТИМЕРОВ
*Шәүкәт Хәсән улы*

драма актеры,
ТАССРның (1968), РСФСРның (1970),
СССРның (1977) халык артисты

*28.10.1928, Казан шәһәре – 28.05.2012, шунда ук*

1949 елда Татар театр техникумын тәмамлаганнан соң, Г. Камал исемендәге Татар академия театрында эшли.
Татар театрының күренекле сәхнә остасы. Аның рольләре арасында онытылмас вакыйга буларак кабул ителгәне — Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976) спектаклендәге Әлмәндәр образы. Актер бу образда асылына рухи сәламәтлек, горурлык, патриотизм хас булган, уен-көлке һәм юмор яратучан чын халыкчан типны гәүдәләндерә. Дәүләт бүләге 1967 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повесте буенча куелган спектакльдә (1966) Байтимер ролен башкарган өчен бирелә.

1967



## ТАЗЕТДИНОВ
*Ринат Арифзянович*

**драматический актер,**
**народный артист ТАССР (1973 г.), РСФСР (1982 г.)**

*1.1.1938, с. Малая Цильна Дрожжановского района ТАССР – 16.10.2024, г. Казань*

После окончания в 1961 г. Высшего театрального училища им. М. С Щепкина (г. Москва) работал в Татарском академическом театре им. Г. Камала.
Ведущий актер театра. Его умным, многогранным драматическим, комедийным положительным и отрицательным героям присущи романтическая взволнованность, горячий темперамент при глубокой жизненной правде, внешней сдержанности. Премию получил в 1967 г. за роль Ильяса в спектакле «Гүзәлем Әсәл» («Тополек мой в красной косынке», 1966 г.) по повести Ч. Айтматова на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала, которая была одной из первых ролей актера в театре.

## ТАҖЕТДИНОВ
*Ринат Арифҗан улы*

**драма актеры,**
**ТАССРның (1973), РСФСРның (1982) халык артисты**

*1.1.1938, ТАССРның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылы – 16.10.2024, Казан шәһәре*

1961 елда Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлаганнан соң, Г. Камал исемендәге Татар академия театрында эшли.
Театрның әйдәп баручы актеры була. Аның күпкырлы драматик, комик характердагы уңай һәм тискәре геройларына тирән тормыш чынлыгы, тышкы сабырлык белән бергә романтик күтәренкелек, кайнар темперамент хас. Дәүләт бүләге 1967 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повесте буенча куелган спектакльдә (1966) актерның беренче рольләреннән булган Ильяс ролен башкарган өчен бирелә.

1968



## ЗАКИРОВ
*Наки Сиразетдинович (псевдоним — Наки Исанбет)*

**писатель, поэт, драматург,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1957 г.), РСФСР (1959 г.), народный писатель ТАССР (1986 г.)**

*29(10).12(1).1899(1900), д. Малояз Златоустовского уезда Уфимской губернии – 15.9.1992, г. Казань*

В 1920–1922 гг. одновременно учился в Уфимском институте народного просвещения и Харьковском университете, затем преподавал на родине и в Уфимском театральном училище. С 1929 г. в Казани, преподавал в Татарском театральном техникуме, в Казанском химико-технологическом институте, на рабфаке.
Драматург, произведения которого входили в репертуар Татарского академического театра им. Г. Камала, ученый-фольклорист, собравший несколько объемных сборников татарских сказок, пословиц, мифов и пр. Премию получил в 1968 г. за исследовательский труд «Татар халык мәкальләре» («Татарские народные пословицы», т. 1–3, 1959–1967).


## ЗАКИРОВ
*Нәкый Сиражетдин улы (псевдонимы — Нәкый Исәнбәт)*

**язучы, шагыйрь, драматург,
ТАССРның (1957), РСФСРның (1959) атказанган сәнгать эшлеклесе,
ТАССРның халык язучысы (1986)**

*29(10).12(1).1899(1900), Уфа губернасының Златоуст өязе Малаяз авылы – 15.9.1992, Казан шәһәре*

1920–1922 елларда бер үк вакытта Уфа халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетында укый, аннары туган ягында һәм Уфа театр училищесында укыта. 1929 елдан Казанда: Татар театр техникумында, Казан химия-технология институтында, рабфакта белем бирә.
Әсәрләре Г. Камал исемендәге Татар академия театры репертуарында урын алган драматург, татар әкиятләре, мәкальләр, мифлар һәм башкалардан гыйбарәт берничә том җыентык туплаган фольклорчы галим. Дәүләт бүләге 1968 елда «Татар халык мәкальләре» хезмәте (1–3 т., 1959–1967) өчен бирелә.

1968



# ХАБИБУЛЛИН
*Загид Валеевич*

**композитор, скрипач,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1950 г.),
РСФСР (1981 г.), народный артист ТАССР (1970 г.)**

*20(3).9(10).1910, г. Орск – 20.11.1983, г. Казань*

В 1936–1940 гг. учился в Татарской оперной студии при Московской консерватории, работал в инструментальном ансамбле Татарской филармонии.
Своим творчеством композитор способствовал развитию татарской скрипичной музыки, был первым среди татарских композиторов автором цикла песен на стихи Г. Тукая.
Премию получил в 1968 г. за цикл песен: «Казакъ кызы сөйгәнем» («Моя любимая казашка»), «Солдат җыры» («Песня солдата»), «Гөлләрем» («Цветы мои»), «Безнең кардәшлек» («Наши братья»), «Мактанчык егет» («Парень-хвастун»), «Бормалы су» («Извилистый ручеек»).


# ХӘБИБУЛЛИН
*Заһид Вәли улы*

**композитор, скрипкачы,
ТАССРның (1950), РСФСРның (1981) атказанган сәнгать эшлеклесе,
ТАССРның халык артисты (1970)**

*20(3).9(10).1910, Орск шәһәре – 20.11.1983, Казан шәһәре*

1936–1940 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый, Татар филармониясенең инструменталь ансамблендә эшли.
Композитор үзенең иҗаты белән татар скрипка музыкасы үсешенә булышлык итә, татар композиторлары арасында Г. Тукай шигырьләре буенча җырлар циклы язучы беренче автор була.
Дәүләт бүләге 1968 елда «Казакъ кызы сөйгәнем», «Солдат җыры», «Гөлләрем», «Безнең кардәшлек», «Мактанчык егет», «Бормалы су» җырлар циклы өчен бирелә.

1969



# АРСЛАНОВ
## *Айрат Гареевич*

**драматический актер, режиссер эстрады, народный артист ТАССР (1979 г.), РСФСР (1987 г.)**

*10.4.1928, с. Ахуново Буздякского района Башкирской АССР – 23.4.2010, г. Казань*

В 1949 г. окончил Татарский театральный техникум, в 1967 г. — Государственный институт театрального искусства в Москве. С 1948 г. диктор на Татарском радио, в 1956–1961 гг. актер Татарского академического театра им. Г. Камала, в 1961–1965 гг. диктор и актер на Казанской студии телевидения, с 1965 г. артист и с 1985 г. режиссер эстрады Татарской филармонии им. Г. Тукая.
Лауреат всесоюзных конкурсов чтецов. Произведения татарских писателей в исполнении Айрата Арсланова записаны Всесоюзной фирмой грамзаписи «Мелодия». Премию получил в 1969 г. за концертные программы «Күңелем Ленин белән сөйләшә» («С Лениным сердце мое говорит») и «Туган җирем — Татарстан» («Татарстан — мой край родной»).

# АРСЛАНОВ
## *Айрат Гәрәй улы*

**драма актеры, эстрада режиссеры, ТАССРның (1979), РСФСРның (1987) халык артисты**

*10.4.1928, Башкортстан АССРның Бүздәк районы Ахун авылы – 23.4.2010, Казан шәһәре*

1949 елда — Татар театр техникумын, 1967 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институтын (ГИТИС) тәмамлый. 1948 елдан — Татарстан радиосында диктор, 1956–1961 елларда — Г. Камал исемендәге Татар академия театры актеры, 1961–1965 елларда — Казан телевидение студиясендә диктор һәм актер, 1965 елдан — Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты, 1985 елдан — эстрада режиссеры.
Бөтенсоюз нәфис сүз конкурслары лауреаты. Татар язучыларының Айрат Арсланов башкаруындагы әсәрләре «Мелодия» Бөтенсоюз фирмасында граммофон тасмасына язылган. Дәүләт бүләге 1969 елда «Күңелем Ленин белән сөйләшә» һәм «Туган җирем — Татарстан» концерт программалары өчен бирелә.

1969



# МИНГАЗЕЕВ
*Ибрагим Зарифуллович (псевдоним — Ибрагим Гази)*

**писатель, журналист**

*22(4).1(2).1907, д. Старые Кармалы Тетюшского уезда Казанской губернии – 21.2.1971, г. Казань*

В 1924–1926 гг. слушатель Татарской областной партийной школы. До 1931 г. на комсомольской работе, одновременно редактор газеты «Кызыл яшьләр» («Красная молодежь») и журнала «Колхоз яшьләре» («Колхозная молодежь»). В 1933–1938 гг. ответственный редактор сектора художественной литературы Татгосиздата. Участник Великой Отечественной войны, фронтовой корреспондент. Работал в журналах «Азат хатын» («Свободная женщина») и «Казан утлары» («Огни Казани»).
Премию получил в 1969 г. за автобиографический роман-трилогию «Онытылмас еллар» («Незабываемые годы»), над которым автор работал в 1949–1966 гг.

# МИНГАЗИЕВ
*Ибраһим Зарифулла улы (псевдонимы — Ибраһим Гази)*

**язучы, журналист**

*22(4).1(2).1907, Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Карамалы авылы – 21.2.1971, Казан шәһәре*

1924–1926 елларда Татар өлкә партия мәктәбе тыңлаучысы. 1931 елга кадәр комсомол эшендә, бер үк вакытта «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Колхоз яшьләре» журналы мөхәррире. 1933–1938 елларда Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторы җаваплы мөхәррире. Бөек Ватан сугышында катнаша, фронт газетасы хәбәрчесе. «Азат хатын» һәм «Казан утлары» журналларында эшли.
Дәүләт бүләге 1969 елда «Онытылмас еллар» автобиографик роман-трилогиясе (1949–1966) өчен бирелә.

1970



# КЛЮЧАРЁВ
*Александр Сергеевич*

**композитор, музыкально-общественный деятель, фольклорист, заслуженный деятель искусств ТАССР (1939 г.), народный артист ТАССР (1964 г.), заслуженный деятель искусств РСФСР (1969 г.)**

*19.2.1906, г. Казань – 30.3.1972, там же*

В 1932 г. окончил Московскую консерваторию. Работал в Москве, Йошкар-Оле, Уфе. С 1937 г. в Казани: главный редактор музыкального вещания Татарского радиокомитета, в 1938–1951 гг. заведующий кабинетом музыкального фольклора Управления по делам искусств при Совете Министров ТАССР, одновременно художественный руководитель Государственного ансамбля песни и танца ТАССР (1939–1940, 1968–1970 гг.) и Татарской филармонии им. Г. Тукая (1940–1942, 1951–1953 гг.).
Его творчество охватывает широкий круг жанров и форм от обработок народных песен до балетов и симфоний. Премию получил в 1970 г. за сборник песен «Канатлы яшьлек» («Крылатая молодость», 1968 г.) и плодотворную деятельность по собиранию и пропаганде татарского народного музыкального творчества.

# КЛЮЧАРЁВ
*Александр Сергеевич*

**композитор, музыка-җәмәгать эшлеклесе, фольклорчы, ТАССРның халык артисты (1964), ТАССРның (1939), РСФСРның (1969) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*19.2.1906, Казан шәһәре – 30.3.1972, шунда ук*

1932 елда Мәскәү консерваториясен тәмамлый. Мәскәү, Йошкар-Ола, Уфа шәһәрләрендә эшли. 1937 елдан Казанда: Татарстан радиокомитетының музыкаль тапшырулар баш мөхәррире, 1938–1951 елларда — ТАССР Министрлар Советы каршындагы Сәнгать эшләре идарәсенең музыкаль фольклор кабинеты мөдире, бер үк вакытта ТАССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең (1939–1940, 1968–1970) һәм Г. Тукай исемендәге Татар филармониясенең (1940–1942, 1951–1953) сәнгать җитәкчесе.
Иҗаты халык җырларын эшкәртүдән башлап балет һәм симфонияләргә кадәр булган киң жанр һәм формаларны колачлый. Дәүләт бүләге 1970 елда «Канатлы яшьлек» җырлар җыентыгы (1968), татар халык музыкаль иҗатын туплау һәм пропагандалаудагы нәтиҗәле эшчәнлеге өчен бирелә.

1970



# ШАКИРОВ
*Ильгам Гильмутдинович*

**певец (баритон), заслуженный артист ТАССР (1964 г.), РСФСР (1974 г.), народный артист ТАССР (1969 г.), Каракалпакской АССР (1981 г.), РСФСР (1983 г.)**

*15.2.1935, д. Яна-Буляк Тукаевского района ТАССР – 16.1.2019, г. Казань*

В 1960 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1960–1992 гг. ведущий солист, в 1992–2010 гг. художественный руководитель Татарской филармонии им. Г. Тукая.
Обладал голосом особой красоты, мелодичности, мягкого тембра, широкого диапазона. Непревзойденный мастер исполнения татарских народных напевов и камерно-вокальной музыки композиторов Татарстана. Премию получил в 1970 г. за концертные программы 1968–1969 гг. «Татар халык җырлары» («Татарские народные песни»), «Җырларым сиңа, Октябрь» («Песни мои тебе, Октябрь») и пропаганду татарских народных песен и творчества татарских композиторов.

---

# ШАКИРОВ
*Илһам Гыйльметдин улы*

**җырчы (баритон), ТАССРның (1964), РСФСРның (1974) атказанган артисты, ТАССРның (1969), Каракалпак АССРның (1981), РСФСРның (1983) халык артисты**

*15.2.1935, ТАССРның Тукай районы Яңа Бүләк авылы – 16.1.2019, Казан шәһәре*

1960 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1960–1992 елларда — Г. Тукай исемендәге Татар филармониясенең әйдәп баручы солисты, 1992–2010 елларда — сәнгать җитәкчесе.
Аһәңле, йомшак тембрлы, киң диапазонлы үзенчәлекле матур тавышка ия була. Татар халык көйләрен һәм Татарстан композиторларының камера-вокаль музыкасын башкаруның кабатланмас остасы. Дәүләт бүләге 1970 елда «Татар халык җырлары», «Җырларым сиңа, Октябрь» концерт программалары (1968–1969 елларда башкара) һәм татар халык җырларын, татар композиторлары иҗатын пропагандалаган өчен бирелә.

1971



# КУЗНЕЦОВ
## *Николай Дмитриевич*

**живописец,
заслуженный деятель искусств ТАССР
и РСФСР (1957 г.)**

*23.5.1923, пос. Васильево Зеленодольского района ТАССР – 15.12.1974, г. Казань*

В 1945 г. окончил Казанское художественное училище. С 1946 г. — в объединении «Татхудожник».
Художник воплощал на своих полотнах образ родного края: красоту природы, волжские просторы с портами и причалами, городские новостройки, стройки нефтехимии. Его произведениям присущ эпический и героико-романтический характер. Премию получил в 1971 г. за цикл современных индустриальных пейзажей.

# КУЗНЕЦОВ
## *Николай Дмитриевич*

**нәкышьче,
ТАССРның (1957), РСФСРның (1957) атказанган
сәнгать эшлеклесе**

*23.5.1923, ТАССРның Зеленодольск районы Васильево поселогы – 15.12.1974, Казан шәһәре*

1945 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. 1946 елдан — «Татхудожник» берләшмәсендә.
Рәссам үзенең картиналарында туган як образын — табигать матурлыгын, портлары һәм причаллары белән Идел киңлекләрен, шәһәрдәге яңа төзелешләрне, нефть химиясе төзелешләрен тасвирлый. Әсәрләренә эпик һәм героик-романтик характер хас. Дәүләт бүләге 1971 елда заманча индустриаль пейзажлар циклы өчен бирелә.

1971



# САЛИМЖАНОВ
## *Марсель Хакимович*

**драматический актер, режиссер,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1969 г.),
РСФСР (1975 г.), народный артист РСФСР (1980 г.),
СССР (1984 г.)**

*7.11.1934, г. Казань – 26.3.2002, там же*

В 1957 г. окончил юридический факультет Казанского университета, в 1962 г. — режиссерский факультет Государственного института театрального искусства в Москве. С 1962 г. режиссер-постановщик, с 1964 г. художественный руководитель Казанского ТЮЗа. С 1966 г. главный режиссер Татарского академического театра им. Г. Камала. Поставил на его сцене более 70 спектаклей.
Создал прочную репертуарную базу татарского театра, основанную на современной драматургии. Премию получил в 1971 г. за спектакли «Американ» («Американец»), «Сүнгән йолдызлар» («Угасшие звезды») по пьесам К. Тинчурина, «Тирән тамырлар» («Глубокие корни») по роману Г. Ибрагимова.

---

# СӘЛИМҖАНОВ
## *Марсель Хәким улы*

**драма актеры, режиссер,
ТАССРның (1969), РСФСРның (1975) атказанган
сәнгать эшлеклесе, РСФСРның (1980),
СССРның (1984) халык артисты**

*7.11.1934, Казан шәһәре – 26.3.2002, шунда ук*

1957 елда — Казан университетының юридик факультетын, 1962 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлык факультетын тәмамлый. 1962 елдан — Казан Яшь тамашачылар театрында сәхнәгә куючы-режиссер, 1964 елдан — сәнгать җитәкчесе. 1966 елдан — Г. Камал исемендәге Татар академия театры баш режиссеры. Әлеге театр сәхнәсендә 70 тән артык спектакль куя.
Татар театрының заманча драматургиягә нигезләнгән ныклы репертуар базасын булдыра. Дәүләт бүләге 1971 елда К. Тинчуринның «Американ» һәм «Сүнгән йолдызлар» пьесалары, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәре буенча куелган спектакльләр өчен бирелә.

1972



## ИДИЯТУЛЛИН
*Шаукат Галиевич (псевдоним — Шаукат Галиев)*

**поэт,
народный поэт РТ (1995 г.)**

*20.11.1928, д. Бакрче Апастовского района ТАССР – 7.5.2011, г. Казань*

Окончил Высшие литературные курсы при Литературном институте (г. Москва, 1961 г.). В 1949–1953 гг. редактор Кайбицкой районной газеты «Колхоз бригадасы» («Колхозная бригада»), в 1953–1959 гг. сотрудник журнала «Чаян» («Скорпион»), в 1971–1984 гг. заведующий редакцией художественной литературы Татарского книжного издательства.
В стихах поэта представлены деревенский быт, народные обычаи, жизнь послевоенной молодежи. Стихи о природе и любви легли в основу песен татарских композиторов. Премию получил в 1972 г. за сборники стихов «Әти белән кабинада» («С папой в кабине»), «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр» («Удивительные и забавные происшествия»), «Котбетдин мәргән» («Кутбутдин — меткий стрелок»), «Шәвәли» («Шавали»), «Тәмле йорт» («Сладкий домик»), «Кызык» («Забава»).


## ҺИДИЯТУЛЛИН
*Шәүкәт Гали улы (псевдонимы — Шәүкәт Галиев)*

**шагыйрь,
ТРның халык шагыйре (1995)**

*20.11.1928, ТАССРның Апас районы Бакырчы авылы – 7.5.2011, Казан шәһәре*

Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү шәһәре, 1961). 1949–1953 елларда — Кайбыч районының «Колхоз бригадасы» газетасы мөхәррире, 1953–1959 елларда — «Чаян» журналы хезмәткәре, 1971–1984 елларда — Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире.
Шигырьләрендә авыл тормышы, халык йолалары, яшьләрнең сугыштан соңгы яшәеше сурәтләнә. Табигать һәм мәхәббәт турындагы шигырьләре татар композиторлары тарафыннан көйгә салына. Дәүләт бүләге 1972 елда «Әти белән кабинада», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Котбетдин мәргән», «Шәвәли», «Тәмле йорт», «Кызык» шигъри җыентыклары өчен бирелә.

1972



## ХУСНУТДИНОВ
*Фатих Хуснутдинович (псевдоним — Фатих Хусни)*

**писатель,**
**народный писатель РТ (1993 г.)**

*21(3).1(2).1908, д. Большие Метески Лаишевского уезда Казанской губернии – 19.5.1996, г. Казань*

Окончил Казанский финансово-экономический институт (1933 г.). С 1935 г. работал в редакциях газеты «Кызыл Татарстан» («Красный Татарстан»), журналах «Совет әдәбияты» («Советская литература»), «Чаян» («Скорпион»). Участник Великой Отечественной войны, военный корреспондент. В 1955–1957 гг. ответственный секретарь правления Союза писателей ТАССР.
Отличительная черта творчества писателя — тонкий психологизм. Он раскрывает внутренний мир героя, показывает его судьбу в контексте общенародной жизни. Психологический портрет персонажей обогащается за счет неповторимого своеобразия их речи. Премию получил в 1972 г. за книгу «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» («Гильмуниса и ее соседи», 1971).

## ХӨСНЕТДИНОВ
*Фатих Хөснетдин улы (псевдонимы — Фатих Хөсни)*

**язучы,**
**ТРның халык язучысы (1993)**

*21(3).1(2).1908, Казан губернасының Лаеш өязе Олы Мәтәскә авылы – 19.5.1996, Казан шәһәре*

Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый (1933). 1935 елдан «Кызыл Татарстан» газетасы, «Совет әдәбияты», «Чаян» журналлары редакцияләрендә эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша, хәрби хәбәрче була. 1955–1957 елларда — ТАССР Язучылар берлеге идарәсе җаваплы сәркатибе.
Язучы иҗатының аерым үзенчәлеге — нечкә психологизм. Ул геройның эчке дөньясын ача, аның язмышын гомумхалык тормышы контекстында күрсәтә. Персонажларының психологик портретын аларның кабатланмас сөйләм үзенчәлеге хисабына баета. Дәүләт бүләге 1972 елда «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» китабы (1971) өчен бирелә.

1973



# АХУНОВ
*Гарифзян Ахунзянович*

**писатель, общественный деятель,
заслуженный деятель искусств РСФСР (1985 г.),
народный писатель РТ (1993 г.)**

*18.9.1925, д. Учили Арского кантона ТАССР – 4.6.2000, г. Казань*

В 1952 г. окончил Казанский университет. В 1951–1956 гг. работал в журнале «Совет әдәбияты» («Советская литература»). В 1963–1965 и 1967–1968 гг. ответственный секретарь Альметьевского отделения Союза писателей ТАССР, в 1971–1974 гг. главный редактор журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), в 1974–1984 гг. председатель правления Союза писателей ТАССР.
Герои произведений писателя — нефтяники, труженики села, руководители производства, представители творческой интеллигенции. В 1973 г. был удостоен премии за повесть «Чикләвек төше» («Ядро ореха», 1973) и роман о нефтяниках «Хәзинә» («Клад», 1963), по сюжету которого в 1977 г. был снят одноименный художественный фильм.

---

# АХУНОВ
*Гарифҗан Ахунҗан улы*

**язучы, җәмәгать эшлеклесе,
РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985),
ТРның халык язучысы (1993)**

*18.9.1925, ТАССРның Арча кантоны Өчиле авылы – 4.6.2000, Казан шәһәре*

1952 елда Казан университетын тәмамлый. 1951–1956 елларда «Совет әдәбияты» журналында эшли. 1963–1965 һәм 1967–1968 елларда — ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркатибе, 1971–1974 елларда — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, 1974–1984 елларда — ТАССР Язучылар берлегенең идарә рәисе.
Әсәрләренең геройлары — нефтьчеләр, авыл хезмәтчәннәре, төрле оешмаларның җитәкчеләре, иҗат интеллигенциясе вәкилләре. Дәүләт бүләге 1973 елда «Чикләвек төше» повесте (1973) һәм нефтьчеләр турындагы «Хәзинә» романы (1963; 1977 елда роман сюжеты буенча шул ук исемдәге нәфис фильм төшерелә) өчен бирелә.

1973



# БАКИРОВ
*Энвер Закирович*

**композитор,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1969 г.), РСФСР (1981 г.), народный артист РТ (1993 г.)**

*7.7.1920, г. Казань – 17.8.2001, там же*

В 1940 г. окончил Казанское музыкальное училище, в 1952 г. — Казанскую консерваторию. В 1951–1956 гг. преподавал в Казанском музыкальном училище, в 1956–1957 гг. заведовал литературной частью Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля, в 1957–1970 гг. работал в детских музыкальных школах Казани, Елабуги.
Творчество композитора характеризуется широким жанровым диапазоном, который включает симфонические и камерно-инструментальные произведения. Премию получил в 1973 г. за музыку балета «Су анасы» («Водяная», 1971 г.) по мотивам одноименной сказки Г. Тукая, поставленного на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# БАКИРОВ
*Әнвәр Закир улы*

**композитор,
ТАССРның (1969), РСФСРның (1981) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык артисты (1993)**

*7.7.1920, Казан шәһәре – 17.8.2001, шунда ук*

1940 елда — Казан музыка училищесын, 1952 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1951–1956 елларда Казан музыка училищесында укыта, 1956–1957 елларда — М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының әдәбият бүлеге мөдире, 1957–1970 елларда Казан һәм Алабуга шәһәрләрендәге балалар музыка мәктәпләрендә эшли.
Композитор иҗаты симфоник һәм камера-инструменталь әсәрләрне дә үз эченә алган киң жанр диапазоны белән аерылып тора. Дәүләт бүләге 1973 елда Г. Тукай әкиятенә нигезләнгән һәм М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Су анасы» балеты (1971) музыкасы өчен бирелә.

1973



# СМИРНОВ
## *Игорь Валентинович*

**балетмейстер, педагог,
заслуженный деятель искусств РСФСР (1959 г.),
народный артист РСФСР (1978 г.)**

*8.12.1926, г. Саратов – 1.12.1989, г. Москва*

В 1944 г. окончил Московское хореографическое училище, в 1951 г. — Государственный институт театрального искусства (г. Москва). В 1944–1949 гг. балетмейстер Татарской оперной студии при Московской консерватории. Работал педагогом и балетмейстером в театрах оперы и балета в Румынии, Японии, а также в Петрозаводске и Москве. С 1967 г. заведующий кафедрой хореографии Московского института культуры.
Балетные постановки мастера отличаются сюжетно развитой драматургией, ясностью пластического языка, музыкальностью. Премию получил в 1973 г. за либретто и постановку балета «Су анасы» («Водяная», 1971 г.) на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# СМИРНОВ
## *Игорь Валентинович*

**балетмейстер, педагог,
РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1959),
РСФСРның халык артисты (1978)**

*8.12.1926, Саратов шәһәре – 1.12.1989, Мәскәү шәһәре*

1944 елда — Мәскәү хореография училищесын, 1951 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институтын (ГИТИС) тәмамлый. 1944–1949 елларда — Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе балетмейстеры. Румыния, Япония, шулай ук Петрозаводск һәм Мәскәү опера һәм балет театрларында педагог һәм балетмейстер булып эшли. 1967 елдан — Мәскәү мәдәният институтының хореография кафедрасы мөдире.
Оста тарафыннан куелган балет спектакльләре сюжетының үстерешле драматургиясе, пластикасының ачыклыгы һәм төгәллеге, музыкальлеге белән аерылып тора. Дәүләт бүләге 1973 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә «Су анасы» балетын (1971) куйган һәм либреттосын язган өчен бирелә.

1973



# КНОБЛОК
## *Борис Георгиевич*

**театральный художник,**
**заслуженный деятель искусств РСФСР (1955 г.),**
**лауреат Государственной премии СССР (1948 г.)**

*6(19).4.1903, г. Москва – 4.2.1984, там же*

В 1919 г. поступил в Высшие художественно-технические мастерские (ВХУТЕМАС), где учился у К. А. Коровина, затем завершил образование в художественной студии В. Н. Яковлева (1926 г.). Работал в ведущих театрах Москвы и Новосибирска, был главным художником VI Всемирного фестиваля молодежи и студентов (г. Москва).
В Татарском театре оперы и балета им. М. Джалиля оформил (совместно с сыном А. Б. Кноблоком) балеты «Су анасы» («Водяная», 1971 г.) и «Две легенды» (1971 г.), широко применив орнаментальные мотивы татарского народного искусства. Премию получил в 1973 г. за оформление балета «Су анасы».

# КНОБЛОК
## *Борис Георгиевич*

**театр рәссамы,**
**РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1955),**
**СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1948)**

*6(19).4.1903, Мәскәү шәһәре – 4.2.1984, шунда ук*

Югары сәнгать-техника остаханәсендә (ВХУТЕМАС), К. А. Коровин остаханәсендә укый (1919), белем алуын В. Н. Яковлевның сынлы сәнгать студиясендә укып тәмамлый (Югары сәнгать-техника институты (ВХУТЕИН), 1926). Мәскәү һәм Новосибирскиның әйдәп баручы театрларында эшли, VI Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестиваленең (Мәскәү шәһәре) баш рәссамы була.
М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрында «Су анасы» (1971) һәм «Ике риваять» (1971) балетларын (улы А. Б. Кноблок белән берлектә) бизи, татар халык сәнгатенең орнамент мотивларын киң куллана. Дәүләт бүләге 1973 елда «Су анасы» балетының сәхнә бизәлеше өчен бирелә.

1973



# ФАЗЛУЛЛИН
*Хасби Валиуллович*

**дирижер, кларнетист,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1950 г.), РСФСР (1960 г.), народный артист ТАССР (1989 г.)**

*3(16).12.1909, г. Казань – 26.6.1995, там же*

В 1924–1928 гг. учился в Казанском Восточном музыкальном техникуме. В 1936 г. окончил оркестровый факультет Московской консерватории по классу кларнета, в 1941 г. — дирижерский факультет. В 1941–1946 гг. дирижер Башкирского театра оперы и балета, в 1946–1973 гг. — Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля. В 1946–1970 гг. преподавал в Казанской консерватории, в 1970–1990 гг. — в Казанском институте культуры.
Один из первых татарских профессиональных дирижеров. Его репертуар в Татарском театре оперы и балета им. М. Джалиля насчитывает более 60 оперных и балетных спектаклей, музыкальных комедий и оперетт. В 1946–1982 гг. бессменный дирижер балета «Шурале». В 1973 г. удостоен премии за музыкальное руководство постановкой балета «Су анасы» («Водяная», 1971 г.) на сцене Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# ФАЗЛУЛЛИН
*Хәсби Вәлиулла улы*

**дирижер, кларнетчы,
ТАССРның (1950), РСФСРның (1960) атказанган сәнгать эшлеклесе,
ТАССРның халык артисты (1989)**

*3(16).12.1909, Казан шәһәре – 26.6.1995, шунда ук*

1941 елда Мәскәү консерваториясен тәмамлый. 1941–1946 елларда — Башкорт опера һәм балет театры, 1946–1973 елларда — М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры дирижеры. 1946–1970 елларда — Казан консерваториясендә, 1970–1990 елларда Казан мәдәният институтында укыта.
Беренче татар профессиональ дирижерларыннан. М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрында аның репертуары 60 тан артык опера һәм балет спектаклен, музыкаль комедия һәм опереттаны үз эченә ала. 1946–1982 елларда — «Шүрәле» балетының даими дирижеры. Дәүләт бүләге 1973 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Су анасы» балетының (1971) дирижеры буларак бирелә.

1973



# САДЫКОВ
## *Ревдар Фаизович*

**артист балета, педагог,**
**народный артист ТАССР (1964 г.),**
**заслуженный артист РСФСР (1970 г.)**

*20.1.1937, с. Мишкино Мишкинского района Башкирской АССР – 21.11.1989, г. Казань*

В 1955 г. окончил Ташкентское хореографическое училище. В 1955–1956 гг. артист балета Узбекского, затем Саратовского театров оперы и балета. В 1956–1977 гг. солист балета, в 1977–1980 гг. педагог-репетитор Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля. Виртуозный танцовщик, свободно владевший всем сложнейшим арсеналом балетной техники. Высоко поднял технику мужского танца в татарском балете, заложил основы преемственности исполнения ряда танцевальных образов. Премию получил в 1973 г. за роль Алмая в балете «Су анасы» («Водяная», 1971 г.), поставленном на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# САДЫЙКОВ
## *Ревдар Фәез улы*

**балет артисты, педагог,**
**ТАССРның халык артисты (1964),**
**РСФСРның атказанган артисты (1970)**

*20.1.1937, Башкортстан АССРның Мишкә районы Мишкә авылы – 21.11.1989, Казан шәһәре*

1955 елда Ташкент хореография училищесын тәмамлый. 1955–1956 елларда — Үзбәк, соңрак Саратов опера һәм балет театрларында балет артисты. 1956–1977 елларда — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының балет солисты, 1977–1980 елларда — педагог-репетиторы.
Виртуоз биюче, балет техникасының иң катлаулы арсеналын иркен үзләштергән шәхес. Татар балетында ирләр бию техникасын югарылыкка күтәрә, күп кенә биюле образларны башкаруның нигезен сала. Дәүләт бүләге 1973 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Су анасы» балетында (1971) Алмай роле өчен бирелә.

1974



# АМИРОВ
*Мирсаяф Масалимович (псевдоним — Мирсай Амир)*

**прозаик, драматург,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1945 г.)**

*24(6).12(1).1906(1907), с. Зирган Стерлитамакского уезда Уфимской губернии – 1.6.1980, г. Казань*

В 1939–1941 гг. учился в Литературном институте им. М. Горького (г. Москва). В 1928–1937 гг. работал в редакциях татарских газет и журналов, Татарском книжном издательстве. В 1937–1939 гг. подвергся необоснованным репрессиям. В 1941–1944 гг. редактор литературных передач Татарского рескома по радиофикации и радиовещанию при СНК ТАССР. Участник Великой Отечественной войны, военный корреспондент (1943 г.).

Очерки и рассказы, повести и романы писателя посвящены современникам, Великой Отечественной войне. Его пьесы ставились на сценах Татарского и Башкирского академических театров. Премию получил в 1974 г. за пьесу (по одноименной повести) «Агидель», по которой был поставлен спектакль в Татарском академическом театре им. Г. Камала.

# ӘМИРОВ
*Мирсәяф Мәсәлим улы (псевдонимы — Мирсәй Әмир)*

**прозаик, драматург,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1945)**

*24(6).12(1).1906(1907), Уфа губернасының Стәрлетамак өязе Җиргән авылы – 1.6.1980, Казан шәһәре*

1941 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институтын (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. 1928–1937 елларда татар газета-журналлары редакцияләрендә, Татарстан китап нәшриятында эшли. 1937–1939 елларда нахакка гаепләнә. 1941–1944 елларда — ТАССР ХКС каршындагы Татарстан радиофикация һәм радиотапшырулар комитетының әдәби тапшырулар редакциясе мөхәррире. Бөек Ватан сугышында катнаша, хәрби хәбәрсе (1943).

Язучының очерк һәм хикәя, повесть һәм романнары замандашларына, Бөек Ватан сугышы чорына багышлана. Пьесалары Татар һәм Башкорт академия театрлары сәхнәләрендә куела. Дәүләт бүләге 1974 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театрында сәхнәләштерелгән «Агыйдел» пьесасы (шул исемдәге повесть буенча) өчен бирелә.

# 1974



# ЮЗЕЕВ
## *Нил Гафурович*

**литературовед, литературный критик, доктор филологических наук (1974 г.), заслуженный деятель науки ТАССР (1981 г.)**

*10.1.1931, д. Ямады Янаульского района Башкирской АССР – 11.9.1996, г. Казань*

В 1953 г. окончил Казанский университет. С 1956 г. работал в журнале «Совет әдәбияты» («Советская литература»), с 1960 г. — в Казанском университете, с 1973 г. — в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР.
Исследования посвящены истории и теории татарской литературы, поэтике, текстологии, литературному источниковедению. Под его руководством были подготовлены и изданы многотомные собрания сочинений классиков татарской литературы. Премию получил в 1974 г. за книги «Шигырь гармониясе» («Гармония стиха», 1972), «Хәзерге татар поэтикасы» («Современная татарская поэтика», 1973).


# ЮЗИЕВ
## *Нил Гафур улы*

**әдәбият белгече, әдәбият тәнкыйтьчесе, филология фәннәре докторы (1974), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1981)**

*10.1.1931, Башкортстан АССРның Яңавыл районы Ямады авылы – 11.9.1996, Казан шәһәре*

1953 елда Казан университетын тәмамлый. 1956 елдан — «Совет әдәбияты» журналында, 1960 елдан — Казан университетында, 1973 елдан ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли.
Тикшеренүләре татар әдәбияты тарихына һәм теориясенә, поэтикага, текстологиягә, әдәби чыганак белеменә багышлана. Аның җитәкчелегендә татар әдәбияты классикларының күптомлы сайланма әсәрләре әзерләнә һәм нәшер ителә. Дәүләт бүләге 1974 елда «Шигырь гармониясе» (1972), «Хәзерге татар поэтикасы» (1973) китаплары өчен бирелә.

1976



## ВАЛЕЕВ
*Диас Назихович*

**писатель,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1981 г.),
РСФСР (1983 г.)**

*1.7.1938, с. Казанбаш Арского района ТАССР –
1.11.2010, г. Казань*

В 1962 г. окончил геологический факультет Казанского университета, в 1975 г. — Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва). В составе геологических партий работал в Удмуртии, Кировской области, на Южном Урале, в Кемеровской области, Хабаровском крае. В 1966–1972 гг. литературный сотрудник газеты «Комсомолец Татарии».
Наиболее ярко талант писателя раскрылся в области драматургии. Премию получил в 1976 г. за пьесу «Гомер бүләк итәм сиңа» («Дарю тебе жизнь», 1972), которая была поставлена в Казанском академическом русском Большом драматическом театре им. В. И. Качалова, Московском драматическом театре им. М. Н. Ермоловой, а также более чем в 50 других театрах страны.

---

## ВӘЛИЕВ
*Диас Назыйх улы*

**язучы,
ТАССРның (1981), РСФСРның (1983) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*1.7.1938, ТАССРның Арча районы Казанбаш авылы –
1.11.2010, Казан шәһәре*

1962 елда — Казан университетының геология факультетын, 1975 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. Геология партияләре составында Удмуртиядә, Киров өлкәсендә, Көньяк Уралда, Кемерово өлкәсендә, Хабаровск краенда эшли. 1966–1972 елларда — «Комсомолец Татарии» газетасының әдәби хезмәткәре.
Язучының таланты аеруча драматургия өлкәсендә ачыла. Дәүләт бүләге 1976 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрында, Мәскәүнең М. Н. Ермолова исемендәге драма театрында, шулай ук илнең 50 дән артык башка театрларында куелган «Тормыш бүләк итәм» (1972) пьесасы өчен бирелә.

1976



# ТУМАШЕВ
*Равиль Рахимович*

**режиссер,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1966 г.)**

*21.4.1923, г. Семипалатинск,*
*ныне Республика Казахстан – 2.1.2016, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. В 1952 г. окончил режиссерский факультет Государственного института театрального искусства (г. Москва). В 1963–1985 гг. главный режиссер Татарского передвижного театра (ныне Татарский театр драмы и комедии им. К. Тинчурина). Одновременно вел преподавательскую деятельность.
За годы работы в театре поставил около 60 спектаклей. Премию получил в 1976 г. за постановки пьес «Сандугачлар килгән безгә» («К нам прилетели соловьи») И. Юзеева, «Үзебез сайлаган язмыш» («Судьбы, которые мы выбираем») Т. Миннуллина и «Сары чәчәк ата көнбагыш» («Подсолнухи») А. Гилязова на сцене Татарского передвижного театра.

# ТУМАШЕВ
*Равил Рәхим улы*

**режиссер,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1966)**

*21.4.1923, хәзерге Казакъстан Республикасының*
*Семипалатинск шәһәре – 2.1.2016, Казан шәһәре*

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлык факультетын тәмамлый. 1963–1985 елларда — Татар күчмә театрының (хәзер К. Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театры) баш режиссеры. Бер үк вакытта педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә.
Театрда эшләгән елларында 60 ка якын спектакль куя. Дәүләт бүләге 1976 елда Татар күчмә театрында И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә», Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» һәм А. Гыйләҗевнең «Сары чәчәк ата көнбагыш» пьесаларын сәхнәгә куйган өчен бирелә.

1976



## ШАБАЕВ
*Марс Садриевич*

**писатель, поэт,**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1984 г.)**

*14.7.1933, д. Верхний Такермен Мензелинского района ТАССР – 22.2.2008, г. Казань*

Окончил Казанский педагогический институт (1958 г.). До 1970 г. работал в газете «Яшь ленинчы» («Молодой ленинец»), журналах «Азат хатын» («Свободная женщина»), «Чаян» («Скорпион»), в 1970–1983 гг. — в Татарском книжном издательстве, с 1991 г. — в журнале «Казан утлары» («Огни Казани»).
В своих произведениях создал образ труженика, человека, любящего Родину, размышлял о месте человека в обществе, его взаимосвязи с природой. Премию получил в 1976 г. за книги «Җикән камыш» («Камыши», 1972), «Онытма...» («Помни...», 1973) и сборник стихов на русском языке «Ищу тебя» (1974).

---


## ШАБАЕВ
*Марс Садри улы*

**язучы, шагыйрь,**
**ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984)**

*14.7.1933, ТАССРның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылы – 22.2.2008, Казан шәһәре*

Казан педагогия институтын тәмамлый (1958). 1970 елга кадәр «Яшь ленинчы» газетасында, «Азат хатын», «Чаян» журналларында эшли, 1970–1983 елларда — Татарстан китап нәшриятында, 1991 елдан — «Казан утлары» журналында.
Әсәрләрендә хезмәт кешесе, туган илне сөюче шәхес образын тудыра, кешенең җәмгыятьтәге урыны, аның табигать белән бәйләнеше турында уйлана. Дәүләт бүләге 1976 елда «Җикән камыш» (1972), «Онытма...» (1973), рус телендәге «Ищу тебя» (1974, «Сине эзлим») китаплары өчен бирелә.

1977



# АФЗАЛОВ (АБЗАЛОВ)

*Гамиль Гимазетдинович (псевдоним — Гамиль Афзал)*

**поэт,
заслуженный работник культуры ТАССР (1985 г.),
народный поэт ТАССР (1991 г.)**

*23.5.1921, с. Такталачук Мензелинского кантона ТАССР, ныне Актанышский район РТ – 20.8.2003, г. Альметьевск*

В 1936–1937 гг. учился в Татарском педагогическом техникуме в г. Троицке Челябинской области. В 1939–1949 гг. работал на Магнитогорском металлургическом комбинате. С 1953 г. жил в д. Шарипово Кушнаренковского района и в д. Заболотское Калтасинского района Башкирской АССР, с 1965 г. — в г. Альметьевске.

Поэт с активной гражданской позицией, глубокими философско-эстетическими взглядами. Премию получил в 1977 г. за сборник стихов «Айлы кичләр» («Лунные вечера», 1977) и стихи из цикла «Борылам да карыйм» («Оборачиваюсь и смотрю»).

# АФЗАЛОВ

*Гамил Гыймазетдин улы (псевдонимы — Гамил Афзал)*

**шагыйрь,
ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985),
ТАССРның халык шагыйре (1991)**

*23.5.1921, ТАССРның Минзәлә кантоны Актаныш волосте, хәзер ТРның Актаныш районы Такталачык авылы – 20.8.2003, Әлмәт шәһәре*

1936–1937 елларда Чиләбе өлкәсе Троицк шәһәрендәге Татар педагогия техникумында укый. 1939–1949 елларда Магнитогорск металлургия комбинатында эшли. 1953 елдан — Башкортстан АССРның Кушнаренко районы Шәрип һәм Калтасы районы Заболотский авылларында, 1965 елдан Әлмәт шәһәрендә яши.

Актив гражданлык позициясенә, тирән фәлсәфи-эстетик карашларга ия шагыйрь. Дәүләт бүләге 1977 елда «Айлы кичләр» (1977) шигырьләр җыентыгы һәм «Борылам да карыйм» шигырьләр циклы өчен бирелә.

1977



# БЕСПАЛОВ
*Виктор Иванович*

**кинорежиссер, кинодокументалист, заслуженный деятель искусств ТАССР (1976 г.), РСФСР (1984 г.)**

*12.8.1925, г. Томск – 5.9.2015, г. Казань*

В 1949 г. окончил Новосибирский педагогический институт, в 1967 г. — Высшие режиссерские курсы (г. Москва). В 1960–1970 гг. режиссер Новосибирской, в 1970–1986 гг. — Казанской студии телевидения.
Снял около 50 документальных и музыкальных фильмов, в том числе «Советский Татарстан», «КамАЗ начинается», «Республика моя, Татарстан», «Город, рожденный нефтью»; фильмы о творчестве музыкантов: «Моң (Мелодия души)», «Рустем Яхин. Сентиментальное путешествие», «Сны Тукая». Премию получил в 1977 г. за режиссерскую работу в фильмах «Татар гармуннары» («Татарские гармошки», 1971 г.), «Н. Җиһанов музыкасы» («Музыка Н. Жиганова», 1972 г.), «Кырлай» (1974 г.).

# БЕСПАЛОВ
*Виктор Иванович*

**кинорежиссер, кинодокументалист, ТАССРның (1976), РСФСРның (1984) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*12.8.1925, Томск шәһәре – 5.9.2015, Казан шәһәре*

1949 елда — Новосибирск педагогия институтын, 1967 елда Югары режиссерлык курсларын (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. 1960–1970 елларда — Новосибирск, 1970–1986 елларда — Казан телевидение студиясе режиссеры.
50 гә якын документаль һәм музыкаль фильм, шул исәптән «Совет Татарстаны», «КамАЗ башлана», «Республикам минем, Татарстан», «Нефть тудырган шәһәр»; музыкантлар иҗаты турында «Моң», «Рөстәм Яхин. Сентименталь сәяхәт», «Тукай төшләре» фильмнарын төшерә. Дәүләт бүләге 1977 елда «Татар гармуннары» (1971), «Нәҗип Җиһанов музыкасы» (1972), «Кырлай» (1974) фильмнарындагы режиссерлык эше өчен бирелә.

1977



# ХАКИМОВА
## *Ирина Шарифовна*

**артистка балета, педагог,**
**заслуженная артистка ТАССР (1974 г.),**
**народная артистка ТАССР (1976 г.), РСФСР (1987 г.)**

*29.3.1951, г. Юрюзань Челябинской области*

В 1970 г. окончила Пермское хореографическое училище, в 2007 г. — Казанскую консерваторию. В 1970–1996 гг. солистка балета, в 1997–2003 гг. педагог-репетитор балетной труппы Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля, с 1993 г. педагог Казанского хореографического училища.

Танец артистки отличался чистотой исполнения классического па, высокой техникой, образной выразительностью. Премию получила в 1977 г. за партии Сююмбике в балете «Шурале» Ф. Яруллина, Сарви — в «Су анасы» («Водяная») Э. Бакирова и Одетты-Одиллии — в «Лебедином озере» П. Чайковского на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# ХӘКИМОВА
## *Ирина Шәриф кызы*


**балет артисты, педагог,**
**ТАССРның атказанган артисты (1974),**
**ТАССРның (1976), РСФСРның (1987) халык артисты**

*29.3.1951, Чиләбе өлкәсенең Йөрүзән шәһәре*

1970 елда — Пермь хореография училищесын, 2007 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1970–1996 елларда — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының балет солисты, 1997–2003 елларда — балет труппасының педагог-репетиторы, 1993 елдан — Казан хореография училищесы педагогы.

Артистканың биюе классик па хәрәкәтен чиста башкаруы, югары техникасы, образлы сәнгатьчәлеге белән аерылып тора. Дәүләт бүләге 1977 елда М.Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетында — Сөембикә, Ә. Бакировның «Су анасы» балетында — Сәрви, П. Чайковскийның «Аккош күле» балетында — Одетта-Одиллия партияләре өчен бирелә.

1978



# ЛЫВИН
## *Сергей Осипович*

**живописец,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1960 г.),**
**народный художник ТАССР (1973 г.)**

*29.9.1923, с. Черемышево Лаишевского кантона ТАССР, ныне Пестречинский район РТ – 18.3.2000, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. В 1947 г. окончил Казанское художественное училище. Один из ведущих пейзажистов республики в 1960–1970-е гг.
Основная тема творчества художника — многообразие, неброская красота и величие, связь с жизнью людей природы. Большую живописную серию «Здесь песни пел свои Тукай» (1975–1976 гг.) создал к 90-летию со дня рождения поэта по материалам, собранным в местах, где прошло детство поэта. Премию получил в 1978 г. за серию картин, посвященных В. И. Ленину и Г. Тукаю.

# ЛЫВИН
## *Сергей Осипович*

**нәкышьче,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1960),**
**ТАССРның халык рәссамы (1973)**

*29.9.1923, ТАССРның Лаеш кантоны, хәзер Питрәч районы Черемыш авылы – 18.3.2000, Казан шәһәре*

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый.
1960–1970 елларда республикада әйдәп баручы пейзаж осталарының берсе. Рәссам иҗатының төп темасы — табигатьнең үзгәрүчәнлеге, тыйнак матурлыгы һәм бөеклеге, кеше тормышы белән өзлексез бәйләнештә булуы. Г. Тукайның тууына 90 ел тулу уңаеннан аның балачагы узган урыннарда тупланган материаллар буенча «Монда Тукай үз җырларын җырлады» (1975–1976) зур нәкышь сериясе иҗат итә. Дәүләт бүләге 1978 елда В. И. Ленин һәм Г. Тукайга багышланган картиналар сериясе өчен бирелә.

1978



# ФАЙЗУЛЛИН
*Равиль Абдрахманович*

**поэт, общественный деятель,
заслуженный работник культуры РСФСР (1985 г.),
народный поэт РТ (1999 г.)**

*4.8.1943, д. Юлсубино Рыбно-Слободского района ТАССР*

В 1965 г. окончил Казанский университет. В 1968–1972 гг. ответственный секретарь Альметьевского отделения Союза писателей ТАССР, в 1973–1977 гг. заместитель председателя правления Союза писателей ТАССР. В 1989–2013 гг. главный редактор журнала «Казан утлары» («Огни Казани»).

Рано вступив в литературу (в 1960-е гг. был самым молодым членом Союза писателей СССР), за годы своей активной творческой деятельности он внес значительный вклад в развитие многонациональной поэзии. Премию получил в 1978 г. за книгу «Шигырьләр һәм поэмалар» («Стихи и поэмы», 1976).

# ФӘЙЗУЛЛИН
*Равил Габдрахман улы*

**шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе,
РСФСРның атказанган мәдәният
хезмәткәре (1985),
ТРның халык шагыйре (1999)**

*4.8.1943, ТАССРның Балык Бистәсе районы Балтач авылы*

1965 елда Казан университетын тәмамлый. 1968–1972 елларда — ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркатибе, 1973–1977 елларда — ТАССР Язучылар берлеге рәисе урынбасары. 1989–2013 елларда — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.

Әдәбиятка иртә килеп (1960 елларда СССР Язучылар берлегенең иң яшь әгъзасы була), актив иҗат эшчәнлеге дәверендә күпмиллләтле поэзия үсешенә зур өлеш кертә. Дәүләт бүләге 1978 елда «Шигырьләр һәм поэмалар» (1976) китабы өчен бирелә.



## ИБРАГИМОВ
*Ренат Исламович*

**певец (баритон),**
**народный артист ТАССР (1980 г.),**
**Каракалпакской АССР (1980 г.), РСФСР (1981 г.)**

*20.11.1947, г. Львов, Украинская ССР –*
*14.5.2022, г. Москва*

В 1973 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1973–1988 гг. солист Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля, в 1988–1990 гг. — Татарской филармонии им. Г. Тукая. С 1990 г. в Москве: художественный руководитель и солист Татарского культурного центра «Сафар», в 1998–1999 гг. начальник Управления культуры РАО «Газпром». С 1999 г. художественный руководитель и солист «Театра песни Рената Ибрагимова».
Репертуар певца включал арии из опер, оперетт и мюзиклов, классические романсы, популярные эстрадные песни. Премию получил в 1979 г. за концертные программы 1976–1978 гг.

## ИБРАҺИМОВ
*Ренат Ислам улы*

**җырчы (баритон),**
**ТАССРның (1980), Каракалпак АССРның (1980),**
**РСФСРның (1981) халык артисты**

*20.11.1947, Украина ССРның Львов шәһәре –*
*14.5.2022, Мәскәү шәһәре*

1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1973–1988 елларда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры солисты, 1988–1990 елларда — Г. Тукай исемендәге Татар филармониясе солисты. 1990 елдан Мәскәүдә: «Сәфәр» татар мәдәният үзәгенең сәнгать җитәкчесе һәм солисты, 1998–1999 елларда — «Газпром» РАҖнең Мәдәният идарәсе башлыгы. 1999 елдан — «Ренат Ибраһимовның җыр театры» сәнгать җитәкчесе һәм солисты.
Җырчының репертуары опера, оперетта һәм мюзикллардан арияләр, классик романслар, популяр эстрада җырларын үз эченә ала. Дәүләт бүләге 1979 елда 1976–1978 еллардагы концерт программалары өчен бирелә.

1979



## КУЗАЕВА
*Дамифа Назмизяновна*

драматическая актриса,
народная артистка ТАССР (1984 г.)

*16.5.1948, д. Тунгук Бардинского района Пермской области – 20.12.1993, г. Альметьевск*

В 1970 г. окончила Казанское театральное училище. С 1966 г. актриса Альметьевского татарского драматического театра.
Для ее актерской игры характерны органичность, психологическая наполненность, эмоциональность, чувство ритмической и поэтической тональности. Премию получила в 1979 г. за роль Мадины в спектакле «Ай булмаса, йолдыз бар» («Нет луны, так светят звезды», 1977 г.) по пьесе Т. Миннуллина, поставленном на сцене Альметьевского татарского драматического театра.

## КУЗАЕВА
*Дамифә Нәҗмиҗан кызы*

драма актрисасы,
ТАССРның халык артисты (1984)

*16.5.1948, Пермь өлкәсенең Барда районы Түнгүк (Төнгүк) авылы – 20.12.1993, Әлмәт шәһәре*

1970 елда Казан театр училищесын тәмамлый. 1966 елдан — Әлмәт татар драма театры актрисасы.
Аның актерлык уенына табигыйлык, психологик бөтенлек, эмоциональлек, ритмик һәм поэтик тоемлау хас. Дәүләт бүләге 1979 елда Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесасы буенча Әлмәт татар драма театры сәхнәсендә куелган спектакльдәге (1977) Мәдинә роле өчен бирелә.

1979



# **МИННУЛЛИН**
## *Туфан Абдуллович*

**драматург, публицист,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1978 г.), РСФСР (1984 г.), Республики Башкортостан (1995 г.), народный писатель РТ (2005 г.)**

*25.8.1935, д. Большое Мереткозино Камско-Устьинского района ТАССР – 2.5.2012, г. Казань*

В 1961 г. окончил Театральное училище им. М. С. Щепкина (г. Москва), в 1977 г. — Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва). В 1961–1962 гг. актер Мензелинского драматического театра, в 1962–1963 гг. — Татарского академического театра им. Г. Камала. В 1963–1964 гг. редактор Комитета радиовещания и телевидения при Совете Министров ТАССР, в 1964–1968 гг. литературный сотрудник журнала «Чаян» («Скорпион»). В 1984–1989 гг. председатель правления Союза писателей ТАССР.
Автор около 40 пьес, более 10 пьес-сказок для детей, повестей, рассказов. Премию получил в 1979 г. за пьесу «Ай булмаса, йолдыз бар» («Нет луны, так светят звезды», 1977), по которой на сцене Альметьевского татарского драматического театра был поставлен спектакль.


# **МИҢНУЛЛИН**
## *Туфан Габдулла улы*

**драматург, публицист,
ТАССРның (1978), РСФСРның (1984), Башкортстан Республикасының (1995) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык язучысы (2005)**

*25.8.1935, ТАССРның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылы – 2.5.2012, Казан шәһәре*

1961 елда — М. С. Щепкин исемендәге Театр училищесын (Мәскәү шәһәре), 1977 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. 1961–1962 елларда — Минзәлә драма театры, 1962–1963 елларда — Г. Камал исемендәге Татар академия театры актеры. 1963–1964 елларда — ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетында мөхәррир, 1964–1968 елларда — «Чаян» журналы әдәби хезмәткәре. 1984–1989 елларда — ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе.
40 ка якын пьеса, балалар өчен уннан артык әкият-пьеса, повестьлар, хикәяләр авторы. Дәүләт бүләге 1979 елда Әлмәт татар драма театрында сәхнәләштерелгән «Ай булмаса, йолдыз бар» (1977) пьесасы өчен бирелә.

1979



# ХУСАИНОВ
*Гали Каримович*

**драматический актер, режиссер,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1966 г.),**
**РСФСР (1982 г.)**

*2.11.1919, с. Кугеево Свияжского уезда Казанской губернии, ныне Зеленодольский район РТ – 26.7.2001, г. Казань*

В 1938 г. окончил студию при Татарском академическом театре и в 1949 г. — Татарскую студию при Государственном институте театрального искусства (г. Москва). Участник Великой Отечественной войны. В 1949–1952 гг. актер Татарского академического театра им. Г. Камала. В 1952–1969, 1972–1975 гг. режиссер, главный режиссер Татарского республиканского радио и телевидения. В 1969–1972, 1975–1983 гг. возглавлял Альметьевский татарский драматический театр, на сцене которого в качестве режиссера поставил около 30 спектаклей.

Премию получил в 1979 г. за постановку спектакля «Ай булмаса, йолдыз бар» («Нет луны, так светят звезды», 1977 г.) по пьесе Т. Миннуллина на сцене Альметьевского татарского драматического театра.

# ХӨСӘЕНОВ
*Гали Кәрим улы*


**драма актеры, режиссер,**
**ТАССРның (1966), РСФСРның (1982) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*2.11.1919, Казан губернасының Зөя өязе, хәзер ТРның Зеленодольск районы Күгәй авылы – 26.7.2001, Казан шәһәре*

1938 елда Татар академия театры каршындагы студияне һәм 1949 елда Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС, Мәскәү шәһәре) каршындагы Татар студиясен тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1949–1952 елларда — Г. Камал исемендәге Татар академия театры актеры. 1952–1969, 1972–1975 елларда — Татарстан республика радио һәм телевидениесе режиссеры, баш режиссеры. 1969–1972, 1975–1983 елларда Әлмәт татар драма театрын җитәкли, аның сәхнәсендә режиссер буларак 30 лап спектакль куя.

Дәүләт бүләге 1979 елда Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесасы (1977) буенча Әлмәт татар драма театры сәхнәсендә куелган спектакльнең режиссеры буларак бирелә.

1980



# МАЛИКОВ
*Васил Маликович*

**скульптор,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1970 г.),**
**народный художник ТАССР (1974 г.),**
**заслуженный художник РСФСР (1982 г.)**

*19.10.1924, д. Старое Курмашево Мензелинского кантона ТАССР, ныне Актанышский район РТ – 11.10.1992, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. В 1953 г. окончил Казанское художественное училище, в 1959 г. — Высшее художественно-промышленное училище им. В. И. Мухиной (г. Ленинград), где учился на отделении монументально-декоративной скульптуры. С 1959 г. жил в Казани.

Один из инициаторов развития монументального искусства в Казани. Премию получил в 1980 г. как скульптор монумента павшим в борьбе за Советскую власть у Центрального парка культуры и отдыха им. М. Горького в Казани (архитекторы А. А. Спориус, Г. М. Пичуев).

# МАЛИКОВ
*Васил Малик улы*

**сынчы,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1970),**
**ТАССРның халык рәссамы (1974),**
**РСФСРның атказанган рәссамы (1982)**

*19.10.1924, ТАССРның Минзәлә кантоны, хәзер Актаныш районы Иске Кормаш авылы – 11.10.1992, Казан шәһәре*

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 елда — Казан сынлы сәнгать училищесын, 1959 елда В. И. Мухина исемендәге Югары сәнгать-сәнәгать училищесын (Ленинград шәһәре) тәмамлый, монументаль-декоратив скульптура бүлегендә укый. 1959 елдан Казанда яши.

Казанда монументаль сәнгатьне үстерүгә башлангыч бирүчеләрнең берсе. Дәүләт бүләге 1980 елда Казанда Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы янындагы Совет власте өчен көрәштә һәлак булганнарга куелган монумент скульпторы буларак бирелә (архитекторлары — А. А. Спориус, Г. М. Пичуев).

1980



## ЮЗЕЕВ
*Ильдар Гафурович*

**поэт,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1979 г.), РСФСР (1983 г.), народный поэт РТ (1993 г.)**

*3.1.1933, д. Ямады Янаульского района Башкирской АССР – 21.12.2004, г. Казань*

В 1954 г. окончил Казанский педагогический институт, в 1973 г. — Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва). В 1954–1966 гг. ответственный секретарь журнала «Пионер», в 1966–1967 гг. литературный сотрудник журнала «Чаян» («Скорпион»), в 1967–1971 гг. консультант Союза писателей ТАССР, в 1973–1976 гг. заведующий отделом поэзии журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), в 1977–1987 гг. заместитель председателя правления Союза писателей ТАССР по работе с молодыми писателями.
Автор 30 поэм и около 40 поэтических сборников. Премию получил в 1980 г. за поэмы «Таш диварлар авазы» («Звуки каменных стен», 1973) и «Өзелмәсме кыллар?» («Струны», 1978).

## ЮЗЕЕВ
*Илдар Гафур улы*

**шагыйрь,**
**ТАССРның (1979), РСФСРның (1983) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык шагыйре (1993)**

*3.1.1933, Башкортстан АССРның Яңавыл районы Ямады авылы – 21.12.2004, Казан шәһәре*

1954 елда — Казан педагогия институтын, 1973 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. 1954–1966 елларда — «Пионер» журналының җаваплы сәркатибе, 1966–1967 елларда — «Чаян» журналы әдәби хезмәткәре, 1967–1971 елларда — ТАССР Язучылар берлеге консультанты, 1973–1976 елларда — «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире, 1977–1987 елларда — ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисенең яшь язучылар белән эшләү буенча урынбасары.
30 поэма һәм 40 ка якын шигырь җыентыгы авторы. Дәүләт бүләге 1980 елда «Таш диварлар авазы» (1973) һәм «Өзелмәсме кыллар?» (1978) поэмалары өчен бирелә.

1981



# КУЗИН
*Евгений Андриянович*

**драматический актер,**
**народный артист ТАССР (1975 г.),**
**заслуженный артист РСФСР (1981 г.)**

*2.4.1933, с. Большая Кандала Старомайнского района Ульяновской области – 16.6.2004, г. Казань*

В 1956 г. окончил Казанский университет. В 1956–1958 гг. инженер-геолог Асбестово-Нейвинской геологической партии. В 1958 г. поступил в студию при Казанском академическом русском Большом драматическом театре им. В. И. Качалова, в 1959–1998 гг. актер этого театра, одновременно в 1985–1987 гг. его директор. С 1965 г. педагог Казанского театрального училища.
Много лет был одним из ведущих актеров театра. Внес большой вклад в пропаганду татарской литературы, принимал участие в теле- и радиопередачах с чтением стихотворений Г. Тукая, Х. Такташа, М. Джалиля и др. Премию получил в 1981 г. за главные роли в спектаклях «Большевики» М. Шатрова, «Гостиница „Астория“» А. Штейна и др. на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.


# КУЗИН
*Евгений Андриянович*

**драма актеры,**
**ТАССРның халык артисты (1975),**
**РСФСРның атказанган артисты (1981)**

*2.4.1933, Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы Олы Кандал авылы – 16.6.2004, Казан шәһәре*

1956 елда Казан университетын тәмамлый. 1956–1958 елларда — Асбест-Нейвинский геология партиясе инженер-геологы. 1958 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры каршындагы студиягә укырга керә, 1959–1998 елларда әлеге театр актеры, бер үк вакытта, 1985–1987 елларда, аның директоры. 1965 елдан — Казан театр училищесы педагогы.
Озак еллар дәвамында театрның әйдәп баручы актерларыннан берсе була. Татар әдәбиятын пропагандалауга зур өлеш кертә, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләрен уку белән телевидение һәм радио тапшыруларында катнаша. Дәүләт бүләге 1981 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры сәхнәсендә М. Шатровның «Большевиклар», А. Штейнның «„Астория“ кунакханәсе» пьесалары буенча куелган һәм башка спектакльләрдәге баш рольләре өчен бирелә.

1981



# ФЕДОТОВ
## *Юрий Степанович*

**актер,**
**народный артист ТАССР (1979 г.), РФ (1996 г.)**

*17.8.1938, г. Казань –*
*5.10.2008, там же*

С 1957 г. актер Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова, в 1961 г. окончил студию при нем.
Сыграл в театре около 200 ролей, многие из которых вошли в золотой фонд российского театрального искусства, стали значительными событиями в культурной жизни республики. Премию получил в 1981 г. за главные роли в спектаклях «Большевики» М. Шатрова, «Гостиница “Астория”» А. Штейна и др. на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.

---


# ФЕДОТОВ
## *Юрий Степанович*

**актер,**
**ТАССРның (1979), РФнең (1996) халык артисты**

*17.8.1938, Казан шәһәре –*
*5.10.2008, шунда ук*

1957 елдан — В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры актеры, 1961 елда әлеге театр каршындагы студияне тәмамлый.
Театрда 200 гә якын роль башкара, аларның күбесе Россия театр сәнгатенең алтын фондына кертелә, республика мәдәни тормышында мөһим вакыйгага әверелә. Дәүләт бүләге 1981 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры сәхнәсендә М. Шатровның «Большевиклар», А. Штейнның «„Астория“ кунакханәсе» пьесалары буенча куелган һәм башка спектакльләрдәге баш рольләре өчен бирелә.

1981



## РАСУЛЕВ
*Атилла Кадырович (псевдоним — Атилла Расих)*

писатель,
зоотехник, кандидат сельскохозяйственных наук (1950 г.)

*3(16).9.1916, г. Стамбул, Турция – 9.5.1996, г. Казань*

С 1929 г. жил в Казани. В 1938 г. окончил Казанский ветеринарный институт. С 1940 г. в Наркомате земледелия ТАССР. Участник Великой Отечественной войны. В 1947–1964 гг. работал в Казанском ветеринарном институте.
Начал публиковаться в довоенные годы, в период Великой Отечественной войны писал на фронтовые темы. Первым в татарской прозе обратился к изображению мира научных работников. Премию получил в 1981 г. за романы «Язгы авазлар» («Весенние голоса», 1963), «Ике буйдак» («Два холостяка», 1965), «Сынау» («Испытание», 1978), трилогию «Ямашев» (1967–1981).

## РӘСҮЛЕВ
*Атилла Кадыйр улы (псевдонимы — Атилла Расих)*

язучы,
зоотехник, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты (1950)

*3(16).9.1916, Төркия, Истанбул шәһәре – 9.5.1996, Казан шәһәре*

1929 елдан Казанда яши. 1938 елда Казан ветеринария институтын тәмамлый. 1940 елдан — ТАССР Җир эшләре халык комиссариатында. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–1964 елларда Казан ветеринария институтында эшли.
Әсәрләре сугышка кадәрге чорда басыла башлый, Бөек Ватан сугышы елларында фронт темаларына яза. Татар прозасында беренче булып фән өлкәсе хезмәткәрләре дөньясын сурәтләүгә мөрәҗәгать итә. Дәүләт бүләге 1981 елда «Язгы авазлар» (1963), «Ике буйдак» (1965), «Сынау» (1978) романнары, «Ямашев» трилогиясе (1967–1981) өчен бирелә.

1981



# БАКУЛИН
*Герман Алексеевич*

**архитектор,
заслуженный архитектор РТ (1994 г.)**

*18.6.1947, г. Казань*

В 1971 г. окончил Казанский инженерно-строительный институт. С 1971 г. в институте «Татаргражданпроект» (с 1992 г. «Татинвестгражданпроект»): с 1975 г. руководитель группы архитекторов, с 1982 г. главный архитектор проектов, с 1988 г. главный архитектор.

В период разработки концепции генерального плана Казани предложил основные закономерности формирования нового облика города с учетом преемственного принципа развития. В соавторстве с художниками проектировал памятники известным деятелям республики. Спроектировал большое количество зданий, ставших визитной карточкой города. Премию получил в составе авторского коллектива в 1981 г. за проектировку и строительство Выставочного зала Союза художников ТАССР (г. Казань, 1979 г.).

# БАКУЛИН
*Герман Алексеевич*

**архитектор,
ТРның атказанган архитекторы (1994)**

*18.6.1947, Казан шәһәре*

1971 елда Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый. 1971 елдан — «Татаргражданпроект» институтында (1992 елдан — «Татинвестгражданпроект»): 1975 елдан — архитекторлар төркеме җитәкчесе, 1982 елдан — проектлар баш архитекторы, 1988 елдан — баш архитектор.

Казанның генераль планы концепциясен эшләү барышында шәһәрнең яңа йөзен формалаштыруда төп закончалык итеп аны үткәннәр мирасына таянып үстерү принцибын тәкъдим итә. Рәссамнар белән автордашлыкта республиканың танылган кешеләренә һәйкәл проектлары эшли. Шәһәрнең визит карточкасына әверелгән күпләгән биналарны проектлый. Дәүләт бүләге 1981 елда авторлар коллективы составында ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залын проектлаган һәм төзегән (Казан шәһәре, 1979) өчен бирелә.

1981



## ЗАКИЕВ
*Ауфар Закиевич*

**инженер-строитель,**
**заслуженный строитель ТАССР (1980 г.)**

*16.4.1938, д. Сарысаз-Такерман Сармановского района ТАССР – 2.2.1994, г. Казань*

В 1968 г. окончил Казанский инженерно-строительный институт. В 1962–1969, 1974–1994 гг. в концерне «Татстрой»: инженер, главный инженер, заместитель начальника. В 1969–1974 гг. инструктор отдела строительства Татарского обкома КПСС.
Внес большой вклад в развитие новых строительных технологий и возведение важнейших объектов промышленного и культурно-бытового назначения в Казани и районах республики. Премию получил в 1981 г. в составе авторского коллектива за проектировку и строительство Выставочного зала Союза художников ТАССР (г. Казань, 1979 г.).

## ЗӘКИЕВ
*Әүфәр Зәки улы*

**төзүче инженер,**
**ТАССРның атказанган төзүчесе (1980)**

*16.4.1938, ТАССРның Сарман районы Сарысаз-Тәкермән авылы – 2.2.1994, Казан шәһәре*

1968 елда Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый. 1962–1969, 1974–1994 елларда — «Татстрой» концернында: инженер, баш инженер, башлык урынбасары. 1969–1974 елларда — КПССның Татарстан өлкә комитеты төзелеш бүлеге инструкторы.
Казан шәһәрендә һәм республика районнарында яңа төзелеш технологияләрен үстерүгә һәм сәнәгать, мәдәни-көнкүреш объектларын төзүгә зур өлеш кертә. Дәүләт бүләге 1981 елда авторлар коллективы составында ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залын проектлаган һәм төзегән (Казан шәһәре, 1979) өчен бирелә.

1981



# ПАРАМОНОВ
*Игорь Петрович*

**инженер-строитель,**
**заслуженный строитель ТАССР (1991 г.)**

*24.6.1936, г. Казань –*
*21.12.2022, там же*


В 1959 г. окончил Казанский инженерно-строительный институт. В 1959–1985 гг. работал в строительно-монтажном тресте №2 «Главтатстроя». В 1985–1995 гг. заместитель директора, в 1995–1997 гг. помощник директора по капитальному строительству Казанского НИИ радиоэлектроники. С 1997 г. заместитель директора Казанского электромонтажного предприятия.
Участвовал в строительстве многих объектов г. Казани. Премию получил в 1981 г. в составе авторского коллектива за проектировку и строительство Выставочного зала Союза художников ТАССР (г. Казань, 1979 г.).

# ПАРАМОНОВ
*Игорь Петрович*

**төзүче инженер,**
**ТАССРның атказанган төзүчесе (1991)**

*24.6.1936, Казан шәһәре –*
*21.12.2022, шунда ук*

1959 елда Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый. 1959–1985 елларда «Главтатстрой»ның 2 нче төзү-монтаж трестында эшли. 1985–1995 елларда — Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү институты директоры урынбасары, 1995–1997 елларда — директорның капиталь төзелеш буенча ярдәмчесе. 1997 елдан — Казан электр-монтажлау предприятиесе директоры урынбасары.
Казан шәһәрендәге күпсанлы объектларны төзүдә катнаша. Дәүләт бүләге 1981 елда авторлар коллективы составында ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залын проектлаган һәм төзегән (Казан шәһәре, 1979) өчен бирелә.



# ФАЙЗУЛЛИН
*Анас Нуруллович*

**строитель, штукатур**

*1928 – 27.5.2013, г. Казань*

С 1952 г. бригадир штукатуров СМУ-10 «Стройтреста» №2. С его участием построено множество промышленных, жилых и культурно-бытовых зданий в Казани. Владел приемами декоративной штукатурки.
Премию получил в 1981 г. в составе авторского коллектива за проектировку и строительство Выставочного зала Союза художников ТАССР (г. Казань, 1979 г.).

# ФӘЙЗУЛЛИН
*Әнәс Нурулла улы*

**төзүче, штукатурчы**

*1928 – 27.5.2013, Казан шәһәре*

1952 елдан 2 нче Төзелеш трестының 10 нчы төзү-монтаж идарәсе (СМУ) штукатурлар бригадиры. Казан шәһәрендәге күпсанлы сәнәгать, торак һәм мәдәни-көнкүреш биналарын төзүгә өлеш кертә. Декоратив штукатурлау ысулларын куллана.
Дәүләт бүләге 1981 елда авторлар коллективы составында ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залын проектлаган һәм төзегән (Казан шәһәре, 1979) өчен бирелә.

1981



## ХИСАМУТДИНОВА
*Сания Шакуровна*

**строитель, плиточница**

*21.4.1934, д. Татарское Пимурзино Буинского района ТАССР – 22.8.2017, г. Буинск*

С 1961 г. облицовщица в СУОР-13 «Стройтреста» №2. Участвовала в строительстве многих объектов г. Казани. Премию получила в 1981 г. в составе авторского коллектива за проектировку и строительство Выставочного зала Союза художников ТАССР (г. Казань, 1979 г.).

---

## ХИСАМЕТДИНОВА
*Сания Шәкүр кызы*

**төзүче, плитка ябыштыручы**

*21.4.1934, ТАССРның Буа районы Татар Биморзасы авылы – 22.8.2017, Буа шәһәре*

1961 елдан 2 нче Төзелеш трестының 13 нче Махсус бизәү эшләре идарәсе (СУОР) плитка ябыштыручысы.
Казан шәһәрендәге күпсанлы объектларны төзүгә өлеш кертә. Дәүләт бүләге 1981 елда авторлар коллективы составында ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залын проектлаган һәм төзегән (Казан шәһәре, 1979) өчен бирелә.

1982



## НУРУЛЛИН
*Ибрагим Зиннятович*

литературовед, писатель,
доктор филологических наук (1968 г.),
профессор (1970 г.)

*18.4.1923, д. Боровка Мелекесского уезда Самарской губернии, ныне Мелекесский район Ульяновской области – 1.7.1995, г. Казань*

В 1950 г. окончил Казанский университет, в 1953–1990 гг. преподавал там же.
Автор трудов по истории татарской литературы начала XX в. и советского периода, по теории творческих методов, о творчестве Г. Тукая, Ф. Амирхана, Г. Исхаки, Ш. Камала, М. Амира и др. Осмысление творческого процесса и личности писателя было главной темой художественных произведений писателя. Премию получил в 1982 г. за художественно-биографические книги «Тукай» (М., 1977) и «Габдулла Тукай» (Казань, 1979).

## НУРУЛЛИН
*Ибраһим Зиннәт улы*

әдәбият галиме, язучы,
филология фәннәре докторы (1968),
профессор (1970)

*18.4.1923, Самара губернасының Мәләкәс өязе, хәзер Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс районы Парау авылы – 1.7.1995, Казан шәһәре*

1950 елда Казан университетын тәмамлый, 1953–1990 елларда шунда ук укыта. XX йөз башы һәм совет чоры татар әдәбияты тарихы, иҗат методлары теориясе, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Ш. Камал, М. Әмир һәм башкалар иҗаты турында хезмәтләр авторы. Әдәби әсәрләренең төп темасын язучы шәхесен һәм иҗат процессы үзенчәлекләрен ачу тәшкил итә. Дәүләт бүләге 1982 елда «Тукай» (Мәскәү, 1977) һәм «Габдулла Тукай» (Казан, 1979) әдәби-биографик китаплары өчен бирелә.

1983



# ГИЛЯЗОВ
## *Аяз Мирсаидович*

писатель,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1978 г.), РСФСР (1985 г.), народный писатель РТ (1993 г.)

*17.1.1928, д. Чукмарлы Челнинского кантона ТАССР, ныне Сармановский район РТ – 13.3.2002, г. Казань*

В 1948 г. поступил в Казанский университет. В 1950 г. необоснованно осужден за «антисоветскую пропаганду». После освобождения в 1955 г. продолжил учебу. В 1957–1961 гг. литературный сотрудник журналов «Чаян» («Скорпион») и «Азат хатын» («Свободная женщина»), редактор отдела прозы журнала «Совет әдәбияты» («Советская литература»). В 1963 г. окончил Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва).
Произведения Гилязова отличаются удивительно ярким, мелодичным и естественным языком. Известен как драматург, спектакли по его пьесам входят в репертуар многих театров республики. Премию получил в 1983 г. за повести «Җомга көн, кич белән...» («В пятницу вечером», 1979), «Әтәч менгән читәнгә» («Петух на плетне», 1980).


# ГЫЙЛӘҖЕВ
## *Аяз Мирсәет улы*

язучы,
ТАССРның (1978), РСФСРның (1985) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык язучысы (1993)

*17.1.1928, ТАССРның Чаллы кантоны, хәзер ТРның Сарман районы Чукмарлы авылы – 13.3.2002, Казан шәһәре*

1948 елда Казан университетына укырга керә. 1950 елда «совет хакимиятенә каршы пропаганда» өчен нахакка хөкем ителә. 1955 елда азат ителгәннән соң, укуын дәвам итә. 1957–1961 елларда — «Чаян» һәм «Азат хатын» журналлары әдәби хезмәткәре, «Совет әдәбияты» журналының проза бүлеге мөхәррире. 1963 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү шәһәре) тәмамлый.
Әсәрләре үзенчәлекле, сыгылмалы һәм табигый теле белән аерылып тора. Драматург буларак таныла, аның пьесалары буенча куелган спектакльләр республиканың күп кенә театрлары репертуарына кертелә. Дәүләт бүләге 1983 елда «Җомга көн, кич белән...» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1980) повестьлары өчен бирелә.

1983



# ЕНИКЕЕВ
## *Ренат Ахметович*

**композитор, пианист,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1979 г.),**
**РСФСР (1987 г.), народный артист РТ (2002 г.)**

*13.6.1937, г. Казань – 13.3.2020, там же*

В 1961 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1956–1957 гг. преподаватель музыкально-теоретических дисциплин и композиции Казанского музыкального училища, в 1961–1963 гг. заведующий музыкальной частью Татарского академического театра им. Г. Камала, в 1963–1973 гг. солист-пианист, концертмейстер Татарской филармонии им. Г. Тукая.

Один из ведущих современных татарских композиторов, автор большого количества произведений различных жанров. Центральное место в его творчестве занимают инструментальные и вокальные сочинения, музыка для детей. Премию получил в 1983 г. за вокально-симфоническую поэму «Памяти Мусы Джалиля» для смешанного хора, симфонического оркестра, органа и чтеца на стихи Х. Туфана (1981 г.).

# ЕНИКИЕВ
## *Ренат Әхмәт улы*

**композитор, пианист,**
**ТАССРның (1979), РСФСРның (1987) атказанган сәнгать эшлеклесе,**
**ТРның халык артисты (2002)**

*13.6.1937, Казан шәһәре – 13.3.2020, шунда ук*

1961 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1956–1957 елларда — Казан музыка училищесында музыка теориясе һәм композиция укытучысы, 1961–1963 елларда — Г. Камал исемендәге Татар академия театрының музыка бүлеге мөдире, 1963–1973 елларда — Г. Тукай исемендәге Татар филармониясендә солист-пианист, концертмейстер.

Хәзерге чор күренекле татар композиторларының берсе була, төрле жанрда иҗат ителгән күпсанлы әсәрләр авторы. Аның иҗатында үзәк урынны инструменталь һәм вокаль әсәрләр, балалар өчен язылган музыкаль әсәрләр алып тора. Дәүләт бүләге 1983 елда Х. Туфан шигырьләреннән торган нәфис сүз башкаручы, катнаш хор, симфоник оркестр, орган өчен язылган «Муса Җәлил истәлегенә» вокаль-симфоник поэмасы (1981) өчен бирелә.

1984



# ЕНИКЕЕВ
*Амирхан Нигметзянович (псевдоним — Амирхан Еники)*

**писатель,**
**народный писатель ТАССР (1989 г.)**

*17(2).2(3).1909, д. Новые Каргалы Белебеевского уезда Уфимской губернии, ныне с. Верхние Каргалы Благоварского района Республики Башкортостан – 16.2.2000, г. Казань*

До 1941 г. работал в гг. Казань, Баку, Маргилан (Узбекская ССР). В 1931–1933 гг. заочно учился в Казанском институте научной организации труда. Участник Великой Отечественной войны. После войны работал в редакции журнала «Совет әдәбияты» («Советская литература»), Комитете радиофикации при Совете Министров ТАССР, Казанском авиационном техникуме.
Для произведений писателя характерны исследование внутреннего мира человека, психологизм, любовная лирика, изображение взаимоотношения поколений отцов и детей. Писатель не склонен формулировать идею прямо, навязывать собственное отношение к персонажам, предоставляя делать выводы читателю. Премию получил в 1984 г. за книги «Повести и рассказы» (1982, на русском языке) и «Путник» («Юлчы», 1979, на татарском языке).

# ЕНИКИЕВ
*Әмирхан Нигъмәтҗан улы (псевдонимы — Әмирхан Еники)*

**язучы, ТАССРның халык язучысы (1989)**

*17(2).2(3).1909, Уфа губернасының Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылы, хәзер Башкортстан Республикасының Благовар районы Югары Каргалы авылы – 16.2.2000, Казан шәһәре*

1941 елга кадәр Казан, Баку, Маргелан (Үзбәкстан ССР) шәһәрләрендә эшли. 1931–1933 елларда, читтән торып, Казан хезмәтне фәнни оештыру институтында укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә, ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиофикация комитетында, Казан авиация техникумында эшли.
Язучының әсәрләренә кешенең эчке дөньясына үтеп керү, психологизм, мәхәббәт лирикасы, аталар һәм балалар мөнәсәбәтен тасвирлау хас. Әдип әйтергә теләгән фикерен турыдан-туры җиткерергә, персонажларга булган мөнәсәбәтен көчләп тагарга омтылмый, нәтиҗә ясауны укучының үзенә калдыра. Дәүләт бүләге 1984 елда «Юлчы» (1979) һәм рус телендә нәшер ителгән «Повести и рассказы» (1982, «Повестьлар һәм хикәяләр») китаплары өчен бирелә.



# МУЛЮКОВ
*Бату Гатауллович*

**композитор, педагог,**
**заслуженный деятель искусств**
**ТАССР (1977 г.), РСФСР (1981 г.)**

*17.4.1928, д. Байсун Узбекской ССР – 23.10.1999, г. Казань*

В 1957 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1970–1996 гг. преподавал в Казанском институте культуры.
Творчество композитора характеризуется широтой жанрового диапазона. Он тяготел к монументальным жанрам (опера, оратория, симфония), в которых обращался к актуальным проблемам истории и современности. Композитор известен также как мастер песенного жанра. Признание слушателей получила опера «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара за любовь», 1981 г.; либретто Г. Рахима) по повести М. Гафури «Кара йөзләр» («Черноликие»), поставленная на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля, за которую в 1984 г. композитор получил премию.

# МӨЛЕКОВ (МУЛЮКОВ)
*Бату Гатаулла улы*

**композитор, педагог,**
**ТАССРның (1977), РСФСРның (1981) атказанган**
**сәнгать эшлеклесе**

*17.4.1928, Үзбәкстан ССРның Байсун авылы –*
*23.10.1999, Казан шәһәре*

1957 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1970–1996 елларда Казан мәдәният институтында укыта.
Композиторның иҗаты жанр диапазонының киңлеге белән характерлана. Ул монументаль жанрларга (опера, оратория, симфония) омтыла, аларда тарихи чорның һәм хәзерге заманның актуаль проблемаларына мөрәҗәгать итә. Җыр жанры остасы буларак та билгеле. Дәүләт бүләге 1984 елда М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Г. Рәхим либреттосына язылган, М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы (1981) өчен бирелә.

1984



## РОДИОНОВ
*Григорий Васильевич (псевдоним — Гарай Рахим)*

**поэт**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1986 г.), заслуженный работник культуры РФ (2007 г.), народный писатель РТ (2011 г.)**

*15.7.1941, д. Федотовка Шугуровского района ТАССР, ныне Лениногорский район РТ – 6.9.2021, г. Казань*

В 1967 г. окончил Казанский университет, в 1981 г. — Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва). В 1967–1992 гг. работал в СМИ республики, Союзе писателей ТАССР и РСФСР. В 1992–2006 гг. в Комитете Госсовета РТ по культуре, науке, образованию и национальным вопросам.
Его поэзия отличалась своеобразием интонации, близкой к народно-песенным традициям, органически соединяющей лиризм, философскую глубину, публицистичность и тонкий юмор. Премию получил в 1984 г. за либретто (по повести М.Гафури «Кара йөзләр» («Черноликие») к опере Б. Мулюкова «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара за любовь», 1981 г.), поставленной на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

## РОДИОНОВ
*Григорий Васильевич (псевдонимы — Гәрәй Рәхим)*

**шагыйрь, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1986), РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (2007), ТРның халык язучысы (2011)**

*15.7.1941, ТАССРның Шөгер районы, хәзер ТРның Лениногорск районы Федотовка авылы – 6.9.2021, Казан шәһәре*

1967 елда — Казан университетын, 1981 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. 1967–1992 елларда республиканың массакүләм мәгълүмат чараларында, ТАССР һәм РСФСР Язучылар берлекләрендә эшли. 1992–2006 елларда — ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетында.
Поэзиясе халык иҗаты һәм җыр традицияләренә якын булган, лиризмны, фәлсәфи тирәнлекне, публицистика һәм нечкә юморны табигый рәвештә берләштергән интонация үзенчәлеге белән аерылып тора. Дәүләт бүләге 1984 елда композитор Б. Мөлековның М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсына (1981) либреттосы (М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча) өчен бирелә.

1984



# СУНГАТУЛЛИНА
*Зиля Даяновна*

**певица (лирическое сопрано), педагог, народная артистка ТАССР (1980 г.), Каракалпакской АССР (1980 г.), РФ (1995 г.), заслуженная артистка РСФСР (1986 г.)**

*30.7.1949, с. Верхние Киги Кигинского района Башкирской АССР*

После окончания в 1973 г. Казанской консерватории солистка Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля. Одновременно с 1983 г. преподает в Казанской консерватории, с 1998 г. заведующая кафедрой вокала, профессор.

Исполнила более 40 ведущих партий в операх русских, зарубежных и татарских композиторов. Обладает ярким, выразительным голосом широкого диапазона. Известна как исполнительница татарской народной песни. Премию получила в 1984 г. за партию Галимы в опере Б. Мулюкова «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара за любовь», 1981 г; либретто Г. Рахима по повести М. Гафури «Кара йөзләр» («Черноликие»), поставленной на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

---

# СӨНГАТУЛЛИНА
*Зилә Даян кызы*

**җырчы (лирик сопрано), педагог, ТАССРның (1980), Каракалпак АССРның (1980), РФнең (1995) халык артисты, РСФСРның атказанган артисты (1986)**

*30.7.1949, Башкортстан АССРның Кыйгы районы Югары Кыйгы авылы*

1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1973 елдан — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры солисты. Бер үк вакытта, 1983 елдан, Казан консерваториясендә укыта, 1998 елдан — вокал сәнгате кафедрасы мөдире, профессор.

Рус, чит ил һәм татар композиторлары операларында 40 тан артык төп партияләрне башкара. Киң диапазонлы көчле, тәэсирле тавышка, драматик талантка ия. Татар халык җырларын башкаручы буларак таныла. Дәүләт бүләге 1984 елда Б. Мөлековның М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсындагы (1981; М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Г. Рәхим либреттосы) Галимә партиясе өчен бирелә.



# БИГИЧЕВ
*Хайдар Аббясович*

**певец (драматический тенор),**
**народный артист ТАССР (1980 г.),**
**заслуженный артист РСФСР (1986 г.)**

*16.6.1949, д. Чембилей Краснооктябрьского района Горьковской области – 13.11.1998, г. Казань*

В 1979 г. окончил Казанскую консерваторию. С 1977 г. один из ведущих солистов Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.
Исполнял главные партии во всех постановках музыкально-сценических произведений татарских композиторов. Завоевал широкое признание благодаря своей музыкально-сценической деятельности и выступлениям на концертной эстраде, телевидении и радио. Тонкий интерпретатор произведений татарского народного песенного творчества. Премию получил в 1984 г. за партию Закира в опере Б. Мулюкова «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара за любовь», 1981 г. либретто Г. Рахима по повести М. Гафури «Кара йөзләр» («Черноликие»), поставленной на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# БИГИЧЕВ
*Хәйдәр Аббас улы*

**җырчы (драматик тенор),**
**ТАССРның халык артисты (1980),**
**РСФСРның атказанган артисты (1986)**

*16.6.1949, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Чүмбәли авылы – 13.11.1998, Казан шәһәре*

1979 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1977 елдан — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының әйдәп баручы солистларыннан берсе.
Иҗат эшчәнлеге дәверендә татар композиторларының опера сәхнәсендә куелган барлык әсәрләрендә төп партияләрне башкара. Музыка-сәхнә эшчәнлеге, концерт эстрадасындагы, телевидение һәм радиодагы чыгышлары аша киң танылу ала. Татар халык җыр сәнгате әсәрләренең хасиятен үтә сизгер тоемлавы белән аерылып тора. Дәүләт бүләге 1984 елда Б. Мөлековның М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсындагы (1981; М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Г. Рәхим либреттосы) Закир партиясе өчен бирелә.

1984



# ВАСИЛЬЕВ
*Владимир Михайлович*

**дирижер, педагог,**
**заслуженный деятель искусств РСФСР (1984 г.)**

*27.7.1935, г. Вологда*

В 1958 г. окончил Ленинградскую консерваторию. В 1958–1974 и с 1982 г. преподаватель Казанской консерватории. Одновременно в 1970–1975 гг. дирижер, в 1982–1993 гг. главный дирижер, с 1994 г. дирижер Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля. В 1975–1979 гг. главный дирижер Челябинского, в 1979–1982 гг. дирижер Одесского театров оперы и балета.
В репертуаре около 100 опер, оперетт, музыкальных комедий и симфоний, в том числе произведения татарских композиторов: оперы «Джалиль» и «Алтынчеч» Н. Жиганова, балеты «Шурале» Ф. Яруллина и «Сказание о Йусуфе» Л. Любовского. Премию получил в 1984 г. как дирижер оперы Б. Мулюкова «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара за любовь», 1981 г.), поставленной на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

---

# ВАСИЛЬЕВ
*Владимир Михайлович*

**дирижер, педагог,**
**РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984)**

*27.7.1935, Вологда шәһәре*

1958 елда Ленинград консерваториясен тәмамлый. 1958–1974 елларда һәм 1982 елдан Казан консерваториясендә укыта. Бер үк вакытта, 1970–1975 елларда, М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры дирижеры, 1982–1993 елларда — баш дирижер, 1994 елдан — дирижер. 1975–1979 елларда — Чиләбе, 1979–1982 елларда — Одесса опера һәм балет театрлары баш дирижеры.
Репертуарын 100 гә якын опера, оперетта, музыкаль комедия һәм симфония, шул исәптән татар композиторлары әсәрләре — Н. Җиһановның «Җәлил» һәм «Алтынчәч» опералары, Ф. Яруллинның «Шүрәле» һәм Л. Любовскийның «Йосыф турында риваять» балетлары тәшкил итә. Дәүләт бүләге 1984 елда Б. Мөлековның М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы (1981; М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Г. Рәхим либреттосы) дирижеры буларак бирелә.

1985



# АРСЛАНОВ
## *Нури Газизович*

**поэт, переводчик**

*19.9.1912, г. Петропавловск,*
*ныне Республика Казахстан –*
*12.4.1991, г. Казань*

В 1931 г. окончил Казанский техникум искусств. В 1931–1934 гг. работал преподавателем татарской литературы и рисования, художником-оформителем в городах Средней Азии и Дальнего Востока. Участник советско-финской и Великой Отечественной войн. После войны работал художником в Татарском книжном издательстве и газете «Социалистик Татарстан» («Социалистический Татарстан»), в 1964–1972 гг. заведующий отделом поэзии журнала «Казан утлары» («Огни Казани»).
В стихах и поэмах часто обращался к сюжетам и мотивам сказок, народной мифологии. В зрелом творчестве поэта преобладает философская лирика, обогащенная традиционными формами классической восточной поэзии, в том числе татарской. Премию получил в 1985 г. за сборник лирической поэзии «Иделем — илем» («Волга моя — родная сторона», 1982).

# АРСЛАНОВ
## *Нури Газиз улы*

**шагыйрь, тәрҗемәче**

*19.9.1912, хәзерге Казакъстан Республикасының*
*Петропавловск шәһәре –*
*12.4.1991, Казан шәһәре*

1931 елда Казан сынлы сәнгать техникумын тәмамлый. 1931–1934 елларда Урта Азия һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә татар әдәбияты һәм рәсем укытучысы, рәссам-бизәүче булып эшли. Совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Сугыштан соң — Татарстан китап нәшриятында һәм «Социалистик Татарстан» газетасында рәссам. 1964–1972 елларда — «Казан утлары» журналының шигърият бүлеге мөдире.
Шигырь һәм поэмаларында еш кына әкият сюжетларына, халык мифологиясе мотивларына мөрәҗәгать итә. Шагыйрьнең җитлеккән чор иҗатында классик көнчыгыш, шул исәптән татар поэзиясенең традицион формалары белән баетылган фәлсәфи лирика өстенлек итә. Дәүләт бүләге 1985 елда лирик шигърият җыентыкларының берсе — «Иделем — илем» (1982) китабы өчен бирелә.

1985



## НИГМЕДЗЯНОВ
*Махмут Нигмедзянович*

**музыковед, педагог,
кандидат искусствоведения (1972 г.),
заслуженный деятель искусств ТАССР (1979 г.)**

*10.5.1930, д. Большой Арташ Мамадышского кантона ТАССР, ныне Мамадышский район РТ – 4.8.2020, г. Казань*

В 1958 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1960–1967, 1974–1984 гг. в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, в 1967–1973 гг. художественный руководитель Татарской государственной филармонии. В 1984–2003 гг. преподавал в Казанском педагогическом университете.
Собиратель и исследователь татарского музыкального фольклора, опубликовал сборники татарских и русских народных песен. Труды по вопросам татарской музыкальной культуры, теории и истории музыки, музыкальной психологии. Премию получил в 1985 г. за труды «Татар халык җырлары» («Татарские народные песни», Казань, 1976), «Идел буе татарларының халык җырлары» («Народные песни волжских татар», М., 1982).

## НИГЪМӘТҖАНОВ
*Мәхмүт Нигъмәтҗан улы*

**музыка белгече, педагог,
сәнгать фәннәре кандидаты (1972),
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1979)**

*10.5.1930, ТАССРның Мамадыш кантоны, хәзер ТРның Мамадыш районы Олы Арташ авылы – 4.8.2020, Казан шәһәре*

1958 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1960–1967, 1974–1984 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1967–1973 елларда — Г. Тукай исемендәге Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе. 1984–2003 елларда Казан дәүләт педагогика университетында укыта.
Татар музыка фольклорын туплаучы һәм өйрәнүче, татар һәм рус халык җырлары җыентыкларын бастырып чыгара. Татар музыка мәдәнияте, музыка теориясе һәм тарихы, музыка психологиясе мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр авторы. Дәүләт бүләге 1985 елда «Татар халык җырлары» (Казан, 1976), «Идел буе татарларының халык җырлары» (М., 1982) хезмәтләре өчен бирелә.

1986



# КАМАЛОВ
*Хисамутдин Нурутдинович (псевдоним — Хисам Камал)*

**писатель,**
**народный писатель РТ (2001 г.)**

*14.4.1926, с. Кама-Исмагилово Альметьевского района ТАССР – 2.11.2016, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. В 1950 г. окончил Бугульминское педагогическое училище, в 1954 г. — Казанский педагогический институт. В 1954–1966 гг. редактор в Татарском книжном издательстве. С 1967 г. профессиональный писатель.
Основные темы творчества — Великая Отечественная война, ее трагические последствия, социально-экономические перемены, происходящие в родном крае, философские раздумья о надежде, счастье и любви. Премию получил в 1986 г. за романы «Һәркемнең гомере бер генә» («У каждого жизнь — одна», 1975; русский перевод 1983), «Безне өйдә көтәләр» («Нас ждут дома», 1986).

# КАМАЛОВ
*Хисаметдин Нуретдин улы (псевдонимы — Хисам Камал)*

**язучы,**
**ТРның халык язучысы (2001)**

*14.4.1926, ТАССРның Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылы – 2.11.2016, Казан шәһәре*

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 елда — Бөгелмә педагогия училищесын, 1954 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. 1954–1966 елларда — Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. 1967 елдан — профессиональ язучы.
Иҗатының төп темалары — Бөек Ватан сугышы, аның фаҗигале нәтиҗәләре, туган яктагы социаль-икътисади үзгәрешләр, өмет, бәхет һәм мәхәббәт турындагы фәлсәфи уйланулар. Дәүләт бүләге 1986 елда, «Һәркемнең гомере бер генә» (1975; русчага тәрҗемәсе — «У каждого жизнь — одна»,1983), «Безне өйдә көтәләр» (1986) романнары өчен бирелә.

1986



## КУДЕЛЬКИН
*Виктор Иванович*

**живописец, педагог,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1960 г.),**
**народный художник ТАССР (1971 г.),**
**заслуженный художник РСФСР (1978 г.)**

*9.1.1911, г. Алатырь Симбирской губернии,*
*ныне Чувашская Республика – 14.6.1995, г. Казань*

В 1938 г. окончил Чебоксарское художественное училище. С 1940 г. в Казани. Участник Великой Отечественной войны. В 1946–1975 гг. преподавал в Казанском художественном училище.
Как живописец работал преимущественно в жанре портрета. Им создана обширная галерея портретов современников — тружеников села, представителей рабочего класса и интеллигенции. Премию получил в 1986 г. за серию картин, посвященных передовикам производства, труженикам села и деятелям культуры Татарстана.


## КУДЕЛЬКИН
*Виктор Иванович*

**нәкышьче, педагог,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1960),**
**ТАССРның халык рәссамы (1971),**
**РСФСРның атказанган рәссамы (1978)**

*9.1.1911, Сембер губернасының, хәзер Чуаш*
*Республикасының Алатырь шәһәре – 14.6.1995, Казан шәһәре*

1938 елда Чабаксар сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. 1940 елдан — Казанда. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–1975 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укыта.
Нәкышьче буларак күбесенчә портрет жанрында эшли. Ул замандашларының — авыл хезмәтчәннәре, эшче сыйныф вәкилләре һәм зыялыларның киң галереясын тудыра. Дәүләт бүләге 1986 елда хезмәт алдынгыларына, авыл хезмәтчәннәренә һәм Татарстанның мәдәният эшлеклеләренә багышланган картиналар сериясе өчен бирелә.

1987



# ЗАРИПОВ
*Марсель Харисович*

**писатель, журналист,**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1981 г.),**
**РСФСР (1987 г.)**

*23.10.1931, д. Янурусово Сармановского района ТАССР – 7.1.2017, г. Казань*

В 1966 г. окончил Казанский университет. В 1962–1966 гг. собственный корреспондент газеты «Советская Татария», в 1966–1991 гг. — газеты «Советская Россия». Один из основателей информационного агентства «Татар-информ»: заместитель генерального директора, в 1992–1998 гг. политический обозреватель. Стоял у истоков татарской газеты «Татар иле» («Татарские края»).
Издал более 20 книг (проза, публицистика, переводы). Премию получил в 1987 г. за документальную повесть «Звёздный час Нижнекамска» (1981).

# ЗАРИПОВ
*Марсель Харис улы*

**язучы, журналист,**
**ТАССРның (1981), РСФСРның (1987) атказанган мәдәният хезмәткәре**

*23.10.1931, ТАССРның Сарман районы Янурыс авылы – 7.1.2017, Казан шәһәре*

1966 елда Казан университетын тәмамлый. 1962–1966 елларда — «Советская Татария», 1966–1991 елларда — «Советская Россия» газеталары үз хәбәрчесе. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына нигез салучыларның берсе: генераль директор урынбасары, 1992–1998 елларда — сәяси күзәтче. «Татар иле» («Татарские края») газетасын нигезләүдә катнаша.
20 дән артык проза, публицистика, тәрҗемә китаплары авторы. Дәүләт бүләге 1987 елда «Звёздный час Нижнекамска» документаль повесте (1981) өчен бирелә.



# ХАЗИАХМЕТОВ
## *Тавиль Гиниатович*

**художник-график,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1978 г.),**
**народный художник ТАССР (1984 г.)**

*3.2.1936, д. Юсуф-Алан Сабинского района ТАССР – 25.5.2007, г. Казань*

В 1957 г. окончил Казанское художественное училище, в 1963 г. — Ленинградский институт живописи, скульптуры и архитектуры им. И. Е. Репина. В 1963–1967 гг. художник в газете «Яшь ленинчы» («Молодой ленинец»), в 1968–2005 гг. — в журнале «Ялкын» («Пламя»). С 1961 г. сотрудничал Татарским книжным издательством, был художником-оформителем более 100 книг. Также создавал эскизы к театральным костюмам для татарских постановок. В 1981–1984 гг. преподавал в Казанском художественном училище. В 1993–1999 гг. художник издательства «Раннур». Автор Государственного флага РТ (1991 г.). Мозаика по его произведению «Зимний вечер» украшает одну из станций Казанского метрополитена. Произведения художника отличаются декоративностью образов и орнаментальной стилизацией. Премию получил в 1987 г. за художественно-графическое оформление книг, изданных в 1981–1985 гг.

# ХАҖИӘХМӘТОВ
## *Тавил Гыйният улы*

**рәссам-график,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1978),**
**ТАССРның халык рәссамы (1984)**

*3.2.1936, ТАССРның Саба районы Йосыф-Алан авылы – 25.5.2007, Казан шәһәре*

1957 елда — Казан сынлы сәнгать училищесын, 1963 елда И. Е.Репин исемендәге Ленинград сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтын тәмамлый. 1963–1967 елларда — «Яшь ленинчы» газетасында, 1968–2005 елларда «Ялкын» журналында эшли. 1961 елдан Татарстан китап нәшрияты белән хезмәттәшлек итә, 100 дән артык китапның бизәлеш рәссамы була. Шулай ук спектакльләргә театр костюмнары эскизларын эшли. 1981–1984 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укыта. 1993–1999 елларда — «Раннур» нәшрияты рәссамы. ТР Дәүләт флагы авторы (1991). Аның «Кышкы кич» әсәре буенча эшләнгән мозаика Казан метрополитенының бер станциясен бизи.

Рәссамның әсәрләре образларның гадилеге, орнаменталь стилистика һәм төсләр ачыклыгы белән аерылып тора. Дәүләт бүләге 1987 елда 1981–1985 елларда нәшер ителгән китапларның сәнгати-график бизәлеше өчен бирелә.

1988



# ХАСАНОВ
## *Махмут Максудович*

**писатель,**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1977 г.)**

*21.12.1927, с. Верхние Кибя-Кози Арского кантона ТАССР, ныне Арский район РТ – 14.9.1990, г. Казань*

В 1949 г. окончил Всесоюзный институт театрального искусства (г. Москва), в 1957 г. — Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва). В 1949–1951 гг. актер Театра юного зрителя, Татарского академического театра им. Г. Камала, в 1952–1955 гг. корреспондент в Комитете радиофикации Совета Министров ТАССР. В 1959–1980 гг. работал в г. Азнакаеве, в 1967–1980 гг. заведующий отделом промышленности газеты «Маяк».
Автор сборников рассказов и повестей, а также романов о жизни и труде сельчан, тружеников производства, нефтяников. Герои произведений писателя — сильные духом, мужественные и верные долгу люди. Автор сборников рассказов и повестей, а также романов о жизни и труде нефтяников. Особое место в его творчестве занимает роман «Язгы аҗаган» («Весенняя зарница», 1987), за который в 1988 г. он получил премию.

# ХӘСӘНОВ
## *Мәхмүт Максуд улы*

**язучы,**
**ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1977)**

*21.12.1927, ТАССРның Арча кантоны, хәзер ТРның Арча районы Югары Кибәхуҗа авылы – 14.9.1990, Казан шәһәре*

1949 елда — Бөтенсоюз театр сәнгате институтын (Мәскәү шәһәре), 1957 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү шәһәре) тәмамлый. 1949–1951 елларда — Яшь тамашачылар театры, Г. Камал исемендәге Татар академия театры актеры, 1952–1955 елларда ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиофикация комитетында хәбәрче. 1959–1980 елларда — Азнакай шәһәрендә, 1967–1980 елларда — «Маяк» газетасының сәнәгать бүлеге мөдире.
Авыл хезмәтчәннәре, эшчеләр, нефтьчеләргә багышланган хикәя-повестьлар җыентыклары, романнар авторы. Әсәрләренең геройлары — көчле рухлы, кыю йөрәкле, максатларына тугрылыклы кешеләр. Дәүләт бүләге 1988 елда иҗатында аерым урын алып торган «Язгы аҗаган» (1987) романы өчен бирелә.

1988



# АХМЕТОВ
*Фасиль*
*Ахметгалиевич*

**композитор, заслуженный деятель искусств ТАССР (1977 г.), РСФСР (1981 г.), народный артист РСФСР (1992 г.), РТ (1995 г.)**

*23.5.1935, д. Салтык-Ерыкла Кукморского района ТАССР – 6.9.1998, г. Казань*

В 1962 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1957–1961, 1969–1975 гг. преподавал в Казанском музыкальном училище, Казанской консерватории. В 1962–1964 гг. работал в Комитете радиовещания и телевидения при Совете Министров ТАССР и Татарском книжном издательстве.

Внес значительный вклад в развитие татарского симфонизма. Наиболее ярко мелодический дар композитора проявился в лирических песнях на любовную, интимно-романсную тематику. Премию получил в 1988 г. за сочинения последних лет, симфонию и сборник песен «Мин гармун булыр идем...» («Стать бы мне гармонью звонкой», Казань, 1985).

---

# ӘХМӘТОВ
*Фасил*
*Әхмәтгали улы*

**композитор, ТАССРның (1977), РСФСРның (1981) атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның (1992), ТРның (1995) халык артисты**

*23.5.1935, ТАССРның Кукмара районы Салтык-Ерыклы авылы – 6.9.1998, Казан шәһәре*

1962 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1957–1961, 1969–1975 елларда — Казан музыка училищесында, Казан консерваториясендә укыта. 1962–1964 елларда ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетында һәм Татарстан китап нәшриятында эшли.

Татар симфонизмын үстерүгә зур өлеш кертә. Композиторның моң байлыгы мәхәббәт хисләре белән сугарылган романсларында, лирик җырларында аеруча ачык чагыла. Дәүләт бүләге 1988 елда шуннан алдагы елларда иҗат ителгән әсәрләре, симфониясе һәм «Мин гармун булыр идем...» (Казан, 1985) җырлар җыентыгы өчен бирелә.

1989



# НАДИРОВ
*Ильбарис Нурисламович*

**фольклорист,**
**кандидат филологических наук (1959 г.),**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1985 г.)**

*1925, д. Новое Надырово Бугульминского кантона ТАССР, ныне Альметьевский район РТ – 20.8.2009, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. В 1953 г. окончил Казанский университет. С 1956 г. в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР: с 1965 г. заместитель директора, в 1972–1991 гг. заведующий отделом народного творчества.
Исследования посвящены татарским народным песням и баитам. Сборники «Кыска җырлар (дүртьюллыклар)» («Короткие песни (четверостишия)», 1976), «Йола һәм уен җырлары» («Обрядовые и игровые песни», 1980), «Тарихи һәм лирик җырлар» («Исторические и лирические песни», 1988) вошли в золотой фонд татарской фольклористики. Премию получил в 1989 г. как научный руководитель сборника татарского фольклора «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», в 13 т., 1972–1988, 1993).

# НАДИРОВ
*Илбарис Нурислам улы*

**фольклорчы,**
**филология фәннәре кандидаты (1959),**
**ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985)**

*1925, ТАССРның Бөгелмә кантоны, хәзер ТРның Әлмәт районы Яңа Нәдер авылы – 20.8.2009, Казан шәһәре*

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 елда Казан университетын тәмамлый. 1956 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында: 1965 елдан — директор урынбасары, 1972–1991 елларда — халык иҗаты бүлеге мөдире.
Тикшеренүләре татар халык җырларына һәм бәетләренә багышланган. «Кыска җырлар (дүртьюллыклар)» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988) җыентыклары татар фольклористикасының алтын фондына керә. Дәүләт бүләге 1989 елда «Татар халык иҗаты» (13 томда, 1972–1988, 1993) татар фольклоры җыентыгының фәнни җитәкчесе буларак бирелә.

1989



# ЯРМУХАМЕТОВ
## *Хамит Хуснутдинович*

**фольклорист,**
**доктор филологических наук (1972 г.),**
**заслуженный деятель науки ТАССР (1964 г.)**

*5.5.1904, д. Казарово Тюменского уезда Тюменской губернии – 30.10.1981, г. Казань*

В 1934 г. окончил Татарский педагогический институт. В 1939–1971 гг. в Институте языка, литературы и истории КФАН СССР: директор (1942–1944 гг.), заведующий сектором народного творчества (с 1961 г.).

В 1940–1950-е гг. руководил экспедициями по сбору татарского фольклора. Подготовил к изданию сборники «Халык иҗаты» («Татарское творчество», 1938), «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», 1951), «Татар халык әкиятләре» («Татарские народные сказки», т. 1–2, 1946–1956) и др. Начал подготовку издания сборника татарского фольклора «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», в 13 т., 1972–1988, 1993), за который в 1989 г. получил премию (посмертно).

---

# ЯРМӨХӘММӘТОВ
## *Хәмит Хөснетдин улы (Хәмит Ярми)*

**фольклорчы,**
**филология фәннәре докторы (1972),**
**ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1964)**

*5.5.1904, Төмән губернасының Төмән өязе Кырынкүл авылы – 30.10.1981, Казан шәһәре*

1934 елда Татар педагогия институтын тәмамлый. 1939–1971 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында: директор (1942–1944), халык иҗаты секторы мөдире (1961 елдан).

1940–1950 елларда татар фольклорын туплау буенча экспедицияләрне җитәкли. «Халык иҗаты» (1938), «Татар халык иҗаты» (1951), «Татар халык әкиятләре» (1–2 нче т., 1946–1956) һәм башка җыентыкларны басмага әзерли. Дәүләт бүләге 1989 елда, «Татар халык иҗаты» (13 томда, 1972–1988, 1993) татар фольклоры җыентыгын төзүчеләренең берсе буларак бирелә (вафатыннан соң).

1989



# МАХМУТОВ
*Хузиахмет*
*Шагиахметович*

**фольклорист,**
**доктор филологических наук (1996 г.),**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1983 г.),**
**РФ (1993 г.)**

*15.2.1933, д. Нижняя Ошма Мамадышского района ТАССР – 18.2.2021, г. Казань*

В 1958 г. окончил Казанский университет. В 1960–1966 гг. работал в редакциях газет г. Буинска. С 1966 г. в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР.
Исследования посвящены афористическим жанрам татарского устного народного творчества. Автор книг о календарных обрядах и праздниках татарского народа, по истории татарской фольклористики. Разработал классификацию жанров татарского фольклора, дал их научную характеристику. Премию получил в 1989 г. как один из составителей сборника татарского фольклора «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», в 13 т., 1972–1988, 1993 г.).

# МӘХМҮТОВ
*Хуҗиәхмәт*
*Шаһиәхмәт улы*

**фольклорчы,**
**филология фәннәре докторы (1996),**
**ТАССРның (1983), РФнең (1993) атказанган мәдәният хезмәткәре**

*15.2.1933, ТАССРның Мамадыш районы Түбән Ушма авылы – 18.2.2021, Казан шәһәре*

1958 елда Казан университетын тәмамлый. 1960–1966 елларда Буа шәһәре газеталары редакцияләрендә эшли. 1966 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында.
Тикшеренүләре татар халык авыз иҗатының афористик жанрларына багышланган. Татар халкының календарь йолалары һәм бәйрәмнәре турында китаплар, татар фольклористикасы тарихына караган хезмәтләр авторы. Татар фольклоры жанрлары классификациясен эшли, аларның фәнни тасвирламасын бирә. Дәүләт бүләге 1989 елда «Татар халык иҗаты» (13 томда, 1972–1988, 1993) татар фольклоры җыентыгы төзүчеләренең берсе буларак бирелә.

1989



# АХМЕТОВА-УРМАНЧЕ
*Флора Вагаповна*

**фольклорист,**
**кандидат филологических наук (1968 г.),**
**заслуженный работник культуры РТ (1997 г.)**

*23.5.1935, д. Чебурга Тобольского района Тюменской области – 16.10.2007, г. Казань*

В 1959 г. окончила Тюменский педагогический институт. В 1964–2007 гг. в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР.
Основные исследования посвящены изучению жанров татарского устного народного творчества, а также фольклора сибирских татар. Работала над систематизацией и публикацией татарских дастанов и баитов. Премию получила в 1989 г. как один из составителей сборника татарского фольклора «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», в 13 т., 1972–1988, 1993).

# ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ
*Флора Вәһап кызы*

**фольклорчы,**
**филология фәннәре кандидаты (1968),**
**ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1997)**

*23.5.1935, Төмән өлкәсенең Тобол районы Күкрәнде авылы – 16.10.2007, Казан шәһәре*

1959 елда Төмән педагогия институтын тәмамлый. 1964–2007 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында.
Төп хезмәтләре татар халык авыз иҗаты жанрларын, шулай ук Себер татарлары фольклорын өйрәнүгә багышлана, ул шулай ук татар дастаннарын һәм бәетләрен системалаштыруда һәм басмага әзерләүдә катнаша. Дәүләт бүләге 1989 елда «Татар халык иҗаты» (13 томда, 1972–1988, 1993) татар фольклоры җыентыгын төзүчеләренең берсе буларак бирелә.

1989



# ЗАМАЛЕТДИНОВ
*Ленар Шайхиевич*

**фольклорист,**
**кандидат филологических наук (1993 г.),**
**заслуженный работник культуры РТ (1995 г.)**

*17.12.1935, с. Средние Лащи Буинского района ТАССР – 15.12.2023, г. Казань*

В 1965 г. окончил Казанский университет. В 1964–1970 гг. редактор музыкальных радиопередач Комитета по радиовещанию и телевидению при Совете Министров ТАССР, с 1970 г. в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР.
Основные труды по исследованию татарских народных сказок, подготовил и выпустил 16 сборников татарских сказок. Премию получил в 1989 г. как один из составителей сборника татарского фольклора «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», в 13 т., 1972–1988, 1993).

---

# ҖАМАЛЕТДИНОВ
*Ленар Шәйхи улы*

**фольклорчы,**
**филология фәннәре кандидаты (1993),**
**ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1995)**

*17.12.1935, ТАССРның Буа районы Урта Лашчы авылы – 15.12.2023, Казан шәһәре*

1965 елда Казан университетын тәмамлый. 1964–1970 елларда ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетының музыкаль тапшырулар редакциясе мөхәррире, 1970 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында.
Төп хезмәтләре татар халык әкиятләрен тикшерүгә багышлана, татар әкиятләренең 16 җыентыгын әзерләп басмага әзерли. Дәүләт бүләге 1989 елда «Татар халык иҗаты» (13 томда, 1972–1988, 1993) татар фольклоры җыентыгын төзүчеләренең берсе буларак бирелә.



# ВАЛИУЛЛИН
*Хуснулла Валиуллович*

**композитор,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1966 г.),
РСФСР (1974 г.)**

*15(28).2.1914, с. Богатые Сабы Мамадышского уезда Казанской губернии, ныне Сабинский район РТ – 24.9.1993, г. Казань*

В 1940 г. окончил Казанское музыкальное училище, в 1950 г. — Казанскую консерваторию. Участник Великой Отечественной войны. В 1950–1951 гг. преподаватель Казанского музыкального училища, в 1968–1973 и 1978–1981 гг. музыкальный редактор Татарского книжного издательства.
Центральное место в творчестве композитора занимает оперный жанр. Лирико-психологическая опера «Самат» (1957 г., 2-я редакция 1970 г.) на либретто Х. Вахита стала его лучшим произведением для оперной сцены. Значителен его вклад в развитие татарской вокальной музыки, написал более 100 песен и романсов. Премию получил в 1989 г. за оперу «Самат» и сборник песен последних лет «Год за годом» (Казань, 1984).

# ВӘЛИУЛЛИН
*Хөснулла Вәлиулла улы (псевдонимы — Хөснул Вәлиуллин)*

**композитор,
ТАССРның (1966), РСФСРның (1974) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*15(28).2.1914, Казан губернасының Мамадыш өязе, хәзер Саба районы Байлар Сабасы авылы – 24.9.1993, Казан шәһәре*

1940 елда — Казан музыка училищесын, 1950 елда Казан консерваториясен тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–1951 елларда — Казан музыка училищесы укытучысы, 1968–1973 һәм 1978–1981 елларда — Татарстан китап нәшриятының музыкаль әдәбият редакциясе мөхәррире.
Композитор иҗатында үзәк урынны опера жанры алып тора. Х. Вахит либреттосына язылган лирик-психологик «Самат» операсы (1957, 2 нче редакциясе — 1970) аның опера сәхнәсе өчен иң яхшы әсәрен тәшкил итә. Татар вокаль музыкасын үстерүгә керткән өлеше шулай ук зур, 100 дән артык җыр һәм романс авторы. Дәүләт бүләге 1989 елда «Самат» операсы һәм «Еллар үтә» (Казан, 1984) җырлар һәм романслар җыентыгы өчен бирелә.



## САЛАХОВ
*Ибрагим Низамович*

писатель, драматург,
заслуженный работник культуры РТ (1992 г.)

*30.8.1911, г. Кокчетав, ныне Республика Казахстан – 7.7.1998, с. Красный Яр Акмолинской области Республики Казахстан*


После окончания Казанского педагогического техникума в 1931 г. работал литературным сотрудником в редакциях газет «Яшь ленинчы» («Молодой ленинец»), «Кызыл яшьләр» («Красная молодежь»), журнала «Пионер». В 1935–1937 гг. учился в Казанском педагогическом институте. В 1937 г. необоснованно репрессирован, осужден на 10 лет лагерей, реабилитирован в 1956 г.
Лауреат премии 1990 г. за автобиографический роман-хронику «Колыма хикәяләре» («Черная Колыма», 1989), одно из первых произведений в татарской литературе на тему ГУЛАГа.

## САЛАХОВ
*Ибраһим Низам улы*

язучы, драматург,
ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992)

*30.8.1911, хәзерге Казакъстан Республикасының Күкчәтау шәһәре – 7.7.1998, Казакъстан Республикасының Акмола өлкәсе Кызыл Яр авылы*

Казан педагогия техникумын тәмамлаганнан соң, 1931 елда «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» газеталары, «Пионер» журналы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1935–1937 елларда Казан педагогия институтында укый. 1937 елда гаепсезгә репрессияләнә, 10 елга лагерьларга хөкем ителә, 1956 елда аклана.
Дәүләт бүләге 1990 елда татар әдәбиятында ГУЛАГ темасын яктырткан беренче әсәрләрнең берсе — «Колыма хикәяләре» (1989) автобиографик роман-хроникасы өчен бирелә.



# МАГДЕЕВ
*Мухаммет Сунгатович*

**писатель, литературовед, кандидат филологических наук (1964 г.), заслуженный работник культуры РСФСР (1983 г.), народный писатель РТ (1993 г.)**

*1.12.1930, с. Губурчак Арского района ТАССР – 12.6.1995, г. Казань*

В 1959 г. окончил Казанский педагогический институт. В 1954–1959 гг. преподавал татарскую литературу и историю в средних школах Арского района. В 1963–1991 гг. работал на кафедре татарской литературы Казанского университета.

Премию получил в 1990 г. за повести «Кеше китә — җыры кала» («Человек уходит — песня остается», 1978), «Бәхилләшү» («Прощание», 1978) и «Торналар төшкән җирдә» («Там, где гнездятся журавли», 1988), в которых отразилось прошлое и настоящее татарских деревень.

# МӘҺДИЕВ
*Мөхәммәт Сөнгат улы*

**язучы, әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты (1964), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1983), ТРның халык язучысы (1993)**

*1.12.1930, ТАССРның Арча районы Гөберчәк авылы – 12.6.1995, Казан шәһәре*

1959 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. 1954–1959 елларда Арча районы урта мәктәпләрендә татар әдәбияты һәм тарих укыта. 1963–1991 елларда Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында эшли.

Язучының иҗаты туган ягы һәм аның тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Дәүләт бүләге 1990 елда «Кеше китә — җыры кала» (1978), «Торналар төшкән җирдә» (1978) һәм «Бәхилләшү» (1988) повестьлары өчен бирелә. Әлеге әсәрләрдә, әхлакый нигезләр, тормыш кагыйдәләре, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр үзәккә алынып, татар авылларының үткәне һәм бүгенгесе ачык чагылыш таба.



# САДЫКОВА
*Сара Гарифовна*

**актриса, певица, композитор,**
**народная артистка ТАССР (1977 г.),**
**заслуженный деятель искусств РСФСР (1984 г.)**

*1.11.1906, г. Казань – 7.6.1986, там же*

В 1921 г. училась в Казанском педагогическом техникуме, в 1922–1928 гг. — в музыкальном техникуме при Московской консерватории. В 1930–1934 гг. работала в Татарском академическом театре. В 1934–1938 гг. училась в Татарской оперной студии при Московской консерватории. В 1938–1948 гг. солистка Татарского театра оперы и балета.
Широкую популярность ей принесли музыкальные комедии «Мәхәббәт җыры» («Песня любви», 1971 г.) и «Кияүләр» («Женихи», 1972 г.), созданные в соавторстве с Р. Губайдуллиным. Ее творческое наследие включает свыше 300 песен и инструментальных произведений. Лауреат премии 1990 г. (посмертно) за значительный вклад в развитие татарской музыки и создание обширного наследия, ставшего неотъемлемой частью культурного достояния республики.

---

# САДЫЙКОВА
*Сара Гариф кызы*

**актриса, җырчы, композитор,**
**ТАССРның халык артисты (1977),**
**РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984)**

*1.11.1906, Казан шәһәре – 7.6.1986, шунда ук*

1921 елда Казан педагогия техникумында, 1922–1928 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка техникумында укый. 1930–1934 елларда Татар академия театрында эшли. 1934–1938 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә белем ала. 1938–1948 елларда — Татар опера һәм балет театры солисты.
Р. Гобәйдуллин белән автордашлыкта иҗат ителгән «Мәхәббәт җыры» (1971) һәм «Кияүләр» (1972) музыкаль комедияләре аңа зур популярлык китерә. Аның иҗат мирасы 300 дән артык җыр һәм инструменталь әсәрне үз эченә ала. Дәүләт бүләге 1990 елда (вафатыннан соң) татар музыкасын үстерүгә һәм республика мәдәни казанышының аерылгысыз өлешенә әверелгән гаять зур мирас булдыруга керткән өлеше өчен бирелә.



# ЗАЙНАШЕВА
## *Гульшат Хисамовна*

поэтесса,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1988 г.)

*13.1.1928, д. Старое Клянчино Челнинского кантона ТАССР, ныне Тукаевский район РТ – 1.4.2005, г. Казань*

В 1949 г. окончила Казанский педагогический институт. В 1949–1952 гг. редактор в комитете радиофикации при Совете Министров ТАССР, в 1952–1963 гг. редактор, в 1973–1983 гг. инспектор по кадрам Татарского книжного издательства. Начала печататься в 1950 г. Первый сборник стихов «Тыңларсыңмы җырларымны» («Будешь ли слушать песню мою») вышел в 1958 г.
Премию получила в 1991 г. за сборник «Илле җыр» («Пятьдесят песен», 1988), в который вошли песни, созданные в соавторстве с композиторами М. Музафаровым, А. Ключарёвым, Р. Яхиным, С. Садыковой, З. Гибадуллиным, Б. Гайсиным.

# ЗӘЙНАШЕВА
## *Гөлшат Хисам кызы*

шагыйрә,
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988)

*13.1.1928, ТАССРның Чаллы кантоны, хәзер ТРның Тукай районы Иске Келәнче авылы – 1.4.2005, Казан*

1949 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. 1949–1952 елларда — ТАССР Министрлар Советы каршындагы радиокомитетта мөхәррир, 1952–1963 елларда — Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1973–1983 елларда — кадрлар бүлеге инспекторы. Әсәрләре 1950 еллар ахырында басыла башлый. «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1958 елда дөнья күрә.
Дәүләт бүләге 1991 елда композиторлар М. Мозаффаров, А. Ключарев, Р. Яхин, С. Садыйкова, З. Гыйбадуллин, Б. Гайсин белән берлектә иҗат ителгән «Илле җыр» (1988) җырлар җыентыгы өчен бирелә.



# КАРИМУЛЛИН
*Абрар Гибадуллович*

**филолог, книговед, библиограф, публицист, доктор филологических наук (1978), действительный член АН РТ (1992 г.), заслуженный деятель науки ТССР (1990 г.)**

*29.5.1925, д. Чабья-Чурчи Мамадышского района ТАССР – 19.9.2000, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. После окончания в 1941 г. средней школы работал в колхозе, бухгалтером в Ныртинской больнице, учителем в начальной школе. После окончания в 1953 г. Казанского университета трудился там же в Научной библиотеке. В 1964–1992 гг. в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, одновременно в 1991–1992 гг. в Национальной библиотеке РТ.
Премию получил в 1991 г. за книги «У истоков татарской книги», «Татарская книга пореформенной России» и «Татарская книга начала XX века».

# КӘРИМУЛЛИН
*Әбрар Гыйбадулла улы*

**филолог, китап белеме галиме, библиограф, публицист, филология фәннәре докторы (1978), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы (1992), ТССРның атказанган фән эшлеклесе (1990)**

*29.5.1925, ТАССРның Мамадыш кантоны, хәзер Саба районы Чәбия-Чурчи авылы – 19.9.2000, Казан*

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1941 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, башта колхозда, аннары Нырты авылы хастаханәсендә хисапчы, башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. 1953 елда Казан университетын тәмамлый, шунда ук фәнни китапханәдә хезмәт куя. 1964–1992 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, бер үк вакытта, 1991–1992 елларда, ТР Милли китапханәсендә эшли.
Дәүләт бүләге 1991 елда «Татар китабының чишмә башы» («У истоков татарской книги»), «Реформадан соңгы Россиядә татар китабы» («Татарская книга пореформенной России») һәм «XX гасыр башы татар китабы» («Татарская книга начала XX века») китаплары өчен бирелә.



## МОНАСЫПОВ
*Алмаз Закирович*

**композитор, дирижер, педагог,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1969 г.), РСФСР (1987 г.), народный артист РТ (2000 г.)**

*11.7.1925, г. Казань – 24.7.2008, г. Москва*

В 1950 г. окончил Казанскую консерваторию, в 1964 г. — ассистентуру-стажировку по симфоническому дирижированию. В 1959–1970 гг. дирижер Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля, в 1970–1971 гг. дирижер симфонического оркестра Татарской филармонии, в 1968–1972 гг. преподаватель Казанской консерватории.
Премию получил в 1991 г. за симфонию «Муса Джалиль» (1971; 1974), вокально-симфоническую поэму «Тукай аһәңнәре» («В ритмах Тукая», 1975) и симфоническую поэму «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» («Музыкальное приношение Салиху Сайдашеву», 1990).

## МОНАСЫЙПОВ
*Алмаз Закир улы*

**композитор, дирижер, педагог,**
**ТАССРның (1969), РСФСРның (1987) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык артисты (2000)**

*11.7.1925, Казан шәһәре – 24.7.2008, Мәскәү шәһәре*

1950 елда — Казан консерваториясен, 1964 елда симфоник дирижерлык буенча ассистентура-стажировка тәмамлый. 1959–1970 елларда — М.Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры дирижеры, 1970–1971 елларда — Татар филармониясенең симфоник оркестры дирижеры, 1968–1972 елларда Казан консерваториясендә укытучы булып эшли.
Иҗатында гомумкешелек мәдәниятенең сәнгати үзенчәлекләрен татар халкының милли музыкаль традицияләре белән табигый бәйләнештә чагылдыра. Дәүләт бүләге 1991 елда «Муса Җәлил» симфониясе (1971; 1974), «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасы (1975) һәм «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» симфоник поэмасы (1990) өчен бирелә.



## АГЛЯМОВ (АГЛЯМУТДИНОВ)
*Мударрис Зуфарович*

поэт,
заслуженный работник культуры РТ (1991 г.),
народный поэт РТ (2006 г.)

*13.10.1946, с. Пуст-Ашит Заинского района ТАССР – 26.11.2006, г. Казань*

Начал печататься в 1959 г. После окончания Казанского университета в 1968–1973 гг. работал учителем истории в Ново-Гардалинской средней школе Тукаевского района. С 1974 г. профессионально занимался литературным творчеством. Автор сборников «Кыңгырау» («Колокол», 1970), «Учак урыннары» («Следы костров», 1973), «Исәнме, йөрәк!» («Здравствуй, сердце!», 1978), сборника избранных произведений «Иман тәрәзә шакый» («Совесть стучит в окно», 1996) и сборника для детей «Без, без, без идек» («Мы — это мы», 1980).
Премию получил в 1992 г. за поэтические сборники «Киләчәккә кайту» («Возвращение в будущее») и «Мин әйттем...» («Я сказал...»).

## ӘГЪЛӘМОВ (ӘГЪЛӘМЕТДИНОВ)
*Мөдәррис Зөфәр улы*

шагыйрь,
ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1991),
ТРның халык шагыйре (2006)

*13.10.1946, ТАССРның хәзерге Зәй районы Пусташит (Бишсубаш) авылы – 26.11.2006, Казан шәһәре*

Әсәрләре 1959 елдан басыла башлый. Казан университетын тәмамлаганнан соң, 1968–1973 елларда Тукай районының Яңа Гәрдәле урта мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли. 1974 елдан профессиональ рәвештә бары тик иҗат эше белән генә шөгыльләнә. «Кыңгырау» (1970), «Учак урыннары» (1973), «Исәнме, йөрәк!» (1978), «Киләчәккә кайту» (1987), «Мин әйттем...» (1991), балалар өчен «Без, без, без идек» (1980) шигъри җыентыклары, «Иман тәрәзә шакый» (1996) сайланма әсәрләр җыентыгы авторы.
Дәүләт бүләге 1992 елда «Киләчәккә кайту» һәм «Мин әйттем...» шигъри җыентыклары өчен бирелә.

1992



# АВЗАЛОВА
*Альфия Авзаловна*

**певица, народная артистка ТАССР (1970 г.), заслуженная артистка РСФСР (1983 г.)**

*15.1.1933, д. Кабан Калтасинского района Башкирской АССР – 15.6.2017, г. Казань*

На профессиональную эстраду пришла из художественной самодеятельности. С 1957 г. артистка Татарской филармонии. Первый значительный успех певице принесли выступления на Декаде татарского искусства и литературы в Москве (1957 г.), где она участвовала в качестве солистки Ансамбля песни и танца ТАССР.

Одна из лучших исполнительниц татарских народных песен: «Шахта», «Гөлҗамал» («Гульжамал»), «Сарман» («Сарманово»), «Минзәлә» («Мензелинск»), «Казан сөлгесе» («Казанское полотенце»), «Зөләйха» («Зулейха»), а также песен татарских композиторов (Ф. Латыпова, С. Садыковой, А. Монасыпова) и самодеятельных авторов (Ф. Ахмадиева, Л. Айтуганова, В. Ахметшина, З. Гибадуллина, М. Имашева и др.). Премию получила в 1992 г. за концертные программы 1989–1991 гг. и значительный вклад в сохранение и развитие татарского вокального исполнительского искусства.

# АВЗАЛОВА
*Әлфия Авзал кызы*


**җырчы, ТАССРның халык артисты (1970), РСФСРның атказанган артисты (1983)**

*15.1.1933, БАССРның Калтасы районы Кабан авылы – 15.6.2017, Казан шәһәре*

Профессиональ сәхнәгә үзешчән сәнгатьтән килә. 1957 елдан — Татар филармониясе артисты. Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (1957) ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле солисты буларак ясаган чыгышлары җырчының беренче җитди уңышы була.

Әлфия Авзалова — «Шахта», «Гөлҗамал», «Сарман», «Минзәлә», «Казан сөлгесе», «Зөләйха» кебек татар халык җырларын, шулай ук татар композиторлары (Ф. Латыйпов, С. Садыйкова, А. Монасыйпов) һәм үзешчән авторлар (Ф. Әхмәдиев, Л. Айтуганов, В. Әхмәтшин, З. Гыйбадуллин, М. Имашев һ.б.) иҗат иткән җырларны иң яхшы башкаручыларның берсе. Дәүләт бүләге 1992 елда 1989–1991 еллардагы концерт программалары һәм татар вокаль башкару сәнгатен саклау һәм үстерүгә зур өлеш керткән өчен бирелә.

1992



# ЛИПКИН
## *Семён Израилевич*

**поэт, переводчик**

*6.9.1911, г. Одесса – 1.4.2003, г. Санкт-Петербург*

С 1929 г. жил в Москве. Окончил Московский инженерно-экономический институт (1937 г.). Автор поэтических сборников «Очевидец» (1967), «Лира» (1989), автобиографической повести «Записки жильца» (1992), мемуаров об А. А. Ахматовой, О. Э. Мандельштаме, Э. Г. Багрицком. С 1930 г. занимался переводами. Перевел на русский язык калмыцкий эпос «Джангар», киргизский эпос «Манас», поэмы «Лейли и Меджнун» Навои, «Шахнаме» Фирдоуси, а также стихотворения и поэмы Г. Тукая («Шурале», «Водяная»), произведения татарских поэтов Г. Чокрыя, Акмуллы, Дэрдменда, М. Джалиля, А. Кутуя, А. Ерикея, Ф. Карима, С. Хакима.

Премию получил в 1992 г. за литературное мастерство переводчика, популяризацию татарского эпоса «Идегей» среди русскоязычной аудитории, способствующую сохранению и передаче художественных и культурных особенностей оригинала, а также за признание значимости эпоса для национальной и мировой культуры.

# ЛИПКИН
## *Семён Израилевич*

**шагыйрь, тәрҗемәче**

*6.9.1911, Одесса шәһәре – 1.4.2003, Санкт-Петербург шәһәре*

1929 елдан Мәскәүдә яши. Мәскәү инженерлык-икътисад институтын тәмамлый (1937). «Очевидец» («Шаһит», 1967), «Лира» («Саз», 1989) шигъри җыентыклары, «Записки жильца» («Фатирчы язмалары», 1992) автобиографик повесте, А. А. Ахматова, О. Э. Мандельштам, Э. Г. Багрицкий турында мемуарлар авторы. 1930 еллардан соң тәрҗемә белән шөгыльләнә. «Җангар» (калмык), «Манас» (кыргыз) эпосларын, Нәваиның «Ләйлә вә Мәҗнүн», Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмаларын, шулай ук Г. Тукайның шигырьләрен, «Шүрәле», «Су анасы» поэмаларын, татар шагыйрьләре Г. Чокрый, Акмулла, Дәрдемәнд, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, Ф. Кәрим, С. Хәким шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә.

Дәүләт бүләге 1992 елда әдәби тәрҗемәләр остасы булуы, аерым алганда, «Идегәй» дастанын тәрҗемә иткән өчен бирелә. Тәрҗемәче, рус телле аудиторияне оригиналның мәдәни һәм сәнгати үзенчәлекләре белән таныштырып, татар эпосын популярлаштыруга зур өлеш кертә, аның милли һәм дөнья мәдәниятендә әһәмиятен танытуга ирешә.

1992



# ШАРАФЕЕВ
*Равиль Шигапович*

актер,
народный артист ТАССР (1978 г.), РСФСР (1988 г.)

*5.4.1938, с. Большой Салтан*
*Рыбно-Слободского района ТАССР*

В 1961 г. окончил татарскую студию Высшего театрального училища им. М. С. Щепкина. Работает в Татарском академическом театре им. Г. Камала. Исполнил множество разноплановых ролей, среди которых: Насретдин («Хужа Насретдин» Н. Исанбета), граф Альмавива («Женитьба Фигаро» П. Бомарше), герцог Винченцо, Петруччо («Мера за меру», «Укрощение строптивой» У. Шекспира), Галяви («Голубая шаль» К. Тинчурина), Ажаль («Старик из деревни Альдермеш» Т. Миннуллина), Сиразетдин («Банкрот» Г. Камала), Чебутыкин («Три сестры» А. Чехова). Всего им создано более 100 ярких сценических образов.
Премию получил в 1992 г. за выдающийся вклад в развитие татарского театрального искусства.

# ШӘРӘФИЕВ
*Равил Шиһап улы*

актер,
ТАССРның (1978), РСФСРның (1988) халык артисты

*5.4.1938, ТАССРның Балык Бистәсе районы*
*Олы Солтан авылы*

1961 елда М. С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесының (Мәскәү) татар студиясен тәмамлый. Шул ук елдан Г. Камал исемендәге Татар академия театрында эшли. Төрле пландагы рольләр башкара, шулар арасында Насретдин («Хуҗа Насретдин», Н. Исәнбәт), граф Альмавива («Фигароның өйләнүе», П. Бомарше), герцог Винченцо, Петруччо («Чамасына күрә чарасы», «Тискәрегә авызлык», У. Шекспир), Галәви («Зәңгәр шәл» К. Тинчурин), Әҗәл («Әлдермештән Әлмәндәр» Т. Миңнуллин), Сираҗетдин («Банкрот» Г. Камал), Чебутыкин («Өч сеңел» А. Чехов) һәм башкалар бар. Аның тарафыннан барлыгы 100 дән артык истә калырлык сәхнә образы иҗат ителә.
Дәүләт бүләге 1992 елда татар театр сәнгатен үстерүгә гаять зур өлеш керткән өчен бирелә.



# МУХАМАДИЕВ
## *Ринат Сафиевич*

**писатель, литературовед, литературный критик, общественный деятель, кандидат филологических наук (1979 г.), заслуженный работник культуры ТАССР (1986 г.), РФ (2010 г.)**

*10.12.1948, д. Малые Кирмени Мамадышского района ТАССР*

Окончил Казанский университет (1971 г.). В 1970–1973 гг. редактор телепередач в Комитете по телевидению и радиовещанию Совета Министров ТАССР, в 1976–1986 гг. редактор отдела и заместитель главного редактора журнала «Казан утлары» («Огни Казани»). В 1986–1989 гг. директор Татарского книжного издательства, в 1989–1999 гг. председатель правления Союза писателей Татарстана, одновременно в 1990–1993 гг. председатель постоянной комиссии Верховного Совета РСФСР по культуре и национальным вопросам. С 2000 г. живет в Москве.
Премию получил в 1993 г. за документально-художественный роман «Сират күпере» («Мост над адом» , 1992).

---


# МӨХӘММӘДИЕВ
## *Ринат Сафа улы*

**язучы, әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе, филология фәннәре кандидаты (1979), ТАССРның (1986), РФнең (2010) атказанган мәдәният хезмәткәре**

*1948 елның 10 декабре, ТАССР, Мамадыш районы, Кече Кирмән авылы*

Казан университетын тәмамлый (1971). 1970–1973 елларда — ТАССР Министрлар Советының телевидение һәм радиотапшырулар комитетында телевизион тапшырулар мөхәррире, 1976–1986 елларда «Казан утлары» журналында бүлек мөхәррире һәм баш мөхәррир урынбасары. 1986–1989 елларда — Татарстан китап нәшрияты директоры, 1989–1999 елларда — Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, бер үк вакытта, 1990–1993 елларда, РСФСР Югары Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе. 2000 елдан Мәскәүдә яши.
Дәүләт бүләге 1993 елда «Сират күпере» (1992) романы өчен бирелә.

1994



# ФАТХУТДИНОВ
## *Ахсан Саримович*

**живописец, монументалист, скульптор, заслуженный деятель искусств ТАССР (1987 г.), народный художник РТ (2001 г.)**

*7.6.1939, пос. Вагаповка Черемшанского района ТАССР – 15.7.2012, г. Нижнекамск*

В 1966 г. окончил художественно-графическое отделение Нижнетагильского педагогического училища, после чего преподавал там же живопись. В 1969–2000 гг. жил в Нижнекамске, работал в Татарском художественном фонде. Творческую деятельность начинал как художник-оформитель, монументалист. Особое место в его наследии занимает искусство резьбы по дереву.

Премию получил в 1993 г. за цикл работ «Иялəр» («Обереги»), который стал подлинным художественным откровением и новым словом в татарском изобразительном искусстве. Цикл включает более 50 произведений, представляющих собой синтез живописи и деревянной скульптуры.

# ФƏТХЕТДИНОВ
## *Əхсəн Сарим улы*

**нəкышьче, монументалист, сынчы, ТАССРның атказанган сəнгать эшлеклесе (1987), ТРның халык рəссамы (2001)**

*7.6.1939, ТАССРның Чирмешəн районы Вагаповка поселогы – 15.7.2012, Түбəн Кама шəһəре*

1966 елда Түбəн Тагил педагогия училищесының сəнгать-графика бүлеген тəмамлаганнан соң, шунда ук рəсем буенча укыта. 1969–2000 елларда Түбəн Камада яши, Татарстан сəнгать фондында эшли. Иҗат эшчəнлеген рəссам-бизəүче, монументалист буларак башлый. Аның иҗат мирасында агачка уеп кисү сəнгате аерым урын алып тора.

Дəүлəт бүлəге 1993 елда «Иялəр» циклы өчен бирелə. Əлеге цикл, чын мəгънəсендə сəнгати ачышка əверелеп, татар сынлы сəнгатенə яңалык алып килə. Ул нəкышь сəнгате белəн агач скульптурасы синтезыннан гыйбарəт булган 50 дəн артык əсəрне үз эченə ала.

1994



# ФАТТАХ (ФАТТАХОВ) *Нурихан Садрильманович*

**писатель, заслуженный работник культуры РСФСР (1978 г.), народный писатель РТ (1998 г.)**

*25.10.1928, д. Кучтэ-аул Янаульского района Башкирской АССР – 18.2.2004, г. Казань*

После окончания Казанского университета (1951 г.) работал в Татарском книжном издательстве. В 1950-е гг. участвовал в освоении целины в Казахстане. В конце 1950-х — начале 1960-х гг. активно участвовал в научных экспедициях, собирал и изучал этнографические материалы, летописи, путешествовал по местам исторических событий. Интерес к национальной истории определил его дальнейшее творчество. В 1957 г. вышел его первый роман «Сезнеңчә ничек?» («Как по-вашему?»).

Премию получил в 1994 г. за роман-дилогию «Сызгыра торган уклар» («Свистящие стрелы»), который способствовал расширению горизонтов татарской исторической прозы и укрепил интерес к национальной истории.


# ФӘТТАХ (ФӘТТАХОВ) *Нурихан Садрилмән улы*

**язучы, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1978), ТРның халык язучысы (1998)**

*25.10.1928, БАССРның Яңавыл районы Күчтавыл авылы – 18.2.2004, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1951), Татарстан китап нәшриятында эшли. 1950 елларда Казакъстанда чирәм, яткын җирләрне күтәрүдә катнаша. 1950 еллар ахыры — 1960 еллар башында фәнни экспедицияләрдә актив катнаша, тарихи һәм этнографик материаллар, елъязмалар туплый һәм өйрәнә, тарихи вакыйгалар булган урыннарга сәяхәт кыла. Милли тарих белән кызыксыну язучының алдагы бөтен иҗатын билгели. 1957 елда аның «Сезнеңчә ничек?» дип аталган беренче романы дөнья күрә. Дәүләт бүләге 1994 елда «Сызгыра торган уклар» роман-дилогиясе өчен бирелә. Әлеге әсәр татар тарихи прозасы чикләрен киңәйтүгә булышлык итә һәм милли тарих белән кызыксыну көчен арттыра.

1994



## ЗАРИПОВ
### *Ильдар Касимович*

**живописец,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1976 г.),**
**заслуженный художник РСФСР (1983 г.),**
**народный художник РФ (2002 г.)**

*15.11.1939, г. Казань – 14.6.2012, там же*

Окончил Казанское художественное училище (1961 г.), Московский художественный институт им. В. И. Сурикова (1968 г.; учился у Д. К Мочальского). В 1968–1970 гг. занимался в Мастерской живописи Академии художеств СССР в Москве у Г. М. Коржева. В 1970–1975 гг. преподаватель изостудии в Казани. Член правления Союза художников РСФСР (1972–1980 гг.).
Премию получил в 1994 г. за серию картин «Буяуларда — халык моңнары» («В красках — песни народа»), в которой воплощены мотивы татарского фольклора, народные песни, сказания и обряды. Серия отражает глубокое погружение мастера в национальную культуру, синтез традиций и новаторства, а также его уникальный художественный язык.

## ЗАРИПОВ
### *Илдар Касыйм улы*

**нәкышьче,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1976),**
**РСФСРның атказанган рәссамы (1983),**
**РФнең халык рәссамы (2002)**

*15.11.1939, Казан шәһәре – 14.6.2012, шунда ук*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1961), В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын (1968, Д. К. Мочальскийда укый) тәмамлый. 1968–1970 елларда Мәскәүдә СССР Сынлы сәнгать академиясенең Нәкышь остаханәсендә Г. М. Коржевта осталык мәктәбе уза. 1970–1975 елларда Казан сынлы сәнгать студиясендә укыта. 1972–1980 елларда РСФСР Рәссамнар берлегенең идарә әгъзасы була.
Дәүләт бүләге 1994 елда татар фольклоры мотивлары, халык җырлары, риваятьләр һәм йолалар гәүдәләнгән «Буяуларда — халык моңнары» картиналар сериясе өчен бирелә. Әлеге хезмәт останың милли мәдәниятне тирәнтен белүен, традицияләр һәм авторның новаторлыгы синтезын, шулай ук аның үзенә генә хас кабатланмас сәнгати телен ачык чагылдыра.

1994



# МАНСУРОВ
## *Фуат Шакирович*

**дирижер, педагог,**
**народный артист Казахской ССР (1967 г.),**
**ТАССР (1975 г.), РФ (1998 г.),**
**заслуженный деятель искусств РФ (1995 г.)**

*10.1.1928, г. Алма-Ата, Казахская ССР – 11.6.2010, г. Москва*

В 1950 г. окончил Алма-Атинский университет, в 1951 г. — Алма-Атинскую консерваторию. В 1953–1956 гг. работал дирижером в Казахском театре оперы и балета, в 1963–1967 гг. — главным дирижером. С 1969 г. дирижер Большого театра СССР. Одновременно в 1968–1970 гг. занимал пост главного дирижера Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля. С 1986 г. главный дирижер и художественный руководитель Симфонического оркестра РТ. Является первым исполнителем многих симфонических произведений композиторов Татарстана: Н. Жиганова, М. Музафарова, А. Ключарёва, Ф. Ахметова, А. Миргородского, А. Луппова и др.
Премию получил в 1994 г. за выдающиеся достижения в области оперного и балетного искусства, систематический вклад в пропаганду татарской симфонической музыки и концертные программы 1991–1993 гг., осуществленные совместно с Симфоническим оркестром РТ.

# МАНСУРОВ
## *Фуат Шакир улы*

**дирижер, педагог,**
**Казакъстан ССРның (1967), ТАССРның (1975),**
**РФнең (1998) халык артисты,**
**РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе (1995)**

*10.1.1928, Казакъстан ССРның Алма-Ата шәһәре – 11.6.2010, Мәскәү шәһәре*

1950 елда Алма-Ата университетын, 1951 елда Алма-Ата консерваториясен тәмамлый. 1953–1956 елларда — Казакъстан опера һәм балет театрында дирижер, 1963–1967 елларда — баш дирижер. 1969 елдан — СССР Зур театры дирижеры. Бер үк вакытта, 1968–1970 елларда, М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының (Казан шәһәре) баш дирижеры вазифасын башкара. 1986 елдан — ТР Дәүләт симфоник оркестрының баш дирижеры һәм сәнгать җитәкчесе. Татарстан композиторлары Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Ф. Әхмәтов, А. Миргородский, А. Луппов һәм башкаларның күпсанлы симфоник әсәрләрен беренче башкаручы.
Дәүләт бүләге 1994 елда опера һәм балет сәнгате өлкәсендәге казанышлары, татар симфоник музыкасын пропагандалауга даими өлеш кертүе һәм 1991–1993 елларда ТР Дәүләт симфоник оркестры белән берлектә башкарган концерт программалары өчен бирелә.



## ЯРУЛЛИН
*Фанис Гатауллович*

писатель,
заслуженный работник культуры ТАССР (1985 г.),
народный поэт РТ (2001 г.)

*9.2.1938, д. Кызыл Яр Бавлинского района ТАССР – 9.12.2011, г. Казань*

Окончил Казанский университет (1970 г.). Известность ему принесла автобиографическая повесть «Җилкәннәр җилдә сынала» («Упругие паруса», 1973). Пьесы писателя ставились во многих театрах Татарстана, Башкортостана и Марий Эл. Является автором книг для детей «Минем елмаю» («Я улыбаюсь», 1968), «Зәңгәр күлдә ай коена» («В синем озере луна купается», 1990), «Серле дөнья» («Таинственный мир», 1997) и др.
Премию получил в 1995 г. за поэтический сборник «Җан авазы» («Крик души», 1994), а также за выдающиеся заслуги в развитии татарской литературы, высокое профессиональное мастерство, новизну и оригинальность произведения, значительный вклад в национальную культуру.

## ЯРУЛЛИН
*Фәнис Гатаулла улы*

язучы,
ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985),
ТРның халык шагыйре (2001)

*9.2.1938, ТАССРның Баулы районы Кызылъяр авылы – 9.12.2011, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1970). «Җилкәннәр җилдә сынала» (1973) автобиографик повесте әдипкә аеруча киң танылу китерә. Язучының пьесалары буенча спектакльләр Татарстан, Башкортстан һәм Мари Республикасы театрлары сәхнәләрендә куела. Балалар өчен «Минем елмаю» (1968), «Зәңгәр күлдә ай коена» (1990), «Серле дөнья» (1997) һәм башка китаплар авторы.
Дәүләт бүләге 1995 елда «Җан авазы» шигъри җыентыгы (1994), шулай ук татар әдәбиятын үстерүдәге олы казанышлары, югары профессиональ осталыгы, әсәрләренең яңалыгы һәм оригинальлеге, шулай ук милли мәдәниятне баетуга зур өлеш керткән өчен бирелә.



# БАШИРОВ
*Гумер Баширович*

**писатель, народный писатель ТАССР (1986 г.), лауреат Государственной премии СССР (1951 г.)**

*7.1.1901, д. Янга-Сала Казанского уезда Казанской губернии, ныне Арский район РТ – 7.5.1999, г. Казань*

Участник Гражданской войны. Учился в спецшколе НКВД (1924–1925 гг.). До 1929 г. работал в правоохранительных органах Арского кантона, до 1932 г. — в системе народного образования. С 1932 г. в Казани. Работал в редакциях газет «Кызыл Татарстан» («Красный Татарстан», до 1936 г.), «Совет әдәбияты» («Советская литература», до 1938 г.), в Таттосиздате (до 1941 г.). В 1941–1942 гг. один из ответственных секретарей журнала «Совет әдәбияты», в 1942–1944 гг. главный редактор Татарского рескома по радиовещанию при Совете Народных Комиссаров ТАССР.
Премию получил в 1996 г. за повести «И язмыш, язмыш» («О судьба, судьба», 1990) и «Сарут» («Пырей», 1990). Произведения этого периода отличаются национальной идентичностью, глубоким психологизмом и мастерским использованием языка.

# БӘШИРОВ
*Гомәр Бәшир улы*

**язучы, ТАССРның халык язучысы (1986), СССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1951)**

*7.1.1901, Казан губернасының Казан өязе, хәзер ТРның Арча районы Яңасала авылы – 7.5.1999, Казан шәһәре*

Авыл мәдрәсәсендә укый. 1919 елдан укытучылык эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Гражданнар сугышында катнаша. 1924–1925 елларда Эчке эшләр халык комиссариатының Казандагы берьеллык махсус мәктәбендә укый, 1929 елга кадәр — Арча кантоны милиция органнарында, аннары 1932 елга кадәр халык мәгарифе системасында эшли. 1932 елдан Казанда яши. «Кызыл Татарстан» (1936 елга кадәр), «Совет әдәбияты» (1938 елга кадәр) газеталары редакцияләрендә, 1941 елга кадәр Татарстан дәүләт нәшриятында (Таттосиздат) эшли. 1941–1942 елларда — «Совет әдәбияты» журналының җаваплы сәркатипләреннән берсе, 1942–1944 елларда — ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Татарстан радиотапшырулар комитетының баш мөхәррире.
Дәүләт бүләге 1996 елда «И язмыш, язмыш» һәм «Сарут» (икесе дә — 1990) повестьлары өчен бирелә. Әдипнең әлеге әсәрләре тирән психологизм, гуманистик идеяләр белән сугарылган, аларда тормыш-көнкүреш турында уйланулар зур урын алып тора, мөһим социаль-иҗтимагый проблемалар күтәрелә.

# 1996



## КУДАШЕВА
*Фарида Ягудовна*

**актриса, певица,
народная артистка Башкирской АССР (1968 г.), ТССР (1990 г.), заслуженная артистка РСФСР (1972 г.)**

*15.12.1920, д. Кляшево Уфимского кантона Уфимской губернии, ныне Чишминский район Республики Башкортостан – 9.10.2010, г. Уфа*

В 1939 г. окончила Уфимское театрально-художественное училище. В 1939–1941 гг. артистка Дюртюлинского театра, в 1944–1947 гг. — Башкирского академического театра драмы. В 1941–1944, 1956–1978 гг. солистка Башкирской филармонии, в 1948–1956 гг. — Башкирского радио.
Репертуар певицы включал народные песни, а также произведения композиторов Башкортостана и Татарстана. Премию получила в 1996 г. за исполнение татарских народных песен и песен на стихи Г. Тукая. Среди наиболее популярных песен — «Каз канаты» («Гусиные крылья») и «Дим буе» («У реки Дёмы»).

## КУДАШЕВА
*Фәридә Яһүдә кызы*

**актриса, җырчы,
БАССРның (1968), ТССРның (1990) халык артисты, РСФСРның атказанган артисты (1972)**

*15.12.1920, Уфа губернасының Уфа кантоны, хәзер БРның Чишмә районы Келәш авылы – 9.10.2010, Уфа шәһәре*

1939 елда Уфа театр-сәнгать училищесын тәмамлый. 1939–1941 елларда — Дүртөйле колхоз-совхоз театры артисты, 1944–1947 елларда — Башкорт академия драма театры артисты. 1941–1944 һәм 1956–1978 елларда — Башкорт дәүләт филармониясе солисты, 1948–1956 елларда — Башкорт радиосы солисты.
Җырчының репертуарын халык җырлары, шулай ук Башкортстан һәм Татарстан композиторлары әсәрләре тәшкил итә. Дәүләт бүләге 1996 елда татар халык җырларын һәм Г.Тукай шигырьләренә язылган җырларны башкарган өчен бирелә. Аның башкаруында иң популяр җырлар арасында — «Каз канаты» һәм «Дим буе».

1997



# АБЗГИЛЬДИН
## *Абрек Амирович*

**живописец, художник-монументалист, народный художник РТ (1995 г.), РФ (2009 г.), заслуженный деятель искусств ТАССР (1986 г.), РФ (2002 г.)**

*1.3.1937, г. Баймак, Башкирская АССР – 24.12.2013, г. Казань*

Окончил Казанское художественное училище (1965 г.), Московский художественный институт им. В. И. Сурикова (1970 г.). С 1970 г. жил и работал в Казани. В 1993–2008 гг. председатель правления Союза художников РТ. Мастер станковой и монументальной живописи, работал в технике керамической и смальтовой мозаики, а также в области декоративно-прикладного искусства.
Премию получил в 1997 г. за цикл работ — триптих «Г. Тукай», «Дэрдменд», «Б.Урманче». Через мастерство портретной живописи художник сумел совершить подлинное художественное откровение. В каждом образе читается не только индивидуальная судьба, но и дыхание времени, неразрывная связь поколений, богатство национальной культуры.

# АБЫЗГИЛДИН
## *Абрек Әмир улы*

**нәкышьче, монументаль сәнгать рәссамы, ТРның (1995), РФнең (2009) халык рәссамы, ТАССРның (1986), РФнең (2002) атказанган сәнгать эшлеклесе.**

*1.3.1937, БАССРның Баймак шәһәре – 24.12.2013, Казан шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1965), В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын (1970) тәмамлый. 1970 елдан Казанда яши һәм иҗат итә. 1993–2008 елларда — ТР Рәссамнар берлегенең идарә рәисе. Станлы һәм монументаль нәкышь остасы, керәч һәм смальталы мозаика техникасын кулланып иҗат итә, шулай ук гамәли бизәлеш сәнгате өлкәсендә эшли.
Дәүләт бүләге 1997 елда «Г. Тукай» (1980), «Б. Урманче» (1989), «Дәрдемәнд» (1997) триптихлары — әсәрләр циклы өчен бирелә. Әлеге күренекле шәхесләрнең портретлары билгеле бер чор язмышлары яктыртылган визуаль симфонияләр ролен үти. Һәр образда шәхси язмыш кына түгел, заман сулышы, буыннар бәйләнеше, милли мәдәният байлыгы да гәүдәләнә.

1997



# ХАРИСОВ
## *Ренат Магсумович (псевдоним — Ренат Харис)*

**поэт, литературный критик, драматург, заслуженный деятель искусств ТАССР (1972 г.), народный поэт РТ (2004 г.), лауреат Государственной премии РФ в области литературы и искусства (2005 г.)**

*6.5.1941, с. Елховое Озеро Богдашкинского района Ульяновской области*

В 1963 г. окончил Казанский педагогический институт. С 1971 г. ответственный секретарь правления Союза писателей ТАССР. С 1973 г. заместитель министра культуры ТАССР, с 1982 г. главный редактор журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), с 1991 г. главный редактор газеты «Татарстан хәбәрләре» («Известия Татарстана»), в 1995–1999 гг. заместитель Председателя Государственного Совета РТ. Важное направление творчества поэта с 1990-х гг. — создание либретто для музыкальных произведений различных жанров.
Премию получил в 1997 г. за сборник стихотворений и поэм «Хисемнең исеме» («Имя моих чувств»), написанных с лирико-философской интонацией.

# ХАРИСОВ
## *Ренат Мәгъсүм улы (псевдонимы — Ренат Харис)*

**шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе, драматург, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1972), ТРның халык шагыйре (2004), әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә РФнең Дәүләт бүләге лауреаты (2005)**

*6.5.1941, Сембер өлкәсенең Богдашкино районы, хәзер Ульяновск өлкәсенең Чынлы районы Кәшә (Зирекле Күл) авылы*

1963 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. 1971 елдан — ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркатип. 1973 елдан — ТАССР мәдәният министры урынбасары. 1982 елдан — «Казан утлары» журналының, 1991 елдан — «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире. 1995–1999 елларда — ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары. 1990 еллардан шагыйрь иҗатының мөһим юнәлеше — төрле жанрдагы музыкаль әсәрләр өчен либреттолар иҗат итү.
Дәүләт бүләге 1997 елда лирик-фәлсәфи юнәлештә язылган «Хисемнең исеме» шигырь һәм поэмалар җыентыгы (1996) өчен бирелә.

1997



## ГАНЕЕВА (ГАНИЕВА)
### *Винера Ахатовна*

**певица (колоратурное сопрано),
народная артистка РТ (1992 г.), РФ (1995 г.),
профессор (2001 г.)**

*24.3.1955, г. Казань*

В 1983 г. окончила Казанскую консерваторию по классу В. Лазько. С 1983 г. солистка Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля. В ее концертном репертуаре песни и романсы татарских, русских, зарубежных композиторов. Ведет активную педагогическую деятельность, с 2000 г. занимает должность заведующей кафедрой сольного пения Казанского института культуры.
Премию получила в 1997 г. за исполнение партий Джильды в опере «Риголетто» Дж. Верди, Розины в опере «Севильский цирюльник» Дж. Россини, Алтынчеч в опере «Алтынчеч» («Златовласка») Н. Жиганова.


## ГАНИЕВА
### *Винера Әхәт кызы*

**җырчы (колоратуралы сопрано),
ТРның (1992), РФнең (1995) халык артисты,
профессор (2001)**

*24.3.1955, Казан шәһәре*

1983 елда Казан консерваториясен (В. Лазько классы) тәмамлый. 1983 елдан — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры солисты. Җырчының концерт репертуарын татар, рус һәм чит ил композиторларының җырлары һәм романслары тәшкил итә. Актив педагогик эшчәнлек алып бара. 2000 елдан — Казан мәдәният институтының ялгыз җырлау кафедрасы мөдире.
Дәүләт бүләге 1997 елда Дж. Вердиның «Риголетто» операсында Джильда, Дж. Россининың «Севилья чәчтарашы» операсында Розина, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партияләрен башкарган өчен бирелә.

1998



# МИННУЛЛИН
*Роберт Мугаллимович*

**поэт, журналист, общественный деятель, заслуженный деятель искусств РТ (1993 г.), народный поэт РТ (2005 г.)**

*1.8.1948, д. Назяде Илишевского района Башкирской АССР – 27.3.2020, г. Казань*

После окончания Казанского университета (1973 г.) работал в редакции газеты «Яшь ленинчы» («Молодой ленинец»). В 1977–1983 гг. в журнале «Казан утлары» («Огни Казани»). В 1983–1986 гг. главный редактор художественных передач Государственного комитета ТАССР по телевидению и радиовещанию. В 1986–1995 гг. главный редактор газеты «Сабантуй». С 1995 г. в Государственном Совете РТ: председатель Постоянной комиссии по культуре и национальным вопросам, заместитель Председателя Государственного Совета РТ (2000–2004 гг.).
Премию получил в 1998 г. за книгу для детей «Күчтәнәч» («Гостинец», 1995), в которой создал особый поэтический язык для детей, которому присущи простота и прозрачность формы, отсутствие назидательности.

# МИҢНУЛЛИН
*Роберт Мөгаллим улы*

**шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), ТРның халык шагыйре (2005)**

*1.8.1948, БАССРның Илеш районы, Нәҗәде авылы – 27.3.2020, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1973), «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли. 1977–1983 елларда — «Казан утлары» журналында. 1983–1986 елларда — ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитетында әдәби тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире. 1986–1995 елларда — «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире. 1995 елдан — ТР Дәүләт Советында: Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары (2000–2004).
Татар әдәбиятында балалар шигырьләрендә өлкәннәр һәм балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, балалар дөньясы проблемаларын яктыртучы беренче шагыйрь. Дәүләт бүләге 1998 елда балаларга аңлаешлы үзенчәлекле поэтик тел белән язылган, гади һәм ачык формага ия булган, үгет-нәсихәткә корылмаган «Күчтәнәч» (1995) китабы өчен бирелә.



# БИКЧАНТАЕВ
*Фарид Рафкатович*

**режиссер, актер, педагог, заслуженный деятель искусств РТ (1996 г.), РФ (2010 г.)**

*21.5.1962, г. Казань*

В 1983 г. окончил Казанское театральное училище, в 1991 г. — режиссерский факультет ГИТИСа (г. Москва). Среди поставленных спектаклей — «Асылъяр» («Возлюбленная» М. Файзи, 1991 г.), «Учитель танцев» Лопе де Веги (1995 г.), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» («Рыжий насмешник и его черноволосая красавица» Н. Исанбета, 1999 г.) и др. С 1990 г. преподает в Казанском институте культуры. С 2002 г. главный режиссер Татарского академического театра им. Г. Камала.
Его манере присущи смелость художественного поиска, верность традициям и способность делать татарский театр явлением общекультурного значения. Премию получил в 1998 г. за постановку спектакля «Хушыгыз!» («Прощайте!», 1993 г.) по пьесе Т. Миннуллина на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала.

# БИКЧӘНТӘЕВ
*Фәрит Рәфкат улы*

**режиссер, драма актеры, педагог, ТРның (1996), РФнең (2010) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*21.5.1962, Казан шәһәре*

1983 елда Казан театр училищесын, 1991 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлык факультетын тәмамлый. Сәхнәгә куйган спектакльләре арасында — «Асылъяр» (М. Фәйзи, 1991), «Биюче» (Лопе де Вега, 1995), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» (Н. Исәнбәт, 1999) һ.б. 1990 елдан Казан мәдәният институтында укыта. 2002 елдан — Г. Камал исемендәге Татар академия театрының баш режиссеры.
Аның иҗат манерасына кыю сәнгати табышлар, традицияләргә тугрылык һәм татар театрын гомуммәдәни әһәмияткә ия күренешкә әвереләдерә белү осталыгы хас. Дәүләт бүләге 1998 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә Т. Миңнуллинның «Хушыгыз!» пьесасы буенча куйган спектакле (1993) өчен бирелә.

1998



## ДУНАЕВ
*Николай*
*(на сцене Наиль)*
*Иванович*

**актер, педагог,**
**народный артист ТАССР (1982 г.),**
**заслуженный артист РФ (1996 г.)**

*3.5.1937, д. Ахметьево Заинского района ТАССР –*
*30.10.2022, г. Казань*

После окончания Театрального училища им. М. С. Щепкина (1961 г.) был принят в труппу Татарского академического театра им. Г. Камала. Одной из творческих вершин актера стал образ Мирвали в спектакле «Өч аршын җир» («Три аршина земли») по повести А. Гилязова. Вел педагогическую деятельность: в 1983–1986 гг. преподавал в Казанском театральном училище, с 1986 г. — в Казанском институте культуры.
Премию получил в 1998 г. за роль Нурислама в спектакле «Хушыгыз!» («Прощайте!»), поставленном по пьесе Т. Миннуллина на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала. Актеру удалось глубоко раскрыть сложный и противоречивый характер своего героя.

---

## ДУНАЕВ
*Николай*
*(псевдонимы Наил)*
*Иванович*

**актер, педагог,**
**ТАССРның халык артисты (1982),**
**РФнең атказанган артисты (1996)**

*3.5.1937, ТАССРның Зәй районы Әхмәт авылы –*
*30.10.2022, Казан*

Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлаганнан соң (1961), Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасына кабул ителә. Актерның иҗади уңышларыннан берсе — А. Гыйләҗев повесте буенча сәхнәләштерелгән «Өч аршын җир» спектаклендәге Мирвәли образы. Педагогик эшчәнлек алып бара: 1983–1986 елларда — Казан театр училищесында, 1986 елдан Казан мәдәният институтында укыта.
Дәүләт бүләге 1998 елда Т. Миңнуллинның «Хушыгыз!» пьесасы буенча Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә Ф. Бикчәнтәев куйган спектакльдәге (1993) Нурислам роле өчен бирелә. Актер үз героеның катлаулы һәм каршылыклы холкын тирәнтен ачуга ирешә.

1998



# ШАКИРОВ
*Азгар Шафикович*

актер,
народный артист РСФСР (1988 г.), РТ (2000 г.)

*22.2.1940, д. Буралы Тумутукского района ТАССР, ныне Азнакаевский район РТ*

После окончания Театрального училища им. М. С. Щепкина в Москве (1961 г.) был принят в труппу Татарского академического театра им. Г. Камала. Особое место в творчестве артиста занимает образ Хромого («Бичура» по пьесе М. Гилязова, 1989 г.). Среди других значительных ролей: Нурхамат, Галимулла («Ильгизар+Вера», 1991 г., «Хушыгыз!» — «Прощайте», 1993 г. Т. Миннуллина), Тохтамыш-хан («Идегей» Ю. Сафиуллина, 1994 г.), Альмухаммат («Әни килде» — «Приехала мама» Ш. Хусаинова, 1999 г.), старый Зариф («Телсез күке» — «Немая кукушка» З. Хакима, 2004 г.), Салим-бай («Курчак туе» — «Кукольная свадьба» М. Гилязова, Р. Хамида по произведениям Г. Исхаки, 2009 г.) и др.
Премию получил в 1998 г. за раскрытие характера и блестящую игру в роли Галимуллы в спектакле «Хушыгыз!» («Прощайте!»), поставленном по пьесе Т. Миннуллина на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала.

# ШАКИРОВ
*Әзһәр Шәфикъ улы*

актер,
РСФСРның (1988), ТРның (2000) халык артисты

*22.2.1940, ТАССРның Тымытык районы, хәзер ТРның Азнакай районы Буралы авылы*

Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлаганнан соң (1961), Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасына кабул ителә. Артист иҗатында Аксакал образы («Бичура», М. Гыйләҗев пьесасы буенча, 1989) аерым урын алып тора. Зур әһәмияткә ия башка рольләре арасында Нурхәмәт һәм Галимулла («Илгизәр+Вера», 1991; «Хушыгыз!», 1993, Т. Миңнуллин), Туктамыш хан («Идегәй», Ю. Сафиуллин, 1994), Әлмөхәммәт («Әни килде» Ш. Хөсәенов, 1999), Зариф карт («Телсез Күке», З. Хәким, 2004), Сәлим бай («Курчак туе», М. Гыйләҗев, Р. Хәмид; Г. Исхакый әсәрләре буенча, 2009) һәм башкалар бар.
Дәүләт бүләге 1998 елда Т. Миңнуллинның «Хушыгыз!» пьесасы буенча Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Ф. Бикчәнтәев куйган спектакльдәге (1993) Галимулла ролендә характерны ачуы һәм оста уены өчен бирелә.

1998



# ИХСАНОВА
*Нажиба*
*Гимаделисламовна*

**актриса,**
**народная артистка ТАССР (1982 г.), РФ (2000 г.)**

*25.1.1938, с. Буралы Азнакаевского района ТАССР – 12.3.2021, г. Казань*

После окончания Высшего театрального училища им. М. С. Щепкина (1961 г.) была принята в труппу Татарского академического театра им. Г. Камала. За годы службы в театре создала более 100 сценических ролей, покоривших зрителей глубиной и искренностью исполнения. Среди известных работ актрисы — роли в спектаклях по пьесам Т. Миннуллина в постановке М. Салимжанова: Гульфина («Әниләр һәм бәбиләр» — «Колыбельная»), Уммия («Әлдермештән Әлмәндәр» — «Старик из деревни Альдермеш»), Аудаки («Гөргөри кияүләре» — «Зятья Григория»).
Премию получила в 1998 г. за роль Миляуши в спектакле «Хушыгыз!» («Прощайте!»), поставленном по пьесе Т. Миннуллина на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала.

# ИХСАНОВА
*Нәҗибә*
*Гыймаделислам кызы*

**актриса,**
**ТАССРның (1982), РФнең (2000) халык артисты**

*25.1.1938, ТАССРның Азнакай районы Буралы авылы – 12.3.2021, Казан шәһәре*

Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлаганнан соң (1961), Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасына кабул ителә. Театрда эшләгән елларында тамашачыны башкару тирәнлеге һәм ихласлыгы белән әсир иткән 100 дән артык сәхнә образы иҗат итә. Т. Миңнуллин пьесалары буенча М. Сәлимҗанов куйган спектакльләрдәге Гөлфинә («Әниләр һәм бәбиләр»), Өммия («Әлдермештән Әлмәндәр»), Әүдәки («Гөргөри кияүләре») рольләре аеруча танылган.
Дәүләт бүләге 1998 елда Т. Миңнуллинның «Хушыгыз!» пьесасы буенча Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә Ф. Бикчәнтәев куйган спектакльдәге (1993) Миләүшә роле өчен бирелә. Әлеге роль актрисаның иҗат биографиясендә аерым бер этап булып тора: ул игътибарга лаек көчле образларның берсен иҗат итә һәм героиняның психологик портретын ачуда югары осталык күрсәтә.



# БАЯН (БАЯНОВ)
*Ахсан*
*Фатхелбаянович*

**писатель,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1988 г.),**
**народный поэт РТ (2004 г.)**

*8.12.1927, д. Ашман, ныне Илишевский район Республики Башкортостан – 7.5.2013, г. Казань*

Окончил Казанский университет (1956 г.). Начал печататься в 1950 г. Автор более 20 поэтических сборников, а также произведений в прозе и драматургии. В 1961–1981 гг. сотрудник журнала «Казан утлары» («Огни Казани»). В 1974–1999 гг. член правления Союза писателей Татарстана. В 1989–1999 гг. руководил Литературным фондом. Среди основных произведений: сборники стихов «Мират» (1963), «Сез аңларсыз мине» («Вы поймете меня», 1971), «Кызыл ут» («Красный огонь», 1994) и др.
Премию получил в 1999 г. за книгу «Урланган ай» («Похищенная луна»), которая стала заметным явлением в татарской литературе, вызвав дискуссию о путях развития общества. Писатель затрагивает темы национальной идентичности, связи поколений, нравственного выбора, а также актуальные проблемы общества.

# БАЯН (БАЯНОВ)
*Әхсән*
*Фәтхелбаян улы*

**язучы,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988),**
**ТРның халык шагыйре (2004)**

*8.12.1927, хәзерге Башкортстан Республикасының Илеш районы Ашман авылы – 7.5.2013, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1956). Әсәрләре 1950 елларда басыла башлый. 20 дән артык шигъри җыентык, шулай ук проза һәм драма әсәрләре авторы. 1961–1981 елларда «Казан утлары» журналында эшли. 1974–1999 елларда — Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, 1989–1999 елларда — Әдәби фонд идарәсе рәисе. Төп әсәрләре арасында «Мират» (1963), «Сез аңларсыз мине» (1971), «Кызыл ут» (1994) шигъри җыентыклары бар.
Дәүләт бүләге 1999 елда «Урланган ай» китабы (1997) өчен бирелә. Җыентыкка тупланган повестьларда актуаль социаль-иҗтимагый проблемалар күтәрелә, милли үзаң, буыннар бәйләнеше, әдәп-әхлак мәсьәләләре үзәккә алынып яктыртыла.



# ЛУППОВ
## *Анатолий Борисович*

**композитор, пианист, педагог, заслуженный деятель искусств Марийской АССР (1968 г.), РСФСР (1974 г.), РТ (1993 г.)**

*2.6.1929, с. Пачи Тужинского района Кировской области – 8.8.2022, г. Казань*

В 1956 г. окончил Казанскую консерваторию по классам композиции и фортепиано. В 1951–1954 гг. работал пианистом в Казанском доме офицеров. С 1954 г. в Казанской консерватории, профессор (1977 г.), заведующий кафедрой композиции (1969–1991 гг.). Автор произведений различных жанров: «Детская сюита для струнного оркестра» (1960 г.), «Татарское каприччио» для симфонического оркестра (1970 г.), кантата «Песнь о храбром джигите» (на стихи М. Джалиля, 1990 г.) и др.

Премию получил в 1999 г. за монооперу «Неотосланные письма» по повести А. Кутуя и седьмую симфонию для струнных «Кара урман» (1995 г.).

---

# ЛУППОВ
## *Анатолий Борисович*

**композитор, пианист, педагог, Мари АССРның (1968), РСФСРның (1974), ТРның (1993) атказанган сәнгать эшлеклесе**

*2.6.1929, Киров өлкәсенең Туҗа районы Пачи авылы – 8.8.2022, Казан шәһәре*

1956 елда Казан консерваториясен композиция һәм фортепиано класслары буенча тәмамлый. 1951–1954 елларда Казан Офицерлар йортында пианист булып эшли. 1954 елдан — Казан консерваториясендә укыта, профессор (1977), композиция кафедрасы мөдире (1969–1991). Төрле жанрдагы әсәрләр авторы: «Кыллы оркестр өчен балалар сюитасы» (1960), симфоник оркестр өчен «Татар каприччиосы» (1970), «Батыр егет турында җыр» кантатасы (М. Җәлил шигырьләренә, 1990) һ.б.

Дәүләт бүләге 1999 елда Г.Кутуй повесте буенча «Тапшырылмаган хатлар» монооперасы (1979) һәм кыллы оркестр өчен «Кара урман» 7 нче симфониясе (1995) өчен бирелә.



# ШАЙДУЛЛИН
## *Шамиль Муртазович*

**живописец, заслуженный деятель искусств ТССР (1991 г.), народный художник РТ (1997 г.), заслуженный художник РФ (2013 г.)**

*1.8.1947, пос. Берлек Тетюшского района ТАССР – 3.8.2021, г. Казань*


Окончил Казанское художественное училище (1968 г.), Ленинградский институт живописи, скульптуры и архитектуры им. И. Е. Репина (1974 г.). В 1977–1980 гг. занимался в Творческой мастерской живописи Академии художеств СССР. Академик Петровской академии наук и искусств (2005 г.). Среди основных произведений: «Портрет поэта Г. Тукая» (1975 г.), «Под старой яблоней» (1978 г.), «В краю нефтяном. Лениногорский промысел» (1982 г.) и др.
Премию получил в 2000 г. за воплощение национального духа в изобразительном искусстве, создание художественно-философского образа татарского мира, за цикл картин «Новый Сабантуй» (1999–2006 гг.), в котором переплетаются элементы фольклора, этнографии и повседневной жизни.

# ШӘЙДУЛЛИН
## *Шамил Мортаза улы*

**нәкышьче, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык рәссамы (1997), РФнең атказанган рәссамы (2013)**

*1.8.1947, ТАССРның Тәтеш районы Берлек поселогы – 3.8.2021, Казан шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1968), И. Е. Репин исемендәге Ленинград нәкышь, скульптура һәм архитектура институтын (1974) тәмамлый. 1977–1980 елларда СССР Сынлы сәнгать академиясенең иҗат остаханәсендә шөгыльләнә. Петр I фән һәм сәнгать академиясе академигы (2005). Төп әсәрләре арасында «Шагыйрь Г. Тукай портреты» (1975), «Карт алмагач төбендә» (1978), «Мәхәббәт һәм мәңгелек» (2009), «Казан өстендә кич» (2011) һәм башкалар бар.
Дәүләт бүләге 2000 елда сынлы сәнгатьтә милли рухны гәүдәләндергән, татар дөньясының сәнгати-фәлсәфи образын тудырган, фольклор, этнография һәм көндәлек тормыш элементлары үрелеп барган «Яңа Сабан туе» картиналар циклы (1999–2006 гг.) өчен бирелә.



# МАЛИКОВ
*Дульфат Усманович*
*(псевдоним — Зульфат)*

**поэт,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1992 г.)**

*3.1.1947, д. Новое Саитово Муслюмовского района ТАССР – 15.5.2007, г. Казань*

Учился в Казанском университете (1965–1969 гг.). Окончил курсы при Литературном институте им. А. М. Горького (г. Москва, 1979 г.). В 1969–1974 гг. работал в журнале «Чаян» («Скорпион»), в 1979–1983 гг. — в газете «Яшь ленинчы» («Молодой ленинец»). Первые стихотворения опубликовал в коллективном сборнике «Беренче карлыгачлар» («Первые ласточки», 1968). Автор поэтических сборников «Язмышлар ярында» («У истоков судеб», 1971), «Утлы бозлар» («Огненные льды», 1978), «Осенние костры» (1985), «Адашкан болыт» («Сжигание корней», 1990), «Ике урман арасы» («Среди лесов», 1995) и др.

Премию получил в 2000 г. за книги «Ике урман арасы» («Среди лесов», 1995) и «Йөрәгемне былбыл чакты» («Ужалил соловей сердце мое», 1999), в которых через поэтические образы воспел родную природу и сельскую жизнь, сумев сохранить и обновить татарскую поэтическую традицию.


# МАЛИКОВ
*Дөлфәт Госман улы*
*(псевдонимы — Зөлфәт)*

**шагыйрь,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1992)**

*3.1.1947, ТАССРның Мөслим районы Яңа Сәет авылы – 15.5.2007, Казан шәһәре*

Казан университетында укый (1965–1969). А. М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1979) тәмамлый. «Чаян» журналында (1969–1974), «Яшь ленинчы» газетасында (1979–1983) эшли. Тәүге шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1968) дип аталган күмәк җыентыкта басыла. «Язмышлар ярында» (1971), «Утлы бозлар» (1978), «Адашкан болыт» (1990), «Ике урман арасы» (1995) һәм башка шигъри җыентыклар авторы.

Дәүләт бүләге 2000 елда «Ике урман арасы» (1995) һәм «Йөрәгемне былбыл чакты» (1999) китаплары өчен бирелә. Аларда тупланган әсәрләрендә әдип поэтик образлар аша газиз табигатькә һәм авыл тормышына дан җырлый.



## АХМЕТЗЯНОВ
*Ильдус Ханифович*

**актер,**
**народный артист РТ (1996 г.)**

*19.6.1950, с. Татарский Кандыз*
*Бавлинского района ТАССР*

После окончания Ленинградского института театра и кинематографии (1973 г.) работает в труппе Татарского академического театра им. Г. Камала. Актер создал ряд таких запоминающихся образов, как Рауф («Две невестки» Х. Вахита), Шайхель («Судьба татарки» Г. Ибрагимова), Закир, Сиражетдин («Несчастный юноша», «Банкрот» Г. Камала), Тукай («Мы уходим, вы остаетесь» Т. Миннуллина), Бадри («Галиябану» М. Файзи), Ахметзян («Зулейха» Г. Исхаки), Субра («Идегей» Ю. Сафиуллина).
Премию получил в 2000 г. за концертные программы «Сөй гомерне, сөй халыкны» («Жизнь люби, люби Отчизну») и «Өзелгән өмет» («Разбитая надежда») по произведениям Г. Тукая. Награда отметила не просто исполнительское мастерство, а глубокое, самобытное прочтение тукаевской поэзии, превращающее слово в живое переживание, выдающийся вклад в сохранение и творческое переосмысление наследия великого поэта.

## ӘХМӘТҖАНОВ
*Илдус Хәниф улы*

**актер,**
**ТРның халык артисты (1996)**

*19.6.1950, ТАССРның Баулы районы*
*Татар Кандызы авылы*

Ленинград театр һәм кинематография институтын тәмамлаганнан соң (1973), Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасында эшли. Театр сәхнәсендә Рәүф («Ике килен-килендәш», Х. Вахит), Шәйхел («Татар хатыны ниләр күрми», Г. Ибраһимов), Закир, Сираҗетдин («Бәхетсез егет», «Банкрот», Г. Камал), Тукай («Без китәбез, сез каласыз», Т. Миңнуллин), Бәдри («Галиябану», М. Фәйзи), Әхмәтҗан («Зөләйха», Г. Исхакый), Субра карт («Идегәй», Ю. Сафиуллин) һәм башка шундый истә калырлык образлар тудыра.
Дәүләт бүләге 2000 елда Г. Тукай әсәрләре буенча төзелгән «Сөй гомерне, сөй халыкны» һәм «Өзелгән өмет» концерт программалары өчен бирелә. Актерның башкару осталыгы белән беррәттән Г. Тукай шигырьләрен, һәр әйтелгән сүздә көчле кичереш ятуын үтемле итеп җиткерерлек дәрәҗәдә тирәнтен аңлап, үзенчәлекле укуы, бөек шагыйрьнең иҗат мирасын саклауга һәм яңача караш булдыруга зур өлеш кертүе билгеләп үтелә.



# СЛАВУТСКИЙ
## *Александр Яковлевич*

**актер, режиссер, педагог,**
**заслуженный деятель искусств РСФСР (1986 г.),**
**народный артист РФ (1998 г.), РТ (2011 г.)**

*24.11.1947, г. Челябинск*

Окончил студию при Челябинском драматическом театре (1968 г.), режиссерский факультет Театрального училища им. Б. В. Щукина (1974 г.). В 1969–1974 гг. режиссер Челябинского молодежного театра, в 1975–1981 гг. — Челябинского театра, в 1981–1987 гг. главный режиссер Читинского театра, в 1987–1993 гг. художественный руководитель театра г. Ростов-на-Дону. С 1994 г. главный режиссер, с 2007 г. художественный руководитель Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.
Премию получил в 2000 г. как режиссер-постановщик спектакля «Скрипач на крыше», поставленного по циклу рассказов Шолом-Алейхема «Тевье-молочник» на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова, в ходе которого труппа театра исполняла все вокальные номера вживую.

---

# СЛАВУТСКИЙ
## *Александр Яковлевич*

**актёр, режиссёр, педагог,**
**РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1986),**
**РФнең (1998), ТРның (2011) халык артисты**

*24.11.1947, Чиләбе шәһәре*

Чиләбе драма театры каршындагы студияне (1968), Б. В. Щукин исемендәге Мәскәү югары театр училищесының режиссёрлык факультетын (1974), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы югары театр курсларын (1980) тәмамлый. 1969–1974 елларда — Чиләбе яшьләр театры режиссеры, 1975–1981 елларда — Чиләбе театры режиссеры, 1981–1987 елларда — Чита театрының баш режиссеры, 1987–1993 елларда — Ростов-Дон театрының сәнгать җитәкчесе. 1994 елдан — Казан академия рус Зур драма театрының баш режиссеры, 2007 елдан — аның сәнгать җитәкчесе.
Дәүләт бүләге 2000 елда Шолом-Алейхемның «Тевье-сөт ташучы» («Тевье-молочник») хикәяләр циклы буенча “Түбәдәге скрипкачы” («Скрипач на крыше») мюзиклын (1991) режиссер-сәхнәгә куючы буларак бирелә.



# ПАТРАКОВ
## *Александр Михайлович*

**художник, мастер театрального костюма и график, заслуженный деятель искусств РСФСР (1986 г.), народный художник РТ (2002 г.)**

*22.9.1948, г. Челябинск – 6.11.2024, г. Казань*

В 1969 г. окончил Свердловское художественное училище, в 1973 г. — режиссерский курс при Государственном институте театрального искусства в Москве. С 1973 г. работал художником в театрах Челябинска, Новокузнецка, Куйбышева, Ярославля (1978–1983 гг.), Читы (1984–1987 гг.), Ростова-на-Дону (1986–1997 гг.). С 1997 г. главный художник Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.
Премию получил в 2000 г. в качестве художника-постановщика спектакля «Скрипач на крыше», поставленном по циклу рассказов Шолом-Алейхема «Тевье-молочник» на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.

# ПАТРАКОВ
## *Александр Михайлович*

**рәссам, театр костюмнары эскизлары ясау остасы һәм график, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1986), ТРның халык рәссамы (2002)**

*22.9.1948, Чиләбе шәһәре – 6.11.2024, Казан шәһәре*

1969 елда — Свердловск сынлы сәнгать училищесын, 1973 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы режиссерлык курсын тәмамлый. 1973 елдан Чиләбе, Новокузнецк, Куйбышев, Ярославль (1978–1983), Чита (1984–1987), Ростов-Дон (1986–1997) театрларында рәссам булып эшли. 1997 елдан — В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрының баш рәссамы.
Дәүләт бүләге 2000 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрында Шолом-Алейхемның «Тевье-сөт ташучы» («Тевье-молочник») хикәяләр циклы буенча куелган “Түбәдәге скрипкачы” («Скрипач на крыше») спектакленең (1991) сценографиясе өчен рәссам-сәхнәгә куючы буларак бирелә.



## ГАЛИЦКИЙ
*Михаил Олегович*

актер,
заслуженный артист РТ (1999 г.), РФ (2013 г.),
народный артист РТ (2005 г.)

*23.1.1953, г. Вичуга Ивановской области*

Окончил Ярославское театральное училище (1987 г.). В 1980–1985 гг. актер Саранского, в 1985–1992 гг. — Йошкар-Олинского театра. С 1992 г. в Казанском академическом русском Большом драматическом театре им. В. И. Качалова.
Обладает певческим голосом, музыкальностью, пластичностью, способностью соединить в едином рисунке музыкальную и драматическую характеристику образа. Премию получил в 2000 г. за исполнение главной роли Тевье в спектакле «Скрипач на крыше», поставленном по циклу рассказов Шолом-Алейхема «Тевье-молочник» на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова.

---

## ГАЛИЦКИЙ
*Михаил Олегович*

актер,
ТРның (1999), РФнең (2013) атказанган артисты,
ТРның халык артисты (2005)

*23.1.1953, Иваново өлкәсе Вичуга шәһәре*

Ярославль театр училищесын тәмамлый (1987). 1980–1985 елларда — Саранск, 1985–1992 елларда — Йошкар-Ола театрлары актеры. 1992 елдан — В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрында.
Җырлау, музыканы тою, образның музыкаль һәм драматик үзенчәлекләрен берләштерү сәләтләренә, сыгылмалылыкка ия. Дәүләт бүләге 2000 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрында Шолом-Алейхемның «Тевье-сөт ташучы» («Тевье-молочник») хикәяләр циклы буенча куелган «Түбәдәге скрипкачы» («Скрипач на крыше») спектаклендә баш рольне — Тевье ролен башкарган өчен бирелә

2001



# АХМЕТЗЯНОВ
*Роберт Валеевич*

**поэт,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1995 г.)**

*1.4.1935, с. Рыбная Слобода Рыбно-Слободского района ТАССР – 13.5.2008, г. Казань*

Окончил Казанский педагогический институт (1959 г.). В 1962–1963 гг. заведующий литературной частью Татарского театра оперы и балета им. М. Джалиля, в 1964–1968 гг. литературный сотрудник газеты «Социалистик Татарстан» («Социалистический Татарстан»). В 1958 г. выпустил первый сборник стихов «Егерменче яз» («Двадцатая весна»). В сборниках «Страна Июнь» (1979), «Хәтер елгасы» («Река памяти», 1980), «Гомер тирәге» («Древо жизни», 1985), «Җәяүле күбәләк» («Пешая бабочка», 1990) поэт раскрывается как тонкий лирик.
Премию получил в 2001 г. за поэтические сборники «Тургай тәрәзәсе» («Окошко жаворонка», 1995) и «Кичке кошлар» («Вечерние птицы», 1999), в которых проявились ключевые черты творчества поэта: гражданственно-патриотическая направленность, романтическое настроение, богатая образность и внимание к музыкальности стиха.

# ӘХМӘТҖАНОВ
*Роберт Вәли улы*

**шагыйрь,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1995)**

*1.4.1935, ТАССРның Балык Бистәсе районы Балык Бистәсе авылы – 13.5.2008, Казан шәһәре*

Казан педагогия институтын тәмамлый (1959). 1962–1963 елларда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире, 1964–1998 елларда «Социалистик Татарстан» газетасында әдәби хезмәткәр. 1958 елда «Егерменче яз» исемле беренче шигырьләр җыентыгын бастыра. «Июнь иле» (1979), «Хәтер елгасы» (1980), «Гомер тирәге» (1985), «Җәяүле күбәләк» (1990) һәм башка шигъри җыентыкларында шагыйрь нечкә хисле лирик булып ачыла.
Дәүләт бүләге 2001 елда «Тургай тәрәзәсе» (1995) һәм «Кичке кошлар» (1999) шигъри җыентыклары өчен бирелә. Әлеге җыентыклардагы әсәрләрдә шагыйрь иҗатына хас булган гражданлык-патриотик юнәлеш, романтик рух, образлар байлыгы, шигырьнең музыкаль яңгырашына игътибар, көтелмәгән чагыштырулар һәм төгәл метафоралар куллану кебек төп үзенчәлекләр күзәтелә.



# ШУТИКОВ
## *Анатолий Иванович*

**дирижер, педагог, профессор (1991 г.), заслуженный деятель искусств ТАССР (1979 г.), РСФСР (1986 г.), народный артист РФ (2007 г.)**

*6.7.1946, г. Козельск Калужской области – 20.12.2025, г. Казань*

После окончания Казанской консерватории (1971 г.), преподавал в Казанском институте культуры, был руководителем студенческих оркестров народных инструментов. В 1989–1993 гг. в Казанской консерватории. С 1993 г. художественный руководитель и главный дирижер Государственного оркестра народных инструментов РТ.
Премию получил в 2001 г. за концертные программы оркестра 1995–1999 гг., а также за выдающиеся успехи в развитии музыкального искусства Татарстана и пропаганду произведений композиторов республики. Под руководством А. И. Шутикова оркестр завоевал признание не только в Татарстане и России, но и далеко за их пределами.

# ШУТИКОВ
## *Анатолий Иванович*

**дирижер, педагог, профессор (1991), ТАССРның (1979), РСФСРның (1986) атказанган сәнгать эшлеклесе, РФнең халык артисты (2007)**

*6.7.1946, Калуга өлкәсенең Козельск шәһәре – 20.12.2025, Казан шәһәре*

Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң (1971), Казан мәдәният институтында укыта, студентлардан оешкан халык музыка уен кораллары оркестрлары белән җитәкчелек итә. 1989–1993 елларда — Казан консерваториясендә. 1993 елдан — ТР Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры.
Дәүләт бүләге 2001 елда оркестрның 1995–1999 еллардагы концерт программалары, шулай ук Татарстанның музыка сәнгатен үстерүдәге һәм республика композиторлары әсәрләрен пропагандалаудагы зур уңышлары өчен бирелә. А. И. Шутиков җитәкчелегендәге оркестр Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, алардан читтә дә танылу яулый.



# МОНАСЫПОВ
*Шамиль Хамитович*

**скрипач, педагог, кандидат искусствоведения (1983 г.), профессор (1999 г.),
заслуженный деятель искусств ТАССР (1983 г.),
народный артист РТ (1999 г.),
заслуженный артист РФ (2005 г.)**

*31.10.1944, г. Днепродзержинск, ныне г. Каменское Днепропетровской области, Украина*

В 1968 г. окончил Музыкально-педагогический институт им. Гнесиных по классу А. Маркова. В 1968–1971 гг. работал солистом Татарской филармонии и преподавателем Казанского музыкального училища. С 1970 г. преподает в Казанской консерватории. В 1979 г. организовал струнный квартет, который в 1996 г. получил статус Государственного струнного квартета РТ.
Премию получил в 2002 г. в составе Государственного струнного квартета РТ за концертные программы «Квартетная музыка Татарстана», «Татарские старинные мелодии» и «Мировая квартетная классика».

---

# МОНАСЫЙПОВ
*Шамил Хәмит улы*

**скрипкачы, педагог,
сәнгать фәннәре кандидаты (1983), профессор (1999),
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1983),
ТРның халык артисты (1999),
РФнең атказанган артисты (2005)**

*31.10.1944, Украина ССРның Днепродзержинск шәһәре*

1968 елда Гнесиннар исемендәге Дәүләт музыка-педагогия институтын (А. Марков классы) тәмамлый. 1968–1971 елларда — Татар филармониясе солисты, бер үк вакытта Казан музыка училищесында укыта. 1970 елдан Казан консерваториясендә белем бирә, 1979 елда кыллы квартет ансамблен оештыра һәм җитәкли, ул 1996 елда ТР Дәүләт кыллы квартеты статусы ала.
Дәүләт бүләге 2002 елда ТР Дәүләт кыллы квартеты составында «Татарстанның квартет музыкасы», «Борынгы татар халык көйләре» һәм «Дөнья квартет классикасы» концерт программалары белән чыгыш ясаган өчен бирелә.



# МОНАСЫПОВ
*Камиль Хамитович*

**альтист, педагог, профессор (2002 г.),**
**заслуженный деятель искусств ТССР (1991 г.),**
**народный артист РТ (1999 г.),**
**заслуженный артист РФ (2005 г.)**

*16.7.1950, г. Казань – 23.7.2025, там же*

После окончания Музыкально-педагогического института им. Гнесиных (1974 г.) артист Ансамбля Московского военного округа. С 1975 г. в Казани, преподавал в музыкальном училище и консерватории. Одновременно с 1979 г. выступал в составе струнного квартета Казанской консерватории (с 1996 г. Государственный струнный квартет РТ), гастролируя в России и за рубежом.

Премию получил в 2002 г. в составе Государственного струнного квартета РТ за концертные программы «Квартетная музыка Татарстана», «Татарские старинные мелодии» и «Мировая квартетная классика». Репертуар программ был посвящен творчеству татарских композиторов, а также включал обработки народных мелодий.

# МОНАСЫЙПОВ
*Камил Хәмит улы*

**альтчы, педагог, профессор (2002),**
**ТССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991),**
**ТРның халык артисты (1999),**
**РФнең атказанган артисты (2005)**

*16.07.1950, Казан шәһәре – 23.07.2025, шунда ук*

1974 елда Гнесиннар исемендәге Дәүләт музыка-педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Мәскәү хәрби округы ансамбле артисты була. 1975 елдан Казанда эшли, музыка училищесында һәм консерваториядә укыта. Бер үк вакытта, 1979 елдан, Казан консерваториясенең кыллы квартеты составында (1996 елдан — ТР Дәүләт кыллы квартеты) чыгышлар ясый, Россиядә һәм чит илләрдә гастрольләрдә була.

Дәүләт бүләге 2002 елда ТР Дәүләт кыллы квартеты составында «Татарстанның квартет музыкасы», «Борынгы татар халык көйләре» һәм «Дөнья квартет классикасы» концерт программалары белән чыгыш ясаган өчен бирелә. Программалар репертуары татар композиторлары иҗатына багышлана, шулай ук халык көйләре эшкәртмәләрен үз эченә ала.



# ЗАРИПОВ
## *Марат Набиевич*

**скрипач, педагог,**
**заслуженный деятель искусств ТССР (1991 г.),**
**народный артист РТ (1999 г.)**

*1.6.1956, г. Капсукас, Литовская ССР*

В 1979 г. окончил Казанскую консерваторию. В 1979–1989 гг. преподавал в Казанском музыкальном училище, с 1989 г. ведет педагогическую деятельность в Казанской консерватории. Одновременно с 1980 г. артист струнного квартета Казанской консерватории (с 1996 г. Государственный струнный квартет РТ), исполняет партию второй скрипки. Выступает в составе квартета на концертных площадках России и зарубежных стран. Редактор и составитель сборников произведений для струнного квартета.
Премию получил в 2002 г. в составе Государственного струнного квартета РТ за концертные программы «Квартетная музыка Татарстана», «Татарские старинные мелодии», «Мировая квартетная классика».

---

# ЗАРИПОВ
## *Марат Нәби улы*

**скрипкачы, педагог,**
**ТССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991),**
**ТРның халык артисты (1999)**

*1.6.1956, Литва ССРның Капсукас шәһәре*

1979 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1979–1989 елларда Казан музыка училищесында укыта, 1989 елдан Казан консерваториясендә педагогик эшчәнлек алып бара. Бер үк вакытта, 1980 елдан, Казан консерваториясе кыллы квартеты (1996 елдан — ТР Дәүләт кыллы квартеты) артисты, икенче скрипка партиясен башкара. Квартет составында Россия һәм чит ил концерт мәйданнарында чыгышлар ясый. Кыллы квартет өчен әсәрләр җыентыклары мөхәррире һәм төзүчесе.
Дәүләт бүләге 2002 елда ТР Дәүләт кыллы квартеты составында «Татарстанның квартет музыкасы», «Борынгы татар халык көйләре» һәм «Дөнья квартет классикасы» концерт программалары белән чыгыш ясаган өчен бирелә.



# АСАДУЛЛИН
## *Альберт Ахатович*

**виолончелист, педагог,
заслуженный деятель искусств ТССР (1991 г.),
народный артист РТ (1999 г.)**

*16.10.1949, г. Казань — 13.7.2020, там же*

Окончил Казанскую консерваторию (1973 г.), с 1976 г. преподавал там же. Одновременно с 1980 г. артист струнного квартета Казанской консерватории, Государственного квартета РТ (с 1996 г.). Концертировал в составе квартета в России и за рубежом.
Премию получил в 2002 г. в составе Государственного струнного квартета РТ за концертные программы «Квартетная музыка Татарстана», «Татарские старинные мелодии» и «Мировая квартетная классика».

# ӘСӘДУЛЛИН
## *Альберт Әхәт улы*

**виолончелист, педагог,
ТССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991),
ТРның халык артисты (1999)**

*16.10.1949, Казан шәһәре – 13.07.2020, шунда ук*

1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый, 1976 елдан шунда ук укыта. Бер үк вакытта, 1980 елдан, Казан консерваториясенең кыллы квартеты (1996 елдан — ТР Дәүләт кыллы квартеты) составында чыгыш ясый.
Дәүләт бүләге 2002 елда ТР Дәүләт кыллы квартеты составында «Татарстанның квартет музыкасы», «Борынгы татар халык көйләре», «Дөнья квартет классикасы» концерт программалары белән чыгыш ясаган өчен бирелә.

2002



# ЗАНКИЕВ
## *Якуб Камалеевич*

**писатель, педагог,**
**заслуженный учитель школы РСФСР (1957 г.)**

*6.4.1917, г. Иркутск – 7.3.2003, г. Тобольск*


Окончил Тюменский учительский институт (1940 г.). С 1934 г. работал учителем в школах Тюмени. В 1952–1955 гг. заведующий Тобольским районным отделом народного образования. В 1955–1975 гг. директор Епанчинской 8-летней школы Тобольского района. Автор романов о жизни сибирских татар «Иртеш таңнары» («Зори Иртыша»), «Ялкында өтелгән мәхәббәт» («Любовь, объятая пламенем») и др.
Премию получил в 2002 г. за роман «Иртеш таңнары» (1–2 книги, 1994). В центре повествования — судьба учителя Мухамеда Уразаева, чья жизнь переплетается с ключевыми событиями эпохи: Октябрьской революцией, Гражданской войной, коллективизацией и Великой Отечественной войной.

# ЗӘНКИЕВ
## *Якуб Камали улы*

**язучы, педагог,**
**РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы (1957)**

*6.4.1917, Иркутск шәһәре – 7.3.2003, Тобол шәһәре*

1940 елда Төмән укытучылар институтын тәмамлый.
1934 елдан Төмән мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1952–1955 елларда Тобол район халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1955–1975 елларда Тобол районы Хуҗайлан (Япанчы) сигезьеллык мәктәбе директоры. Себер татарлары тормышы турында «Иртеш таңнары», «Ялкында өтелгән мәхәббәт» романнары, балалар өчен «Кайчыколак» хикәяләр җыентыгы авторы.
Дәүләт бүләге 2002 елда «Иртеш таңнары» романы (1–2 китап, 1994) өчен бирелә. Ул — Себер төбәге татар әдәбиятында 1917–1940 еллардагы Иртеш буе Себер татарлары тормышына багышланган беренче масштаблы тарихи әсәр. Роман тематик киңлеге һәм этик проблемалар кискенлеге белән аерылып тора. Әсәрнең үзәгендә — тормышы чорның Октябрь инкыйлабы, Гражданнар сугышы, күмәкләштерү һәм Бөек Ватан сугышы вакыйгалары белән үрелеп барган укытучы Мөхәммәт Уразаев язмышы.



# РАФИКОВ
*Искандер Валиуллович*

**живописец,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1980 г.),**
**народный художник ТАССР (1990 г.), РФ (2007 г.)**

*5.10.1929, г. Казань – 1.10.2018, там же*

Окончил Казанское художественное училище (1949 г.), отделение станковой живописи Академии художеств Латвийской ССР в Риге (1955 г.). В 1956–1967 гг. преподавал в Казанском художественном училище, в 1967–2010 гг. — в Казанском архитектурно-строительном университете. Работал в направлении реалистического искусства.

Премию получил в 2002 г. за создание серии образов татарской женщины в картинах: «Девчата», «Скорбь матери», «В годы войны», «В гости», «Булгарская царевна», «Сююмбике-ханбике», «Портрет председателя сельсовета Н. Мотыгуллиной», «Портрет народной артистки ТАССР Г. Болгарской», «Портрет народной артистки РСФСР М. Рахманкуловой».

---

# РӘФЫЙКОВ
*Искәндәр Вәлиулла улы*

**нәкышьче,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1980),**
**ТАССРның (1990), РФнең (2007) халык рәссамы**

*5.10.1929, Казан шәһәре – 1.10.2018, шунда ук*

1949 елда Казан сынлы сәнгать училищесын, 1955 елда Латвия ССР Сынлы сәнгать академиясенең (Рига) станлы нәкышь бүлеген тәмамлый. 1956–1967 елларда — Казан сынлы сәнгать училищесында, 1967–2010 елларда Казан архитектура-төзелеш университетында укыта. Реалистик сәнгать юнәлешендә иҗат итә.

Дәүләт бүләге 2002 елда «Кызлар», «Ана хәсрәте», «Сугыш елларында», «Кунакка», «Болгар патшабикәсе», «Сөембикә-ханбикә», «Авыл советы рәисе Н. Мотыйгуллина портреты», «ТАССРның халык артисты Г. Болгарская портреты», «РСФСРның халык артисты М. Рахманкулова портреты» картиналарында татар хатын-кызы образлары сериясен иҗат иткән өчен бирелә.



# АБЯЗОВ
## *Рустем Юнусович*

**скрипач, дирижер, педагог,
заслуженный деятель искусств ТССР (1991 г.),
РФ (2005 г.), народный артист РТ (1998 г.)**

*29.3.1959, г. Казань*

В 1982 г. окончил Московскую консерваторию по классу скрипки, в 1990 г. — Казанскую консерваторию по классу композиции. В 1983–1986 гг. солист Татарской филармонии, преподаватель Казанского музыкального училища. В 1986–1996 гг. директор музыкальной школы при Казанской консерватории. С 1989 г. создатель, художественный руководитель и главный дирижер Казанского камерного оркестра La Primavera. Автор инструментальных и вокальных произведений. Среди них: вокальный цикл «Превращенный в песню» (1985 г., на стихи Р. Хариса), сюита для скрипки и симфонического оркестра «Образы Тукая» (1986 г.) и др.

Премию получил в 2003 г. за организацию и проведение концертов-посвящений С. Сайдашеву, Г. Тукаю, Н. Жиганову, Р. Яхину, а также за концертные программы «Солист — Рустем Абязов», «Юбилейный цикл», «Премьеры La Primavera», «Музыка настроений».

# АБЯЗОВ
## *Рөстәм Юныс улы*

**скрипкачы, дирижер, педагог,
ТССРның (1991), РФнең (2005) атказанган сәнгать эшлеклесе,
ТРның халык артисты (1998)**

*29.3.1959, Казан шәһәре*

1982 елда — Мәскәү консерваториясенең скрипка классын, 1990 елда Казан консерваториясенең композиция классын тәмамлый. 1983–1986 елларда — Татар филармониясе солисты, бер үк вакытта Казан музыка училищесында укыта. 1986–1996 елларда — Казан консерваториясе каршындагы музыка мәктәбе директоры. 1989 елдан «La Primavera» Казан дәүләт камера оркестрын оештыра, аның сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры. Инструменталь һәм вокаль әсәрләр авторы. Алар арасында «Җырга әверелгән» вокаль циклы (1985, Р. Харис шигырьләре), скрипка һәм симфоник оркестр өчен «Тукай моңнары» сюитасы (1986) һәм башкалар бар.

Дәүләт бүләге 2003 елда С. Сәйдәшев, Г. Тукай, Н. Җиһанов, Р. Яхинга багышланган искә алу концертларын оештырган һәм уздырган өчен, шулай ук «Солист — Рөстәм Абязов», «Юбилей циклы», «La Primavera премьералары», «Кәефләр музыкасы» концерт программалары өчен бирелә.



# ХАБИБУЛЛИН
*Мусагит*
*Мударрисович*

**писатель,**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1978 г.), РСФСР (1988 г.), народный писатель РТ (2008 г.)**

*25.12.1927, с. Габдрахман Абдуллинского района Оренбургской области – 4.1.2019, г. Казань*

Окончил Казанский университет (1971 г.). С 1967 г. работал в районной газете «Маяк» (г. Азнакаево, ТАССР), с 1969 г. преподавал историю в школе г. Ленинабад (Таджикистан). С 1971 г. в Казани, ответственный секретарь правления Союза писателей ТАССР (до 1989 г.). В 1995–1999 гг. заведующий отделом прозы в журнале «Мирас» («Наследие»). С 1950 г. публиковался в периодической печати. Автор повестей, рассказов, исторических романов.
Премию получил в 2003 г. за роман «Кубрат-хан», посвященный основателю первого тюрко-булгарского государства — Великой Болгарии. В произведении автор художественно отобразил важнейший этап исторического развития тюркских народов, их борьбу за независимость, культурные и религиозные трансформации.

# ХӘБИБУЛЛИН
*Мөсәгыйть*
*Мөдәррис улы*

**язучы,**
**ТАССРның (1978), РСФСРның (1988) атказанган мәдәният хезмәткәре,**
**ТРның халык язучысы (2008)**

*25.12.1927, Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылы – 4.1.2019, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1971). 1967 елдан «Маяк» район газетасында (Азнакай шәһәре, ТАССР) эшли, 1969 елдан Ленинабад шәһәрендә (Таҗикстан) мәктәптә тарих укыта. 1971 елдан — Казанда, ТР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе (1989 елга кадәр). 1995–1999 елларда — «Мирас» журналының проза бүлеге мөдире. 1950 еллардан вакытлы матбугатта басыла. Повестьлар, хикәяләр, тарихи романнар авторы.
Дәүләт бүләге 2003 елда Бөек Болгар дәүләтенә нигез салучы һәм идарәчесенә багышланган «Кубрат хан» романы өчен бирелә. Әсәрдә төрки халыклар тарихи үсешенең мөһим этабы, аларның бәйсезлек өчен көрәше, дини һәм мәдәни үзгәрешләре сәнгати югарылыкта сурәтләнә. Авторның әлеге әсәре — төрки-болгар дөньясының әһәмиятле тарихи сәхифәләрен торгызудагы зур казанышы.



# ЮНУСОВ (ЮНУС)
## *Мирғазиян Закирович*

**писатель, моряк**

*25.5.1927, д. Исергапово Бугульминского кантона ТАССР, ныне Бавлинский район РТ – 2.6.2014, г. Москва*

Окончил Московский университет (1961 г.). В 1944–1955 гг. служил военным летчиком в ВВС СССР, в 1957–1968 гг. помощник капитана торгового судна Черноморского пароходства, в 1968–1972 гг. заведующий отделом в Министерстве морского флота СССР, с 1973 г. в редакции журнала «Наука и религия». В 1977–1987 гг. плавал на судах Азовского морского пароходства. Начал печататься в 1960 г. Автор рассказов и повестей о жизни и труде моряков, дальних морях и странах.

Премию получил в 2004 г. за книгу «Судьба альбатроса» (2002). Обращаясь к истокам тюркской цивилизации, автор через символический образ альбатроса — сильной и свободолюбивой птицы — раскрыл судьбу народа, рассеянного по миру, но сохранившего свои корни.


# ЮНЫСОВ (ЮНЫС)
## *Мирғазиян Закир улы*

**язучы, диңгезче**

*25.5.1927, ТАССРның Бөгелмә кантоны, хәзер ТРның Баулы районы Исергәп авылы – 2.6.2014, Мәскәү шәһәре*

Мәскәү университетын тәмамлый (1961). 1944–1955 елларда СССР Хәрби-Һава көчләрендә хәрби очучы булып хезмәт итә, 1957–1968 елларда — Кара диңгез пароходчылыгы сәүдә корабльендә капитан ярдәмчесе, 1968–1972 елларда — СССР Диңгез флоты министрлыгында, 1973 елдан — «Наука и религия» («Фән һәм дин») журналы редакциясендә бүлек мөдире. 1977–1987 елларда Азов диңгезе пароходчылыгы корабльләрендә хезмәт итә. Әсәрләре матбугатта 1960 елдан басыла башлый. Диңгезчеләр тормышы һәм хезмәте, ерактагы диңгезләр һәм илләр турындагы хикәяләр һәм повестьлар авторы.

Дәүләт бүләге 2004 елда «Альбатрос язмышы» публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы (2002) өчен бирелә. Автор, төрки цивилизациянең башлангыч чорларына мөрәҗәгать итеп, альбатрос — көчле һәм ирек сөючән кош символик образы аша дөньяның төрле җирләренә таралган, әмма үз тамырларын саклап калган халык язмышын яктырта.



# ГИМАЕВ
## *Зуфар Фаатович*

**живописец,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2002 г.),**
**заслуженный художник РФ (2012 г.),**
**народный художник РТ (2017 г.)**

*9.1.1951, г. Наманган, Узбекская ССР – 15.2.2022, г. Казань*


Окончил Казанское художественное училище (1970 г.), Ленинградский институт живописи, скульптуры и архитектуры им. И. Е. Репина (1976 г.), творческую мастерскую живописи Академии художеств СССР в Казани (1980 г.). С 2008 г. возглавлял Союз художников РТ. Работал в жанрах тематической картины, портрета, пейзажа, натюрморта.
Премию получил в 2005 г. за создание серии портретов деятелей литературы и искусства Республики Татарстан. Работы отличаются глубиной эмоционального содержания, лиризмом и умением раскрыть характер через композицию и детали.

# ГЫЙМАЕВ
## *Зөфәр Фоат улы*

**нәкышьче,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002),**
**РФнең атказанган рәссамы (2012),**
**ТРның халык рәссамы (2017)**

*9.1.1951, Үзбәкстан ССРның Нәманган шәһәре – 15.2.2022, Казан шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1970), И. Е. Репин исемендәге Ленинград нәкышь, скульптура һәм архитектура институтын (1976), СССР Сынлы сәнгать академиясенең Казандагы иҗат остаханәсен (1980) тәмамлый. 2008 елдан ТР Рәссамнар берлеге рәисе. Тематик картиналар, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында эшли.
Дәүләт бүләге 2005 елда Татарстан Республикасының әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре портретлары сериясен иҗат иткән өчен бирелә. Әсәрләре эмоциональ эчтәлекнең тирәнлеге, лиризм һәм характерны композиция һәм детальләр аша ача белү осталыгы белән аерылып тора.



# МИНГАЛИМОВ (МИНГАЛИМ)
*Рустам Галиевич*

**поэт, драматург,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1987 г.),**
**народный поэт РТ (2010 г.)**

*15.9.1937, д. Юлдуз Камышлинского района Куйбышевской области, ныне Самарская область – 1.6.2014, г. Казань*

Окончил Казанский университет (1967 г.), Высшие литературные курсы при Союзе писателей СССР (г. Москва, 1978 г.), театральные курсы при Институте театрального искусства (г. Москва, 1980 г.). В 1967–1975 гг. литературный сотрудник, ответственный секретарь газеты «Яшь ленинчы» («Молодой ленинец»). В 1975–1977, 1989–1997 гг. литературный консультант Союза писателей РТ. Автор многочисленных поэтических сборников и пьес. Для его творчества характерны философская глубина, богатство языка, метафоричность и ритмическая свобода.
Премию получил в 2005 г. за сборник стихотворений и поэм «Дәрт чүлмәге» («Кувшин азарта», 2003), который стал итогом многолетнего творческого пути.

# МИНГАЛИМОВ (МИНГАЛИМ)
*Рөстәм Гали улы*

**шагыйрь, драматург,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987),**
**ТРның халык шагыйре (2010)**

*15.9.1937, Куйбышев өлкәсенең Камышлы районы Йолдыз авылы – 1.6.2014, Казан шәһәре*

Казан университетын (1967), СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1978), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы театр курсларын (1980) тәмамлый. 1967–1975 елларда — «Яшь ленинчы» газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип. 1975–1977, 1989–1997 елларда — ТР Язучылар берлегендә әдәби консультант. Күпсанлы шигъри җыентыклар һәм пьесалар авторы. Иҗатына фәлсәфи тирәнлек, тел, метафоралар байлыгы, ирекле ритмика хас.
Дәүләт бүләге 2005 елда, күпьеллык иҗат тәҗрибәсе нәтиҗәсе буларак, шагыйрьнең тормыш, халык язмышы турында уйланулары, шәхси кичерешләре яктыртылган «Дәрт чүлмәге» шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы (2003) өчен бирелә.



# ШАРИФУЛЛИН
## *Шамиль Камильевич*

**композитор, педагог,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1992 г.)**

*13.9.1949, пос. Фараб Чарджоуской области Туркменской ССР – 25.12.2007, г. Казань*

В 1973 г. окончил Казанскую консерваторию по классу композиции. В 1972–1982 гг. заведующий кабинетом музыки народов Поволжья, в 1982–2001 гг. преподаватель Казанской консерватории. В своем творчестве оригинально преломил татарский фольклор, связанный с исламской музыкально-поэтической культурой и музыкальным творчеством различных этнических групп татар, а также использовал музыкальные традиции неевропейских народов.

Премию получил в 2005 г. за хоровые концерты «Мөнәҗәтләр» («Мунаджаты») и «Авыл көйләре» («Деревенские напевы»), которые стали важным вкладом в развитие татарской хоровой музыки и отразили глубокое осмысление композитором национальных традиций.

# ШӘРИФУЛЛИН
## *Шамил Камил улы*

**композитор, педагог,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1992)**

*13.9.1949, Төрекмәнстан ССРның Чарджоу өлкәсе Фараб поселогы – 25.12.2007, Казан шәһәре*

1973 елда Казан консерваториясенең композиция классын тәмамлый. 1972–1982 елларда Идел буе халыклары музыкасы кабинеты мөдире, 1982–2001 елларда Казан консерваториясендә укыта. Иҗатында ислам музыкаль-поэтик культурасы һәм татарларның төрле этник төркемнәре музыкаль иҗаты белән бәйле татар фольклоры үзенчәлекле чагыла, шулай ук европалы булмаган халыкларның музыкаль традицияләре дә файдаланыла.

Дәүләт бүләге 2005 елда татар хор музыкасы үсешенә мөһим өлеш керткән һәм композиторның милли традицияләрне тирәнтен аңлавын чагылдырган «Мөнәҗәтләр» (1975) һәм «Авыл көйләре» (1977) хор концертлары өчен бирелә. Борынгы фольклор жанры саналган мөнәҗәтләр белән Европаның заманча башкару формалары (полифония, алеаторика һәм сонористика элементларын да кертеп) берләштерелгән концертлар татар музыкасында новаторлык күренешенә әверелә.

2006



# БАТУЛЛИН
*Роберт Мухлисович (псевдоним — Рабит Батулла)*

**писатель, актер, режиссер, заслуженный деятель искусств ТАССР (1985 г.), народный писатель РТ (2008 г.)**

*26.3.1938, д. Нижние Лузи Заинского района ТАССР*

Окончил Театральное училище им. М. С. Щепкина (1961 г.), Высшие режиссерские курсы при Государственном институте театрального искусства в Москве (1966 г.) и Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва, 1979 г.). В 1961–1963 гг. актер Татарского академического театра им. Г. Камала, одновременно занимался режиссурой. В 1963–1965 гг. режиссер Казанского театра кукол и детских передач Казанской студии телевидения. В 1970–1975 гг. преподавал в Казанском театральном училище и Казанском институте культуры. Литературным творчеством начал заниматься в 1960-е гг. Активно пишет в жанрах прозы и драмы. Выпустил сборник толкований аятов Корана на татарском языке (2000).

Премию получил в 2006 г. за исторические произведения «Сөембикә» («Сююмбике», 1992), «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» («Острее меча, тоньше волоска», 1996) и «Яралы бүре» («Раненый волк», 1996).

# БАТУЛЛИН
*Роберт Мөхлис улы (псевдонимы — Рабит Батулла)*

**язучы, актер, режиссер, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), ТРның халык язучысы (2008)**

*26.3.1938, ТАССРның Зәй районы Түбән Лоҗы авылы*

М. С. Щепкин исемендәге Театр училищесын (1961), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы Югары режиссерлык курсларын (1966) һәм М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1979) тәмамлый. 1961–1963 елларда Г. Камал исемендәге Татар академия театры актеры, бер үк вакытта режиссура белән шөгыльләнә. 1963–1965 елларда Казан курчак театры һәм Казан телевидение студиясендә балалар өчен тапшырулар редакциясе режиссеры. 1970–1975 елларда Казан театр училищесында һәм Казан мәдәният институтында укыта. Әдәби иҗат белән 1960 елларда шөгыльләнә башлый. Проза һәм драма жанрларында актив иҗат итә. Коръән аятьләренең татарча тәфсирен әзерләп бастыра (2000).

Дәүләт бүләге 2006 елда «Сөембикә» (1992), «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» (1996) һәм «Яралы бүре» (1996) тарихи әсәрләре өчен бирелә.

2006



# БАТЫРКАЕВА (БАТЫР-БУЛГАРИ)
*Луиза Миннигалеевна*

**композитор,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2000 г.)**

*14.8.1953, с. Бобровка Арамильского района Свердловской области*

В 1978 г. окончила Казанскую консерваторию по классу композиции. В 1981–1993 гг. работала музыкальным редактором Татарского книжного издательства. Центральное место в творчестве занимают песни и театральная музыка, симфонические и камерно-инструментальные сочинения. Автор более 400 песен и музыки к более чем 20 спектаклям.
Премию получила в 2006 г. за цикл патриотической и гражданской лирики, а также песни на историческую тематику. Среди произведений, отмеченных премией: «Кайту» («Возвращение»), «Су буеннан әнкәй кайтып килә» («Песня о матери») на стихи М. Галиева, «Мин сине шундый сагындым» («Я так соскучилась по тебе») на стихи Ф. Зиятдиновой.

# БАТЫРКАЕВА (БАТЫР-БОЛГАРИ)
*Луиза Миңнегали кызы*

**композитор,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2000)**

*14.8.1953, Свердловск өлкәсенең Арамиль районы Бобровка авылы*

1978 елда Казан консерваториясенең композиция классын тәмамлый. 1981–1993 елларда Татарстан китап нәшриятында музыкаль әдәбият мөхәррире булып эшли. Иҗатында үзәк урынны җырлар һәм театр музыкасы, симфоник һәм камера-инструменталь әсәрләре алып тора. 400 дән артык җыр һәм 20 дән артык спектакльгә музыка авторы.
Дәүләт бүләге 2006 елда патриотик һәм гражданлык лирикасы, шулай ук тарихи тематикага җыр цикллары өчен бирелә. Шулар арасында «Кайту», «Су буеннан әнкәй кайтып килә» (М. Галиев сүзләре), «Мин сине шундый сагындым» сүзләре (Ф. Зыятдинова сүзләре) җырлары бар.



# БУХАРАЕВ
*Равиль Раисович*

**поэт, прозаик,**
**драматург, переводчик,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2001 г.)**

*18.10.1951, г. Казань – 24.1.2012, г. Лондон*

Окончил Казанский университет (1974 г.). Начал печататься с 1969 г. Автор поэтических сборников: «Яблоко, привязанное к ветке» (1977), «Редкий дождь» (1980), «Знак Августа» (1983), «Время цветов» (1985), «Вокруг Тукая» (1989), «Трезвые пиры» (1990). С 1990 г. жил и работал в Лондоне. В 1992–2007 гг. был штатным сотрудником русской службы Би-би-си.
Премию получил в 2006 г. за книги «Бесконечный поезд» (2001) и «Казанские снега» (2004), которые отличаются яркой образностью, историчностью, глубокой философичностью и напряженными нравственными и религиозными исканиями.

# БОХАРАЕВ
*Равил Рәис улы*

**шагыйрь, прозаик,**
**драматург, тәрҗемәче,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001)**

*18.10.1951, Казан шәһәре – 24.1.2012, Лондон шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1974). Әсәрләре 1969 елдан басыла башлый. Шигъри җыентыклар авторы: «Яблоко, привязанное к ветке» («Ботагына бәйләнгән алма», 1977), «Редкий дождь» («Сирәк яңгыр», 1980), «Знак Августа» («Август билгесе», 1983), «Время цветов» («Чәчәкләр чоры», 1985), «Вокруг Тукая» («Тукай даирәсендә», 1989), «Трезвые пиры» («Аек мәҗлесләр», 1990). 1990 елдан Лондонда яши һәм эшли. 1992–2007 елларда — Би-би-си радиостанциясендә рус бүлегенең штатлы хезмәткәре.
Дәүләт бүләге 2006 елда «Бесконечный поезд» («Очсыз-кырыйсыз поезд», 2001) һәм «Казанские снега» («Казан карлары», 2004) шигъри җыентыклары өчен бирелә. Җыентыкка тупланган әсәрләр көчле образлылык, тарихи һәм фәлсәфи тирәнлек, киеренке әхлакый һәм дини эзләнүләр белән аерылып тора.

2006



# ГАЛИЕВ
*Марсель Баянович*

**поэт, прозаик,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1995 г.)**

*8.10.1946, с. Балтачево*
*Азнакаевского района ТАССР*

Окончил Казанский университет (1974 г.), Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва, 1985 г.). Первые стихи были опубликованы в коллективном сборнике «Беренче карлыгачлар» («Первые ласточки», 1972). В 1979 г. издан сборник его стихотворений «Еллар чалымы» («Признаки времени»). В 1980 г. выпустил первый сборник повестей и рассказов «Ул чакта» («В те времена»).
Премию получил в 2006 г. за значительный вклад в развитие татарской литературы и искусства, за сборник художественно-публицистических произведений «Догалы еллар» («Годы праведные», 1998), поэтические сборники «Кайту» («Возвращение», 2000), «Гомер бизмәне» («Запах полыни», 2004).

# ГАЛИЕВ
*Марсель Баян улы*

**шагыйрь, прозаик,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1995)**

*8.10.1946, ТАССРның Азнакай районы*
*Балтач авылы*

Казан университетын (1974) һәм Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1985) тәмамлый. Беренче шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1972) исемле күмәк җыентыкта басыла. 1979 елда «Еллар чалымы» шигъри җыентыгы нәшер ителә. 1980 елда «Ул чакта» исемле беренче повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы басыла.
Дәүләт бүләге 2006 елда татар әдәбияты һәм сәнгате үсешенә зур өлеш керткән, «Догалы еллар» (1998) әдәби-публицистик әсәрләр җыентыгы, «Кайту» (2000), «Гомер бизмәне» (2004) шигъри җыентыклары өчен бирелә.



## ИНДЮХОВ
### *Николай Петрович*

**живописец,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1999 г.)**

*17.4.1932, с. Ломовое Моховского района Орловской области – 5.4.2009, г. Казань*

Окончил Казанское художественное училище (1965 г.). Организатор и руководитель изостудии при Доме культуры им. М. С. Урицкого в Казани (1963–1975 гг.). В 1960–1970-е гг. работал преимущественно в жанре тематической картины — «Праздник в татарской деревне» (1969 г.), «Урожай» (1972 г.), «Будни нефтяников» (1973 г.) и др.

Премию получил в 2006 г. за серию лирических пейзажей («Березка», «Стожок», «На току», «Последний снег», «Теплый день», «Одуванчики», «Синий март», «Веселый март», «Облачный день», «Полевые цветы», «Тропинка», «Апрель», «Снегопад»).

---

## ИНДЮХОВ
### *Николай Петрович*

**нәкышьче,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1999)**

*17.4.1932, Орёл өлкәсенең Моховое районы Ломовое авылы – 5.4.2009, Казан шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1965). Казандагы М. С. Урицкий исемендәге мәдәният йортында сынлы сәнгать студиясе оештыра һәм аның белән җитәкчелек итә (1963–1975). 1960–1970 елларда башлыча тематик жанрдагы картиналар иҗат итә: «Татар авылында бәйрәм» (1969), «Уңыш» (1972), «Нефтьчеләрнең тынгысыз хезмәте» (1973) һ.б.

Дәүләт бүләге 2006 елда лирик пейзажлар сериясе («Каенкай», «Печән кибәне», «Колхозның ындыр табагында», «Соңгы кар», «Җылы көн», «Тузганаклар», «Зәңгәр март», «Күңелле март», «Болытлы көн», «Кыр чәчәкләре», «Сукмак», «Апрель», «Кар яуганда») өчен бирелә.

2006



# МУСТАФИН
*Рафаэль Ахметович*

**литературовед, критик,
кандидат филологических наук (1971 г.),
заслуженный работник культуры ТАССР (1985 г.)**

*14.5.1931, пос. Бавлы Бавлинского района ТАССР –
14.4.2011, г. Казань*

Окончил Казанский университет (1954 г.). В 1961–1963 гг. главный редактор литературно-художественных программ Казанской студии телевидения, в 1965–1969 гг. главный редактор журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), в 1968–1991 гг. преподаватель Казанского университета, с 1991 г. главный редактор журнала «Татарстан», с 1997 г. заведующий отделом литературы и искусства газеты «Казанские ведомости», с 2001 г. заведующий отделом литературы и искусства журнала «Татарстан». Автор книг, посвященных жизни и творчеству поэта М. Джалиля: «Поиск продолжается» (1965, в соавторстве), «По следам поэта-героя» (1971).
Премию получил в 2006 г. за сборник документальных повестей «По следам оборванной песни» («Өзелгән җыр эзеннән», 1982).

# МОСТАФИН
*Рафаэль Әхмәт улы*

**әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе,
филология фәннәре кандидаты (1971),
ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985)**

*14.5.1931, ТАССРның Баулы районы Баулы поселогы –
14.4.2011, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1954). 1961–1963 елларда — Казан телевидение студиясенең әдәбият-сәнгать тапшырулары баш мөхәррире, 1965–1969 елларда — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, 1968–1991 елларда Казан университетында укыта, 1991 елдан — «Татарстан» журналының баш мөхәррире, 1997 елдан — «Казанские ведомости» газетасының, 2001 елдан — «Татарстан» журналының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире. М. Җәлилнең тормышы һәм иҗатына багышланган китаплар авторы: «Поиск продолжается» («Эзләнү дәвам итә», 1965, автордаш), «По следам поэта-героя» («Герой шагыйрь эзләреннән», 1971).
Дәүләт бүләге 2006 елда документаль повестьлар тупланган «Өзелгән җыр эзеннән» китабы (1982) өчен бирелә.

2006



# ХАЛИКОВ
## *Фиринат Гаптухаевич*

**живописец,
заслуженный деятель искусств РТ (2001 г.),
действительный член Российской академии художеств (2019 г.; член-корреспондент с 2012 г.)**

*28.8.1957, г. Донецк, Украинская ССР*

Окончил Кировское художественное училище им. А. А. Рылова (1984 г.), Творческую мастерскую живописи Российской академии художеств (1996 г.). Творческую деятельность начинал как пейзажист, создав серию полотен «Умирающая деревня» (1982–1993 гг.). В 1992 г. переехал в Казань, где начал работать над масштабными историческими полотнами, посвященными эпохе Казанского ханства. В 2008–2015 гг. главный художник Московской соборной мечети. В 2014–2022 гг. руководил Творческой мастерской живописи Российской академии художеств в Казани.
Премию получил в 2006 г. за серию исторических полотен «Вечная Казань» (1995–2003 гг.). Эта награда стала признанием его вклада в сохранение и воссоздание образа тысячелетнего города, в развитие исторической живописи в Татарстане.

# ХАЛИКОВ
## *Фиринат Гаптухай улы*

**нәкышьче,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001),
Россия Сәнгать академиясе академигы (2019; 2012 елдан — мөхбир-әгъза)**

*28.8.1957, Украина ССРның Донецк шәһәре*

А. А. Рылов исемендәге Киров сынлы сәнгать училищесын (1984), Россия Сынлы сәнгать академиясенең Нәкышь иҗат остаханәсен (1996) тәмамлый. Иҗат юлын пейзажлар ясаудан башлый, «Үлеп баручы авыл» картиналар сериясен (1982–1993) иҗат итә. 1992 елда Казанга күчеп килә, биредә тарихи темаларга мөрәҗәгать итә, күпчелек картиналары Казан ханлыгы чорын тасвирлауга багышлана. 2008–2015 еллардан — Мәскәү Җамигъ мәчетенең баш рәссамы. 2014–2022 елларда Казандагы Россия Сынлы сәнгать академиясенең Нәкышь иҗат остаханәсе белән җитәкчелек итә.
Дәүләт бүләге 2006 елда «Мәңгелек Казан» (1995–2003) тарихи картиналар сериясе өчен бирелә. Әлеге бүләк аның меңьеллык шәһәр образын саклау һәм торгызуга, Татарстанда тарихи нәкышь сәнгатен үстерүгә керткән өлешен тану була.

2007



# ВАЛЕЕВ
## *Разиль Исмагилович*

**писатель, общественный деятель,
кандидат исторических наук (2005 г.),
заслуженный работник культуры ТАССР (1990 г.),
РФ (1997 г.), народный поэт РТ (2011 г.)**

*4.1.1947, д. Ташлык Шереметьевского района ТАССР, ныне Нижнекамский район РТ – 20.10.2023, г. Казань*

Окончил Литературный институт им. М. Горького в Москве (1972 г.). С 1972 г. литературный сотрудник, с 1976 г. ответственный секретарь журнала «Ялкын» («Пламя»). С 1981 г. ответственный секретарь Набережночелнинской организации Союза писателей ТАССР. С 1984 г. заместитель председателя правления Союза писателей ТАССР. В 1986–2000 гг. директор Национальной библиотеки РТ. В 2000–2019 гг. председатель Комитета Государственного Совета РТ по культуре, науке, образованию и национальным вопросам.
Премию получил в 2007 г. за сборник прозаических произведений «Иске сәгать дөрес йөри» («Старые часы ходят верно», 2004) и книгу песен «Ядкарь» («Наследие», 2005).

# ВӘЛИЕВ
## *Разил Исмәгыйль улы*

**язучы, җәмәгать эшлеклесе,
тарих фәннәре кандидаты (2005),
ТАССРның (1990), РФнең (1997) атказанган
мәдәният хезмәткәре, ТРның халык шагыйре (2011)**

*4.1.1947, ТАССРның Ширәмәт, хәзер ТРның Түбән Кама районы Ташлык авылы – 20.10.2023, Казан шәһәре*

М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый (Мәскәү, 1972). 1972 елдан — «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр, 1976 елдан — җаваплы сәркатип. 1981 елдан — ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы оешмасы җаваплы сәркатибе. 1984 елдан — ТАССР Язучылар берлегенең идарә рәисе урынбасары. 1986–2000 елларда — ТР Милли китапханәсе директоры. 2000–2019 елларда — ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе.
Дәүләт бүләге 2007 елда проза әсәрләреннән торган «Иске сәгать дөрес йөри» җыентыгы (2004) һәм «Ядкарь» җырлар китабы (2005) өчен бирелә. Әлеге бүләк әсәрләрендә татар халкының милли рухын, тарихи үткәнен һәм бүгенгесен тирәнтен чагылдырган язучының күпьеллык иҗат эшчәнлегенә лаеклы бәя булып тора.

2007



# КАЛИМУЛЛИН
*Рашид Фагимович*

**композитор, педагог,
заслуженный деятель искусств ТССР (1990 г.), РФ (1996 г.),
народный артист РТ (2004 г.), РФ (2007 г.)**

*6.5.1957, г. Зеленодольск, ТАССР*


В 1985 г. окончил Казанскую консерваторию по классу Б. Трубина. В 1989–2024 гг. председатель правления Союза композиторов РТ, в 2015–2017 гг. председатель Союза композиторов России, с 2017 г. председатель правления Союза композиторов России. В 1987–2001 гг. преподавал в Казанской консерватории (в 1992–2001 гг. заведующий кафедрой композиции).
Премию получил в 2007 г. за цикл симфонических произведений: симфония для струнных «Мелодии Тукая», концерт-поэма «Казанны сагыну» («Сказание о Казани») для хора и симфонического оркестра (2004 г.), а также за симфонические произведения последних лет, которые стали важным вкладом в развитие татарской и российской музыкальной культуры.

# КӘЛИМУЛЛИН
*Рәшит Фәһим улы*

**композитор, педагог,
ТССРның (1990), РФнең (1996) атказанган сәнгать эшлеклесе,
ТРның (2004), РФнең (2007) халык артисты**

*6.5.1957, ТАССРның Зеленодольск шәһәре*

1985 елда Казан консерваториясен (Б. Трубин классы) тәмамлый. 1989–2024 елларда ТР Композиторлар берлеге идарәсе рәисе, 2015–2017 елларда — Россия Композиторлар берлеге рәисе, 2017 елдан — Россия Композиторлар берлеге Идарәсе рәисе. 1987–2001 елларда Казан консерваториясендә укыта (1992–2001 елларда — композиция кафедрасы мөдире).
Дәүләт бүләге 2007 елда татар һәм Россия музыкаль культурасын үстерүгә мөһим өлеш керткән симфоник әсәрләр циклы — кыллы уен кораллары өчен «Тукай моңнары» симфониясе, хор һәм симфоник оркестр өчен «Казанны сагыну» концерт-поэмасы (2004), шулай ук соңгы елларда иҗат ителгән симфоник әсәрләре өчен бирелә.



# НИГМАТУЛЛИНА
## *Рада Хусаиновна*

**скульптор,**
**заслуженный деятель искусств ТАССР (1984 г.),**
**народный художник РТ (2002 г.),**
**заслуженный художник РФ (2012 г.)**

*14.4.1931, г. Казань – 11.10.2019, там же*

Окончила Казанское художественное училище, мастерскую скульптуры С. С. Ахуна (1954 г.), Институт живописи, скульптуры и архитектуры им. И. Е. Репина (1960 г.). С 1960 г. работала в Татарском художественном фонде. Первая женщина-скульптор в Татарстане. Вошла в историю искусства как мастер, привнесший в скульптуру яркую национальную образность и живописную пластику.
Премию получила в 2007 г. за серию скульптурных работ «С любовью к Тукаю» (2006 г.), созданную совместно с дочерьми — Изабеллой Рогожиной и Мариной Нигматуллиной.

# НИГЪМӘТУЛЛИНА
## *Рада Хөсәен кызы*

**сынчы,**
**ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984),**
**ТРның халык рәссамы (2002),**
**РФнең атказанган рәссамы (2012)**

*14.4.1931, Казан шәһәре – 11.10.2019, шунда ук*

1954 елда — Казан сынлы сәнгать училищесын (С. С. Ахунның скульптура остаханәсе), 1960 елда И. Е. Репин исемендәге Нәкышь, скульптура һәм архитектура институтын тәмамлый. 1960 елдан Татарстан сәнгать фондында эшли. Ул — Татарстанда беренче хатын-кыз сынчы. Сынлы сәнгать тарихында иҗади үзенчәлеккә ия булган, якты милли образлылык алып килеп, пластикага нәфислек рухы өргән әйдәп баручы уеп бизәү остасы буларак урын ала.
Дәүләт бүләге 2007 елда кызлары Изабелла Рогожина һәм Марина Нигъмәтуллина белән берлектә иҗат ителгән «Тукайга мәхәббәт илә» скульптур эшләр сериясе (2006) өчен бирелә. 40 тан артык фигуралы композицияне үз эченә алган әлеге тупланма халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукай исемен мәңгеләштерүгә һәм татар сынлы сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә.

2007



# РОГОЖИНА
*Изабелла Викторовна*

**скульптор,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1996 г.)**

*31.12.1957, г. Казань*

В 1990 г. окончила Московский художественный институт им. В. И. Сурикова. Член Союза художников России (с 1992 г.). Среди проектов, в которых участвовала, — памятники композитору С. Садыковой, режиссеру М. Салимжанову, драматургу Г. Камалу, певцу Ф. Шаляпину и художнику И. Шишкину.
Премию получила в 2007 г. в составе авторской группы (совместно с Радой и Мариной Нигматуллиными) за серию скульптурных работ «С любовью к Тукаю» (2006 г.).

# РОГОЖИНА
*Изабелла Викторовна*

**сынчы,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1996)**

*31.12.1957, Казан шәһәре*

Сынчылар Рада Нигъмәтуллина белән Виктор Рогожинның кызы. 1990 елда В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын тәмамлый. Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992). Композитор С. Садыйкова, режиссер М. Сәлимҗанов, драматург Г. Камал, шулай ук җырчы Ф. Шаляпин һәм рәссам И. Шишкин һәйкәлләрен ясауда катнаша.
Дәүләт бүләге 2007 елда авторлар төркеме составында (Рада һәм Марина Нигъмәтуллиналар белән берлектә) «Тукайга мәхәббәт илә» скульптур эшләр сериясе (2006) өчен бирелә.



## НИГМАТУЛЛИНА
*Марина Викторовна*

**скульптор,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2017 г.)**

*5.9.1961, г. Казань*

В 1988 г. окончила Московский художественный институт им. В. И. Сурикова. С 1989 г. член Союза художников России. Премию получила в 2007 г. в составе авторской группы (совместно с Радой Нигматуллиной и Изабеллой Рогожиной) за серию скульптурных работ «С любовью к Тукаю» (2006 г.).

## НИГЪМӘТУЛЛИНА
*Марина Викторовна*

**сынчы,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2017)**

*5.9.1961, Казан шәһәре*

Сынчылар Рада Нигъмәтуллина һәм Виктор Рогожинның кызы. 1988 елда В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын тәмамлый. 1989 елдан Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. Дәүләт бүләге 2007 елда авторлар төркеме составында (Рада Нигъмәтуллина һәм Изабелла Рогожина белән берлектә) «Тукайга мәхәббәт илә» скульптур эшләр сериясе (2006) өчен бирелә.

2008



## ФАТХУТДИНОВ
*Салават Закиевич*

**певец,**
**народный артист РТ (1995 г.), Республики Башкортостан (2019 г.),**
**заслуженный артист РФ (2005 г.)**

*10.1.1960, д. Аксаитово Татышлинского района Башкирской АССР*

Окончил Казанский институт культуры (1989 г.). В 1977–1989 гг. руководитель культурно-просветительских учреждений Татышлинского района Республики Башкортостан, в 1989–2000 гг. руководитель и солист Набережночелнинского экспериментального концертного объединения, с 1992 г. организатор и руководитель театра песни «Салават». С 2002 г. заведующий кафедрой татарской театральной эстрады Казанского института культуры.
Премию получил в 2008 г. за концертные программы последних лет и исполнение песни «Мин яратам сине, Татарстан» («Я люблю тебя, Татарстан», стихи Р. Ракипова, музыка Р. Андреева).

## ФӘТХЕТДИНОВ
*Салават Зәки улы*

**җырчы,**
**ТРның (1995), БРның (2019) халык артисты,**
**РФнең атказанган артисты (2005)**

*10.1.1960, БАССРның Тәтешле районы Аксәет авылы*

Казан мәдәният институтын тәмамлый (1989). 1977–1989 елларда Башкортстан Республикасының Тәтешле районында мәдәни-агарту учреждениеләре белән җитәкчелек итә, 1989–2000 елларда Чаллы эксперименталь концерт берләшмәсенең концерт төркеме җитәкчесе һәм солисты, 1992 елдан «Салават» җыр театрын оештыручы һәм аның җитәкчесе. 2002 елдан Казан мәдәният институтының татар театр эстрадасы кафедрасы мөдире.
Дәүләт бүләге 2008 елда соңгы еллардагы концерт программалары һәм «Мин яратам сине, Татарстан» җырын (Р. Рәкыйпов сүзләре, Р. Андреев көе) башкарган өчен бирелә.



# АНДРЕЕВ
*Роберт Егорович*

**композитор, баянист, певец,**
**заслуженный работник культуры РТ (2002 г.)**

*5.4.1956, д. Баткак Сармановского района ТАССР*

Окончил Альметьевский строительный техникум (1975 г.), Казанский институт культуры (1991 г.), Альметьевское музыкальное училище (2003 г.). С 1978 г. работал в управлении «Татнефтегазпереработка», на насосном заводе в г. Альметьевске. С 1982 г. заместитель директора по культурно-просветительской работе в санатории «Ромашкино» ПАО «Татнефть» (Заинский район), в 1996–2020 гг. ведущий инженер по организации досуга.
Премию получил в 2008 г. за авторство песни «Мин яратам сине, Татарстан» («Я люблю тебя, Татарстан») на стихи Р. Ракипова (1990 г.). Эта композиция стала народным гимном и символом республики.

---

# АНДРЕЕВ
*Роберт Егорович*

**композитор, баянчы, җырчы,**
**ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2002)**

*5.4.1956, ТАССРның Сарман районы Баткак авылы*

Әлмәт төзелеш техникумын (1975), Казан мәдәният институтын (1991), Әлмәт музыка училищесын (2003) тәмамлый. 1978 елдан «Татарстан нефть һәм газ эшкәртү» идарәсендә, Әлмәттә насос заводында эшли. 1982 елдан «Татнефть» ГАЖнең «Ромашкино» санаториендә (Зәй районы) мәдәни-агарту эшләре буенча директор урынбасары, 1996–2020 елларда ялны оештыру буенча әйдәп баручы инженер.
Дәүләт бүләге 2008 елда халык гимнына һәм республика символына әверелгән «Мин яратам сине, Татарстан» (1990, Р. Рәкыйпов сүзләре) җырының көй авторы буларак бирелә.



# РАКИПОВ
## *Роберт Зиганшевич*

**поэт**

*10.11.1936, с. Новые Чукалы Дрожжановского района ТАССР – 4.5.1995, г. Альметьевск*

Окончил Казанский университет (1970 г.). В 1969–1974 гг. работал заведующим учебной частью, директором средних школ в Дрожжановском районе. С 1974 г. жил в г. Альметьевске, преподавал в школе-интернате. Автор поэтических сборников «Сагыну» («Берег мой», 1981), «Сиңа гына ачам күңелемне» («Откроюсь только тебе», 1983), «Яшьлегем башкаласы» («Столица моей юности», 1985), «Җилкәннәрдә зәңгәр җилләр» («На парусах — синие ветра», 1986), «Хәтер урамы» («Улица памяти», 1988).

Премия присуждена в 2008 г. (посмертно) за авторство песни «Мин яратам сине, Татарстан» («Я люблю тебя, Татарстан», 1990 г., музыка Р. Андреева). Эта композиция стала народным гимном и символом республики.

# РӘКЫЙПОВ
## *Роберт Җиһанша улы*

**шагыйрь**

*10.11.1936, ТАССРның Чүпрәле районы Яңа Чокалы авылы – 4.5.1995, Әлмәт шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1970). 1969–1974 елларда Чүпрәле урта мәктәпләрендә уку-укыту бүлеге мөдире, соңрак мәктәп директоры булып эшли. 1974 елдан Әлмәттә яши, интернат-мәктәптә белем бирә. «Сагыну» (1981), «Сиңа гына ачам күңелемне» (1983), «Яшьлегем башкаласы» (1985), «Җилкәннәрдә зәңгәр җилләр» (1986), «Хәтер урамы» (1988) шигъри җыентыклары авторы. Иҗатының төп темасы — туган җиргә мәхәббәт. Күп кенә шигырьләренә Әлмәт композиторлары көй яза.

Дәүләт бүләге 2008 елда халык гимнына һәм республика символына әверелгән «Мин яратам сине, Татарстан» (1990, Р. Андреев көе) җырының авторы буларак бирелә (вафатыннан соң).



# ГАТАУЛЛИН
*Радиф Кашфуллович*
*(псевдоним —*
*Радиф Гаташ)*

поэт,
заслуженный работник культуры ТАССР (1982 г.),
заслуженный деятель искусств РТ (2001 г.),
народный поэт РТ (2012 г.)

*30.3.1941, д. Марс Кушнаренковского района*
*Башкирской АССР*

Окончил Казанский университет (1964 г.), Высшие литературные курсы при Литературном институте им. М. Горького (г. Москва, 1969 г.). В 1966–1971 гг. (с перерывом) работал редактором художественной литературы Татарского книжного издательства, в 1973–1974 гг. литературный сотрудник журнала «Ялкын» («Пламя»). В 1975–2011 гг. заведующий отделом поэзии журнала «Казан утлары» («Огни Казани»). Начал печататься в 1962 г.
Премию получил в 2008 г. за знаковые в его творчестве книги «Газәлләр» («Газели», 2001), «Мәңгелек сусау» («Жажда вечности», 2005), которые внесли значительный вклад в развитие татарской поэзии.

---

# ГАТАУЛЛИН
*Рәдиф Кәшфулла улы*
*(псевдонимы —*
*Рәдиф Гаташ)*

шагыйрь,
ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1982),
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001),
ТРның халык шагыйре (2012)

*30.3.1941, БАССРның Кушнаренко районы Марс авылы*

Казан университетын (1964), Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (1969) тәмамлый. 1966–1971 елларда (бүленеп) — Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире, 1973–1974 елларда — «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр, 1975–2011 елларда — «Казан утлары» журналының шигърият бүлеге мөдире. Шигъри әсәрләре 1962 елдан матбугатта басыла башлый.
Дәүләт бүләге 2008 елда татар шигърияте үсешенә зур өлеш керткән һәм әдип иҗатының әһәмиятен билгеләгән «Газәлләр» (2001), «Мәңгелек сусау» (2005) китаплары өчен бирелә.

2008



# АРШИНОВ
*Виктор Петрович*

график, живописец,
заслуженный деятель искусств РТ (1993 г.),
народный художник РТ (2005 г.)

*22.10.1945, г. Баку*

Окончил Московское областное художественное училище памяти 1905 года (1970 г.). С 1970 г. работал художником-проектировщиком на Казанском комбинате торговой рекламы, с 1974 г. — в Художественном фонде. С 1976 г. член правления Союза художников РТ. С 2013 г. возглавляет отделение Союза художников России в РТ. Творческая деятельность охватывает книжную и журнальную графику, живопись, скульптуру, театрально-декорационное и монументально-декоративное искусство.
Премию получил в 2008 г. за графическую серию «Бессмертная песня», посвященную стихам Мусы Джалиля из «Моабитских тетрадей».

# АРШИНОВ
*Виктор Петрович*

график, нәкышьче,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993),
ТРның халык рәссамы (2005)

*22.10.1945, Баку*

1905 ел истәлеге исемендәге Мәскәү өлкә сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1970). 1970 елдан — Казан сәүдә рекламасы комбинатында рәссам-проектлаучы, 1974 елдан Сәнгать фондында эшли. 1976 елдан — Татарстан Рәссамнар берлегенең идарә әгъзасы. 2013 елдан Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлеген җитәкли. Иҗаты китап һәм журнал графикасын, нәкышь, скульптура, театр-декорация һәм монументаль-гамәли-бизәлеш сәнгатен колачлый.
Дәүләт бүләге 2008 елда Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләренә багышланган «Үлемсез җыр» график сериясе өчен бирелә.

2008



## АХИЯРОВА
*Резеда Закиевна*

**композитор,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1993 г.),**
**РФ (2003 г.), народная артистка РТ (2006 г.)**

*1.6.1956, д. Верхнее Яркеево Илишевского района Башкирской АССР*

Окончила Казанскую консерваторию по классу композиции у Р. Белялова (1980 г.). Автор многих произведений различных жанров: симфонической, вокально-симфонической, театральной, камерно-инструментальной и вокальной музыки. На сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля были поставлены оперы композитора «Любовь поэта» и «Сююмбике», а также балеты «Золотая Орда» и «Иакинф», созданные в сотрудничестве с поэтом Ренатом Харисом.
Премию получила в 2008 г. за написанную с опорой на национальные традиции оперу «Любовь поэта» и цикл симфонических произведений.

## АХИЯРОВА
*Резеда Зәки кызы*

**композитор,**
**ТРның (1993), РФнең (2003) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык артисты (2006)**

*1.6.1956, БАССРның Илеш районы Югары Яркәй авылы*

Казан консерваториясен (Р. Беляловның композиция классы) тәмамлый (1980). Төрле жанрдагы музыкаль әсәрләр — симфоник, вокаль-симфоник, камера-инструменталь һәм вокаль музыка, театр музыкасы һ.б. авторы. М.Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә композиторның «Шагыйрь мәхәббәте» һәм «Сөембикә» опералары, шулай ук шагыйрь Ренат Харис белән хезмәттәшлектә иҗат ителгән «Алтын Урда» һәм «Иакинф» балетлары куела.
Дәүләт бүләге 2008 елда милли традицияләргә таянып язылган, музыка теленең үзенчәлеге, мелодикасының байлыгы белән аерылып торган «Шагыйрь мәхәббәте» операсы һәм симфоник әсәрләр циклы өчен бирелә.

2008



## АГАДИ
*Ахмед Эльтифадоглы*

**певец (тенор),**
**заслуженный артист РФ (1999 г.),**
**народный артист РТ (2001 г.)**

*30.3.1965, д. Совхоз им. 22-го партсъезда Чимкентского района Чимкентской области Казахской ССР*

После окончания Московской консерватории им. П. И. Чайковского (1993 г.) солист Московского музыкального театра им. К. Станиславского и В. Немировича-Данченко, с 2005 г. — Мариинского театра (Санкт-Петербург), одновременно выступает на многих оперных сценах мира.
Премию получил в 2008 г. за исполнение партии Тукая в первой постановке оперы «Любовь поэта» Р. Ахияровой на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

## ӘХМӘТ АГАДИ
*(тулы исеме — Агади Әхмәд Илтифад улы)*

**җырчы (лирик тенор),**
**РФнең атказанган артисты (1999),**
**ТРның халык артисты (2001)**

*30.3.1965, Казакъстан ССРның Чимкент өлкәсе Чимкент районы 22 нче партсъезд исемендәге совхоз*

П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң (1993), К. Станиславский һәм В. Немирович-Данченко исемендәге Мәскәү музыкаль театры солисты була. 2005 елдан — Мария театры (Санкт-Петербург) солисты, бер үк вакытта дөньяның күп кенә опера сәхнәләрендә чыгышлар ясый.
Дәүләт бүләге 2008 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә «Шагыйрь мәхәббәте» операсының (Р. Ахиярова) беренче куелышында Тукай партиясен башкарган өчен бирелә.



компоризитор, дирижер

*27.9.1955, г. Ленинград*

Окончил Ленинградскую консерваторию по классу контрабаса (1978 г.), затем по классу оперно-симфонического дирижирования (1986 г.). С 2000 г. преподавал в Санкт-Петербургской консерватории. Выступал как музыкальный руководитель оперных спектаклей. Дирижировал симфоническими оркестрами Чувашии, Татарстана, Санкт-Петербурга.

Премию получил в 2008 г. в составе творческой группы за постановку оперы «Любовь поэта» Р. Ахияровой на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

## СОБОЛЕВ
*Виктор Евгеньевич*

## СОБОЛЕВ
*Виктор Евгеньевич*

композитор, дирижер

*27.9.1955, Ленинград*

Ленинград консерваториясенең контрабас классын (1978), аннары опера-симфония дирижерлыгы классын (1986) тәмамлый. 2000 елдан Санкт-Петербург консерваториясендә укыта. Опера спектакльләренең музыкаль җитәкчесе вазифасын башкара. Чуаш Республикасы, Татарстан Республикасы, Санкт-Петербург симфоник оркестрлары белән дирижерлык итә.

Дәүләт бүләге 2008 елда иҗат төркеме составында М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә Р. Ахиярованың «Шагыйрь мәхәббәте» операсын куйган өчен бирелә.



# ПАНДЖАВИДЗЕ
*Михаил Александрович*

**оперный режиссер**

*5.3.1969, г. Ашхабад*

Окончил Российский институт театрального искусства в Москве (1997 г.). С 2001 г. руководитель режиссерской группы Большого театра России, в 2006–2008 гг. художественный руководитель Государственного театра «Царицынская опера» (г. Волгоград), в 2010–2019 гг. главный режиссер Национального академического Большого театра оперы и балета Республики Беларусь, в 2014–2017 гг. главный режиссер Самарского академического театра оперы и балета. С 2004 г. сотрудничает с Татарским академическим театром оперы и балета им. М. Джалиля, среди поставленных на его сцене спектаклей — оперы «Борис Годунов» М. Мусоргского (2005 г.), «Риголетто» Дж. Верди (2009 г.), «Джалиль» Н. Жиганова (2011 г.) и др.
Премию получил в 2008 г. в составе творческой группы за постановку оперы «Любовь поэта» Р. Ахияровой на сцене Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.

# ПАНДЖАВИДЗЕ
*Михаил Александрович*

**опера режиссеры**

*5.3.1969, Ашхабад*

Мәскәүдәге Россия театр сәнгате институтын (ГИТИС) тәмамлый (1997). 2001 елдан — Россия Зур театрында режиссерлар төркеме җитәкчесе, 2006–2008 елларда — «Царицынская опера» дәүләт театрында (Волгоград шәһәре) сәнгать җитәкчесе, 2010–2019 елларда — Беларусь Республикасының Милли академия Зур опера һәм балет театрында баш режиссер, 2014–2017 елларда — Самара академия опера һәм балет театрында баш режиссер. 2004 елдан М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры белән хезмәттәшлек итә, аның сәхнәсендә М. Мусоргскийның «Борис Годунов» (2005), Дж. Вердиның «Риголетто» (2009), Н. Җиһановның «Җәлил» (2011) операларын куя.
Дәүләт бүләге 2008 елда иҗат төркеме составында М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры сәхнәсендә Р. Ахиярованың «Шагыйрь мәхәббәте» операсын куйган өчен бирелә.

2009



## МАНСУРОВ
*Зиннур Музипович*

**поэт,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1994 г.),**
**народный поэт РТ (2014 г.)**

*15.7.1949, д. Нижняя Ошма Мамадышского района ТАССР*

В 1972 г. окончил Казанский университет. В 1974–1983 гг. работал в газете «Социалистик Татарстан» («Социалистический Татарстан»), в 1983–1986 гг. — в редакции журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), в 1986–1990 гг. главный редактор Государственного комитета ТАССР по телевидению и радиовещанию, в 1990–1995 гг. заместитель председателя правления Союза писателей РТ, в 1995–2014 гг. главный редактор газеты «Мәдәни җомга» («Культурная пятница»). Первый поэтический сборник увидел свет в 1979 году. Творчество Зиннура Мансурова отличается глубоким лиризмом, философским осмыслением жизни и любовью к родному языку.
Премию получил в 2009 г. за сборник стихов и поэм «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» («Теплее греет раненое сердце», 2003) и книгу «Күңелдә фидаи яшәсә» («Душа беззаветности полна», 2006).

## МАНСУРОВ
*Зиннур Мөҗип улы*

**шагыйрь,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1994),**
**ТРның халык шагыйре (2014)**

*15.7.1949, ТАССРның Мамадыш районы Түбән Ушма авылы*

1972 елда Казан университетын тәмамлый. 1974–1983 елларда — «Социалистик Татарстан» газетасында, 1983–1986 елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә эшли, 1986–1990 елларда — ТАССР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитетында баш мөхәррир, 1990–1995 елларда — Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе урынбасары, 1995–2014 елларда — «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире. Беренче шигырьләр җыентыгы 1979 елда дөнья күрә. Иҗаты тирән лиризм, кичерешләр ихласлыгы, тормыш-яшәешкә фәлсәфи карашы һәм туган телгә мәхәббәт хисләре белән аерылып тора.
Дәүләт бүләге 2009 елда «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» (2003) шигырьләр һәм поэмалар, «Күңелдә фидаи яшәсә» (2006) публицистик мәкаләләр җыентыклары өчен бирелә.

2009



## ХАКИМХАНОВ
*Зульфат Зуфарович (псевдоним — Зульфат Хаким)*

**писатель,
народный писатель РТ (2020 г.)**

*11.8.1960, с. Шингальчи Нижнекамского района ТАССР*

Окончил Нижнекамский химико-технологический институт (1988 г.). С 1980 г. жил в г. Нижнекамске, в 1982–1988 гг. художественный руководитель клуба «Строитель». С 1988 г. в Казани: автор-исполнитель, певец Татарской филармонии им. Г. Тукая, заведующий литературной частью Татарского театра драмы и комедии им. К. Тинчурина. Начал печататься в 1980 г.
Премию получил в 2009 г. в составе творческой группы за постановку на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала спектакля по своему роману «Телсез куке» («Немая кукушка»), в котором поднимаются вопросы идентичности, войны и мира, нравственного выбора.

---


## ХӘКИМХАНОВ
*Зөлфәт Зөфәр улы (псевдонимы — Зөлфәт Хәким)*

**язучы,
ТРның халык язучысы (2020)**

*11.8.1960, ТАССРның Түбән Кама районы Шәңгәлче авылы*

Түбән Кама химия-технология институтын тәмамлый (1988). 1980 елдан Түбән Кама шәһәрендә яши, 1982–1988 елларда — Төзүчеләр клубында сәнгать җитәкчесе. 1988 елдан Казанда: Г. Тукай исемендәге Татар филармониясендә автор-башкаручы, җырчы, К. Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театрында әдәби бүлек мөдире. Беренче әсәрләре 1980 елда «Идел», «Сөембикә», «Чаян», «Казан утлары» журналларында басыла.
Дәүләт бүләге 2009 елда иҗат төркеме составында үзенең шәхес һәм язмыш, сугыш һәм тынычлык, әхлакый-иҗтимагый проблемалар күтәрелгән «Телсез Күке» романы буенча Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә спектакль куюда (2004) катнашкан өчен бирелә.

## 2009



# СКОМОРОХОВ
*Сергей Геннадьевич*

**театральный художник,**
**заслуженный деятель искусств ТССР (1990 г.),**
**народный художник РТ (2003 г.),**
**заслуженный художник РФ (2012 г.)**

*25.4.1952, г. Саратов*

Окончил художественное училище им. М. Б. Грекова в г. Ростове-на-Дону (1972 г.), школу-студию при МХАТ СССР им. М. Горького (1977 г.). В разные годы работал в гг. Комсомольск-на-Амуре, Хабаровск, Чита, Тверь, Тула, Нижний Новгород, Чебоксары, Йошкар-Ола, в г. Ремшайд (ФРГ). С 1984 г. главный художник Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова, с 1995 г. — Татарского академического театра им. Г. Камала.
Премию получил в 2009 г. в составе творческой группы за создание на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала отличающегося глубиной и метафоричностью визуального ряда спектакля «Телсез күке» («Немая кукушка», 2004 г.) по роману З. Хакима.

# СКОМОРОХОВ
*Сергей Геннадьевич*

**театр рәссамы,**
**ТССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1990),**
**ТРның халык рәссамы (2003),**
**РФнең атказанган рәссамы (2012)**

*25.4.1952, Саратов шәһәре*

Ростов-Дон шәһәрендәге М. Б. Греков исемендәге сынлы сәнгать училищесын (1972), М. Горький исемендәге МХАТ каршындагы мәктәп-студияне (1977) тәмамлый. Төрле елларда Комсомольск-Амур, Хабаровск, Чита, Тверь, Тула, Түбән Новгород, Чабаксар, Йошкар-Ола, Ремшайд (ГФР) шәһәрләрендә эшли. 1984 елдан — В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрының, 1995 елдан — Г. Камал исемендәге Татар академия театрының баш рәссамы.
Дәүләт бүләге 2009 елда иҗат төркеме составында Г. Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә З. Хәкимнең «Телсез Күке» романы буенча куелган спектакльнең (2004) декорация конструкциясенә һәм һәр детальгә аерым мәгънә салынган үзенчәлекле сәхнә бизәлеше өчен бирелә.



# ХАСАНОВ
*Рим Махмутович*

**композитор, заслуженный деятель искусств Башкирской АССР (1979 г.), народный артист Республики Башкортостан (2017 г.)**

*9.3.1947, с. Языково Благоварского района Башкирской АССР*

В 1973 г. окончил Уфимский институт искусств. В 1973–1978 гг. заведующий музыкальной частью Башкирского академического театра драмы им. М. Гафури. Автор балетов «Легенда о курае» (1979 г.), «Немой» (1991 г.), симфонических поэм «Прометей» (1980 г.) и «Сибай» (1982 г.), множества хоровых, камерно-инструментальных произведений, а также более 400 песен, многие из которых стали национальными шлягерами и вошли в репертуар известных исполнителей (А. Авзаловой, И. Газиева, Р. Гареева, Н. Кадыровой, Ф. Кильдияровой, И. Шакирова, Алсу).
Премию получил в 2009 г. в составе творческой группы Татарского академического театра им. Г. Камала за создание музыки к спектаклю «Телсез күке» («Немая кукушка») по роману З. Хакима.

# ХӘСӘНОВ
*Рим Мәхмүт улы*

**композитор,
БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1979),
БРның халык артисты (2017)**

*9.3.1947, БАССРның Благовар районы, Языков авылы*

1973 елда Уфа сәнгать институтын тәмамлый. 1973–1978 елларда М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының музыка бүлеге мөдире. «Курай турында легенда» (1979), «Телсез» (1991) балетлары, «Прометей» (1980), «Сибай» (1982) симфоник поэмалары, күпсанлы хор, камера-инструменталь әсәрләр, шулай ук күпчелеге, халык мәхәббәтен казанып, танылган башкаручыларның (Ә. Авзалова, И. Газиев, Р. Гәрәев, Н. Кадыйрова, Ф. Килдиярова, И. Шакиров, Алсу һ.б.) репертуарына кергән 400 дән артык җыр авторы.
Дәүләт бүләге 2009 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театры иҗат төркеме составында З. Хәкимнең «Телсез Күке» романы буенча куелган спектакльгә (2004) музыка язган өчен бирелә.

2009



# ТУХВАТУЛЛИН
## *Рамиль Чингизович*

**актер,**
**народный артист РТ (2003 г.),**
**заслуженный артист РФ (2023 г.)**

*2.10.1966, с. Аксубаево Аксубаевского района ТАССР*

После окончания Казанского театрального училища (1987 г.) был принят в труппу Татарского академического театра им. Г. Камала. Заочно окончил факультет татарской филологии (1999 г.) и юридический факультет (2008 г.) Казанского университета. С 2000 г. занимался кинорежиссурой. С 2017 г. вновь в труппе Татарского академического театра им. Г. Камала. Мастер характерных ролей (Жаграп, «Зятья Григория» Т. Миннуллина; Альфред, «Казанские парни», «Снова Казанские парни» М. Гилязова; Нурадын, «Идегей» Ю. Сафиуллина и др.). Одна из особо запомнившихся ролей — глубоко трагический образ Рахимжана («Искал тебя, любимая» Т. Миннуллина). С 2019 г. депутат Государственного Совета РТ.
Премию получил в 2009 г. в составе творческой группы Татарского академического театра им. Г. Камала за исполнение главной роли (Зиятдина) в спектакле «Телсез күке» («Немая кукушка») по роману З. Хакима.

# ТӨХФӘТУЛЛИН
## *Рамил Чыңгыз улы*

**актер,**
**ТРның халык артисты (2003),**
**РФнең атказанган артисты (2023)**

*2.10.1966, ТАССРның Аксубай районы Аксубай авылы*

Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң (1987), Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасына кабул ителә. Читтән торып, Казан университетының татар филологиясе (1999) һәм юридик (2008) факультетларын тәмамлый. 2000 елдан кино режиссурасы белән шөгыльләнә. 2017 елдан кабат — Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасында. Характерлы рольләр остасы (Җаграп, «Гөргөри кияүләре», Т. Миңнуллин; Альфред, «Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М. Гыйләҗев; Норадын, «Идегәй», Ю. Сафиуллин һ.б.). Аеруча истә калган рольләренең берсе — көчле трагизм белән сугарылган Рәхимҗан образы («Эзләдем, бәгърем, сине», Т. Миңнуллин). 2019 елдан ТР Дәүләт Советы депутаты
Дәүләт бүләге 2009 елда Г. Камал исемендәге Татар академия театры иҗат төркеме составында З. Хәкимнең «Телсез Күке» романы буенча куелган спектакльдә (2004) төп рольне (Зыятдин) башкарган өчен бирелә.

2009



# СЛАВУТСКАЯ (РОМАНОВА)

*Светлана Геннадьевна*

**актриса, педагог,**
**народная артистка РФ (2002 г.), РТ (2007 г.)**

*24.12.1952, г. Потсдам, ГДР*

В 1975 г. окончила Челябинский институт культуры. С 1975 г. актриса Челябинского, с 1981 г. — Читинского областного драматического театров, с 1986 г. — Ростовского академического театра им. М. Горького. С 1995 г. в Казанском академическом русском Большом драматическом театре им. В. И. Качалова. За годы работы в театре им. Качалова исполнила множество ведущих ролей в классическом и современном репертуаре, среди которых: Графиня («Пиковая дама» по повести А. С. Пушкина), Целия Пичем («Трёхгрошовая опера» Б. Брехта), Раневская («Вишнёвый сад» А. П. Чехова), Клара Цеханасьян («Визит дамы» Ф. Дюрренматта) и др.
Премию получила в 2009 г. за создание на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова образа Раневской в спектакле «Вишневый сад» по пьесе А. П. Чехова (2004 г.).

# СЛАВУТСКАЯ (РОМАНОВА)

*Светлана Геннадьевна*

**актриса, педагог,**
**РФнең (2002), ТРның (2007) халык артисты**

*24.12.1952, ГДР, Потсдам шәһәре*

1975 елда Чиләбе мәдәният институтын тәмамлый. 1975 елдан — Чиләбе, 1981 елдан — Чита өлкә драма театрлары, 1986 елдан — М. Горький исемендәге Ростов академия театры актрисасы. 1995 елдан В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрында. В. И. Качалов исемендәге театрда эшләгән елларында классик һәм заманча репертуардагы күпсанлы баш рольләрне башкара, алар арасында Графиня («Пики дамасы», А. С. Пушкин повесте буенча), Целия Пичем («Өч тиенлек опера», Б. Брехт), Раневская («Чия бакчасы», А. П. Чехов), Клара Цеханасьян («Дама визиты», Ф. Дюрренматт) һәм башкалар бар.
Дәүләт бүләге 2009 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры сәхнәсендә А. П. Чеховның «Чия бакчасы» пьесасы буенча куелган спектакльдә (2004) Раневская образын гәүдәләндергән өчен бирелә.



# ПРЫТКОВ
*Геннадий Николаевич*

**актер, режиссер, педагог,**
**народный артист ТАССР (1989 г.), РФ (2007 г.)**

*25.1.1948, с. Левашёво Алексеевского района ТАССР*

В 1968 г. окончил Казанское театральное училище и был принят в труппу Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова. С 1978 г. также занимается педагогической деятельностью в Казанском театральном училище и с 2001 г. — в Казанском институте культуры. За более чем полувековую карьеру исполнил множество разноплановых ролей, среди которых: Глумов («На всякого мудреца довольно простоты», А. Н. Островского), Базаров («Отцы и дети» по роману И. С. Тургенева), Воланд («Мастер и Маргарита» по роману М. А. Булгакова), Городничий («Ревизор» Н. В. Гоголя), Менахем («Поминальная молитва» Г. И. Горина) и др.

Премию получил в 2009 г. за создание на сцене Казанского академического русского Большого драматического театра им. В. И. Качалова образа Гаева в спектакле «Вишневый сад» по пьесе А. П. Чехова (2004 г.).

# ПРЫТКОВ
*Геннадий Николаевич*

**актер, режиссер, педагог,**
**ТАССРның (1989), РФнең (2007) халык артисты**

*25.01.1948, ТАССРның Алексеевск районы Левашёво авылы*

1968 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры труппасына кабул ителә. 1978 елдан — Казан театр училищесында, 2001 елдан Казан мәдәният институтында педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә. Күптөрле рольләр башкара, алар арасында Глумов («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А. Н. Островский), Базаров («Аталар һәм балалар», И. С. Тургенев романы буенча), Воланд («Мастер һәм Маргарита», М. А. Булгаков романы буенча), Городничий («Ревизор», Н. В. Гоголь), Менахем («Мәрхүмне искә алу догасы», Г. И. Горин) һәм башкалар бар.

Дәүләт бүләге 2009 елда В. И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры сәхнәсендә А. П. Чеховның «Чия бакчасы» пьесасы буенча куелган спектакльдә (2004) Гаев образын гәүдәләндергән өчен бирелә.

2009



# МУЛЛАШЁВ
*Камиль Валиахмедович*

**живописец,
заслуженный деятель искусств
Республики Казахстан (1996 г.),
народный художник РТ (2003 г.)**

*27.10.1944, г. Урумчи, провинция Синьцзян, Китай*

Окончил Институт искусств г. Урумчи (1996 г.). С 1963 г. в Казахстане. Окончил Алма-Атинское художественное училище им. Н. В. Гоголя (1967 г.), Московский художественный институт им. В. И. Сурикова (1978 г.). В 1978–1980 гг. преподавал в Алма-Атинском художественном училище, в 1980–2001 гг. работал в художественном комбинате «Онер». В работах отражены темы освоения целины и космоса, добычи нефти, экологической защиты, образы национальных героев прошлого.
Премию получил в 2009 г. за создание художественных работ «Сююмбике-ханбике», «Евразия, или Кыпчак кызы», «Сабантуй», «Думы о Родине», «У истоков Итиля».

# МУЛЛАШЁВ
*Камил Вәлиәхмәт улы*

**нәкышьче,
Казакъстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1996),
ТРның халык рәссамы (2003)**

*27.10.1944, Кытай, Шөнҗан провинциясе, Өремче шәһәре*

Өремче шәһәренең Сынлы сәнгать институтын тәмамлый (1996). 1963 елдан — Казакъстанда. Н. В. Гоголь исемендәге Алма-Ата сынлы сәнгать училищесын (1967), В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын (1978) тәмамлый. 1978–1980 елларда Алма-Ата сынлы сәнгать училищесында укыта, 1980–2001 елларда «Онер» («Һөнәр») сәнгать комбинатында эшли. Хезмәтләре чирәм җирләрне һәм галәмне үзләштерү, нефть чыгару, табигатьне саклау, борынгы каһарман образлары («Корылык», 1974; «Чабан», 1979; «Капчагай даласы», 1998; «Абай портреты», 1994; «Сөембикә ханбикә», 1997 һ.б.) һәм башка темаларга багышлана.
Дәүләт бүләге 2009 елда «Сөембикә ханбикә», «Кыпчак кызы Евразия», «Сабан туе», «Туган як хакында уйланулар», «Идел башында» сәнгать әсәрләрен иҗат иткән өчен бирелә.

2010



## ЗАЙДУЛЛИН
*Ркаил Рафаилович (псевдоним — Ркаил Зайдулла)*

**поэт, прозаик,
заслуженный деятель искусств РТ (2009 г.),
народный поэт РТ (2019 г.)**

*23.1.1962, д. Чичканы Комсомольского района Чувашской АССР*

Окончил Казанский университет (1984 г.). С 1985 г. работал корреспондентом в газете «Яшь ленинчы» («Юный ленинец»), с 1987 г. — в газете «Татарстан яшьләре» («Молодежь Татарстана»), в 1989–2009 гг. редактор отдела в журнале «Идель». Начал печататься в 1977 г. Автор поэтических сборников «Кояшлы күзләр» («Солнечные глаза», 1984), «Күрәзә» («Провидение», 1988), «Урыс кышын озату» («Проводы русской зимы», 1993). С 2021 г. председатель правления Союза писателей РТ. Депутат Государственного Совета РТ (с 2019 г.).
Премию получил в 2010 г. за поэтический сборник «Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар» («Пещера: Стихи, поэмы», 2005) и сборник прозаических произведений «Ташка ордым башны: Хикәяләр, эсселар» («Биться головой о камень: Рассказы, эссе», 2008).

---

## ЗӘЙДУЛЛИН
*Ркаил Рафаил улы (псевдонимы — Ркаил Зәйдулла)*

**шагыйрь, прозаик,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2009), Татарстанның халык шагыйре (2019)**

*23.1.1962, Чуаш АССРның Комсомол районы Чичкан авылы*

Казан университетын тәмамлый (1984). 1985 елдан — «Яшь ленинчы», 1987 елдан — «Татарстан яшьләре» газеталарында хәбәрче, 1989–2009 елларда «Идел» журналында бүлек мөхәррире булып эшли. Әсәрләре матбугатта 1977 елдан басыла башлый. «Кояшлы күзләр» (1984), «Күрәзә» (1988), «Урыс кышын озату» (1993) шигъри җыентыклары авторы. 2021 елдан — ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (2019 елдан).
Дәүләт бүләге 2010 елда «Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар» (2005) шигъри һәм «Ташка ордым башны: Хикәяләр, эсселар» (2008) проза җыентыклары өчен бирелә.

# 2010



## САДРИЕВ
*Фоат Миннеахметович*

**писатель, драматург,
заслуженный деятель искусств РТ (1991 г.),
народный писатель РТ (2014 г.)**

*10.3.1941, с. Большой Чекмак Муслюмовского района ТАССР*

Окончил Казанский университет (1965 г.), Высшие театральные курсы при Государственном институте театрального искусства (г. Москва, 1982 г.). В 1963–1970 гг. работал в районных газетах. В 1970–1972 гг. заведующий учебно-консультационным пунктом Лаишевского сельскохозяйственного техникума в с. Муслюмово. В 1972–1981 гг. редактор газеты «Авыл утлары». В 1992–1996 гг. директор Муслюмовской центральной библиотечной системы.
Премию получил в 2010 г. за трилогию «Бәхетсезләр бәхете» («Счастье несчастных», 2001, 2005, 2007), раскрывающую трагедию личности в условиях тоталитарного режима.

## САДРИЕВ
*Фоат Миңнәхмәт улы*

**язучы, драматург,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991),
ТРның халык язучысы (2014)**

*10.03.1941, ТАССРның Мөслим районы Олы Чакмак авылы*

Казан университетын (1965), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы Югары театр курсларын (1982) тәмамлый. 1963–1970 елларда район газеталарында эшли. 1970–1972 елларда — Лаеш авыл хуҗалыгы техникумының Мөслим авылындагы уку-укыту-консультация пункты мөдире. 1972–1981 елларда — «Авыл утлары» газетасы редакторы. 1992–1996 елларда — Мөслим үзәкләштерелгән китапханә системасы директоры.
Дәүләт бүләге 2010 елда «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе (2001, 2005, 2007) өчен бирелә. Трилогия тоталитар режим шартларында шәхес трагедиясен ача, җәмгыятьтәге катлаулы социаль-сәяси һәм рухи-әхлакый үзгәрешләрне чагылдыра.



# ФЕДОТОВ
## *Владимир Сергеевич*

**баянист, дирижер, педагог,
заслуженный артист ТАССР (1986 г.),
народный артист РТ (1993 г.),
заслуженный артист РФ (2001 г.)**

*13.1.1950, г. Октябрьск Куйбышевской области*

Окончил Казанскую консерваторию (1984 г.). В 1971–1976 гг. баянист Ансамбля песни и танца ТАССР, в 1976–1979 и 1988–1993 гг. концертмейстер и солист Татарской филармонии им. Г. Тукая. В 1984–1988 гг. преподаватель Казанской консерватории, с 1993 г. — Татарского гуманитарно-педагогического университета, с 2011 г. — Казанского федерального университета. Автор концертных транскрипций произведений «Попурри на татарские темы», «Тафтиляу», «Су буйлап» («По бережку») и др.

Премию получил в 2010 г. за составление и высокохудожественное исполнение концертных программ разных лет (1995–2009 гг.), в том числе «Дустыма» («Другу»), «Чарующие звуки баяна».

---

# ФЕДОТОВ
## *Владимир Сергеевич*

**баянчы, дирижер, педагог,
ТРның халык артисты (1993),
РФ атказанган артисты (2001)**

*13.01.1950, Куйбышев өлкәсенең Октябрьск шәһәре*

Казан консерваториясен (1984) тәмамлый. 1971–1976 елларда — ТАССР җыр һәм бию ансамбле баянчысы, 1976–1979 һәм 1988–1993 елларда — Г. Тукай исемендәге Татар филармониясе концертмейстеры һәм солисты. 1984–1988 елларда Казан консерваториясендә укыта, 1993 елдан — Татар гуманитар-педагогика университеты, 2011 елдан — Казан университеты укытучысы. «Татар темаларына попурри», шулай ук «Тәфтиләү», «Су буйлап» һәм башка әсәрләрнең концерт транскрипцияләре авторы.

Дәүләт бүләге 2010 елда төрле еллардагы (1995–2009) концерт программалары, шул исәптән «Дустыма», «Баянның сихри авазлары» программаларын төзегән һәм югары сәнгать дәрәҗәсендә башкарган өчен бирелә.



## МИНУЛИНА
*Асия Минвалиевна*

**скульптор,**
**художник декоративно-прикладного искусства,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2006 г.),**
**народный художник РТ (2012 г.)**

*26.11.1952, г. Ленинград*

Окончила Казанское художественное училище (1971 г.), Ленинградское высшее художественно-промышленное училище им. В. И. Мухиной (1984 г.). В 1984–1989 гг. работала в Художественном фонде ТАССР. С 2001 г. преподаватель отделения скульптуры Казанского художественного училища. Является одним из ведущих скульпторов Татарстана, успешно работает в мелкой и декоративной пластике, бытовом и портретном жанрах, монументальной скульптуре. Работает с камнем, деревом, бронзой, алюминием, керамикой.
Премию получила в 2010 г. за создание ряда скульптурных произведений, среди которых особо выделяют памятник В. И. Качалову и памятник Благотворителю в Казани.


---

## МИҢНУЛИНА
*Асия Минвәли кызы*

**сынчы, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2006),**
**ТРның халык рәссамы (2012)**

*26.11.1952, Ленинград шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1971), В. И. Мухина исемендәге Ленинград югары сәнгать-сәнәгать училищесын (1984) тәмамлый. 1984–1989 елларда ТАССР Сәнгать фондында эшли. 2001 елдан — Казан сынлы сәнгать училищесының скульптура бүлеге укытучысы. Татарстанның әйдәп баручы скульпторларыннан берсе, вак һәм декоратив пластикада, көнкүреш һәм портрет жанрларында, монументаль скульптура өлкәсендә уңышлы иҗат итә. Таш, агач, бронза, алюминий, керамика белән эшли.
Дәүләт бүләге 2010 елда скульптура әсәрләре сериясе, шул исәптән Казандагы В. И. Качалов һәйкәле (В. И. Качалов театры атриумында) һәм Хәйрияче һәйкәле өчен бирелә.



# ХАНОВ
## *Ильдар Мансавеевич*

**художник-монументалист, живописец,
скульптор, архитектор,
заслуженный деятель искусств РТ (1994 г.)**

*3.11.1940, пос. Старое Аракчино Юдинского района ТАССР – 9.2.2013, г. Москва*

Окончил Казанское художественное училище (1960 г.), Московский художественный институт им. В. И. Сурикова (1968 г.). Художник широкого творческого диапазона, один из мастеров монументального искусства. Автор живописных полотен, скульптурных композиций. Наибольшую известность как скульптор-монументалист получил благодаря работам в г. Набережные Челны: монументальные композиции из бетона и смальты «Родина-мать», «Древо жизни», «Пробуждение», «Эволюция», «Ангел-хранитель» стали смысловым и эстетическим центром города.

Премию получил в 2010 г. за серию скульптурных и монументально-декоративных композиций в городах и районах Республики Татарстан, в том числе рельеф «Расстрел» (г. Казань), памятник «Родина-мать», скульптуры «Древо жизни» (г. Набережные Челны), «Древо поэзии» (д. Новый Кырлай, Арский район РТ).

# ХАНОВ
## *Илдар Мәнсәви улы*

**рәссам-монументалист, нәкышьче,
сынчы, архитектор,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1994)**

*3.11.1940, ТАССРның Юдино районы, хәзер Казан шәһәрендәге Иске Аракчино бистәсе – 9.2.2013, Мәскәү*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1960), В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын (1968) тәмамлый. Киң иҗади диапазондагы рәссам, монументаль сәнгать осталарының берсе. Нәкышь әсәрләре, скульптур композицияләр авторы. Монументаль скульптура остасы буларак бигрәк тә Чаллы шәһәренең мәгънәви һәм эстетик үзәген тәшкил иткән эшләре: бетон һәм смальтадан эшләнгән «Ватан-ана», «Тормыш агачы», «Уяну», «Эволюция», «Сакчы фәрештә» монументаль композицияләре белән таныла.

Дәүләт бүләге 2010 елда Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарында урын алган скульптур һәм монументаль-гамәли композиция серияләре, шул исәптән «Ату» рельефы (Казан шәһәре), «Ватан-ана» һәйкәле, «Тормыш агачы» (Чаллы шәһәре) һәм «Шигърият агачы» (Арча районы Яңа Кырлай авылы) скульптуралары өчен бирелә.

2011



# ШАГИМУРАТОВА
*Альбина Анваровна*

**певица (колоратурное сопрано), народная артистка РТ (2009 г.), заслуженная артистка РФ (2017 г.)**

*17.10.1979, г. Ташкент*

Окончила Московскую консерваторию по классу Г. Писаренко (2004 г.). В 2004–2006 гг. солистка Московского музыкального театра им. К. С. Станиславского и В. И. Немировича-Данченко, с 2008 г. — Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля, с 2018 г. — Мариинского театра. В репертуаре ведущие оперные партии: Джильда, («Риголетто» Дж. Верди), Царевна-лебедь, («Сказка о царе Салтане» Н. Римского-Корсакова), Зайтуна («Любовь поэта» Р. Ахияровой); сольные партии: «Реквием» В. А. Моцарта и др.; камерно-вокальные произведения композиторов (С. Сайдашева, Н. Жиганова, Р. Яхина, А. Монасыпова) и др.
Премию получила в 2011 г. за исполнение на высочайшем уровне вокальных партий в операх западноевропейских и русских композиторов, песен и романсов татарских композиторов, народных татарских песен.

# ШАҺИМОРАТОВА
*Альбина Әнвәр кызы*

**җырчы (колоратур сопрано), Татарстанның халык артисты (2009), РФнең атказанган артисты (2017)**

*17.10.1979, Ташкент шәһәре*

Мәскәү консерваториясен (Г. Писаренко классы) тәмамлый (2004). 2004–2006 елларда — К. С. Станиславский һәм В. И. Немирович-Данченко исемендәге Мәскәү музыкаль театры, 2008 елдан — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры, 2018 елдан — Мария театры солисты. Репертуарында төп опера партияләре: Джильда («Риголетто», Дж. Верди), Аккош-патшабикә («Салтан патша турында әкият», Н. Римский-Корсаков), Зәйтүнә («Шагыйрь мәхәббәте», Р. Ахиярова); соло партияләре: В. А. Моцартның «Реквием»ы һәм башкалар; композиторларның (С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, Р. Яхин, А. Монасыйпов) камера-вокаль әсәрләре һәм башкалар.
Дәүләт бүләге 2011 елда Көнбатыш Европа һәм рус композиторлары опраларындагы вокаль партияләрне, татар композиторларының җыр һәм романсларын, татар халык җырларын югары дәрәҗәдә башкарган өчен бирелә.

2011



# КИЛЬДИБЕКОВ
*Рустем Ахмедович*

**живописец, график, монументалист,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1991 г.),**
**народный художник РТ (2006 г.),**
**заслуженный художник РФ (2011 г.)**

*30.3.1934, г. Казань – 9.11.2023, там же*

Окончил Казанское художественное училище (1954 г.), Львовский институт прикладного и декоративного искусства (1960 г.). С 1960 г. жил и работал в Казани.
Премию получил в 2011 г. за совместные произведения монументального и декоративно-прикладного искусства, созданные для интерьеров и экстерьеров общественных зданий в Республике Татарстан, и серию полотен: монументальная живопись «мозаика» и «сграффито» в гостиничных комплексах «Волга», «Татарстан», Татарском академическом театре им. Г. Камала и др.; гобелены «Труппа «Сайяр», триптих «По мотивам народных сказок»: «Су анасы», «Сак-Сок», «Шурале»; серию живописных полотен, посвященных истории и культуре татарского народа «Кукморские валенки», «Поэтессы», «Паломники», «Возвращение», «Танцующий дервиш» и др.

# КИЛДЕБӘКОВ
*Рөстәм Әхмәт улы*

**нәкышьче, график, монументалист,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991),**
**ТРның халык рәссамы (2006),**
**РФнең атказанган рәссамы (2011)**

*30.3.1934, Казан шәһәре – 9.11.2023, шунда ук*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1954), Львов гамәли-сәнгать институтын (1960) тәмамлый. 1960 елдан Казанда яши һәм иҗат итә.
Дәүләт бүләге 2011 елда иҗат төркеме составында башкарылган хезмәтләре — Татарстан Республикасының җәмәгать биналары: «Волга», «Татарстан» кунакханә комплекслары, Г. Камал исемендәге Татар академия театры һ.б. ларның интерьер һәм экстерьерлары өчен иҗат ителгән монументаль һәм гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләре — станлы нәкышь, «мозаика» һәм «сграффито»; шулай ук «Сәйяр труппасы» һәм «Халык әкиятләре буенча»: «Су анасы», «Сак-Сок», «Шүрәле» триптихы гобеленнары; татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә багышланган «Кукмара итекләре», «Шагыйрәләр», «Хаҗилар», «Кайту», «Биюче дәрвиш» нәкышь сериясе һәм башка картиналары өчен бирелә.

2011



# КИЛЬДИБЕКОВА
*Мария Семёновна*

**художник декоративно-прикладного искусства, заслуженный деятель искусств РТ (2002 г.).**

*20.7.1932, г. Одесса – 4.8.2017, г. Казань*

Окончила Львовское училище прикладного искусства (1956 г.). С 1960 г. жила и работала в Казани. С 1974 г. руководитель творческой мастерской гобелена и секции декоративно-прикладного искусства в Татарском художественном фонде. Мастер гобелена, работала в технике безворсового ковроткачества.
Премию получила в 2011 г. за совместные произведения монументального и декоративно-прикладного искусства, созданные для интерьеров и экстерьеров общественных зданий в Республике Татарстан, и серию полотен: монументальная живопись «мозаика» и «сграффито» в гостиничных комплексах «Волга», «Татарстан», Татарском академическом театре им. Г. Камала и др.; гобелены «Труппа «Сайяр», триптих «По мотивам народных сказок»: «Су анасы», «Сак-Сок», «Шурале»; серию живописных полотен, посвященных истории и культуре татарского народа «Кукморские валенки», «Поэтессы», «Паломники», «Возвращение», «Танцующий дервиш» и др.

# КИЛДЕБӘКОВА
*Мария Семёновна*

**гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002)**

*20.7.1932, Одесса шәһәре – 4.8.2017, Казан шәһәре*

Львов гамәли сәнгать училищесын тәмамлый (1956). 1960 елдан Казанда яши һәм иҗат итә. 1974 елдан Татарстан сәнгать фондында гобелен иҗат остаханәсе һәм гамәли-бизәлеш сәнгате секциясе җитәкчесе. Гобелен туку остасы, асалап туку техникасында эшли.
Дәүләт бүләге 2011 елда иҗат төркеме составында башкарылган хезмәтләре — Татарстан Республикасының җәмәгать биналары: «Волга», «Татарстан» кунакханә комплекслары, Г. Камал исемендәге Татар академия театры һ.б. ларның интерьер һәм экстерьерлары өчен иҗат ителгән монументаль һәм гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләре — станлы нәкышь, «мозаика» һәм «сграффито»; шулай ук «Сәйяр труппасы» һәм «Халык әкиятләре буенча»: «Су анасы», «Сак-Сок», «Шүрәле» триптихы гобеленнары; татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә багышланган «Кукмара итекләре», «Шагыйрәләр», «Хаҗилар», «Кайту», «Биюче дәрвиш» нәкышь сериясе һәм башка картиналары өчен бирелә.

2011



## ШАКИРЗЯНОВА
*Лена Галимзяновна (псевдоним — Лена Шагирзян)*

**поэтесса,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2000 г.),**
**народный поэт РТ (2016 г.)**

*4.6.1945, с. Поисево Актанышского района ТАССР – 16.1.2017, г. Казань*

Окончила Казанский педагогический институт (1967 г.). В 1968–1973 гг. вокалистка Государственного ансамбля песни и танца ТАССР, в 1974–1987 гг. переводчица в Государственном комитете ТАССР по телевидению и радиовещанию. В 1982 г. опубликовала первый сборник — «Мөлдерәмә күңел» («Душа переполненная»).
Премию получила в 2011 г. за сборники «Боҗра вә Хөҗрә: Шигырьләр һәм поэмалар» («Круговорот: Стихи и поэмы», 2002) и «Сагынмаклык: Багышланмалар, истәлекләр» («Дарю на память: Посвящения, воспоминания», 2005).

## ШАКИРҖАНОВА
*Лена Галимҗан кызы (псевдонимы — Лена Шагыйрьҗан)*

**шагыйрә,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2000),**
**Татарстанның халык шагыйре (2016)**

*4.6.1945, ТАССРның Актаныш районы Пучы авылы – 16.1.2017, Казан шәһәре*

Казан педагогия институтын тәмамлый (1967). 1968–1973 елларда — ТАССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле вокалисты, 1974–1987 елларда — ТАССР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитетында тәрҗемәче. 1982 елда беренче җыентыгы — «Мөлдерәмә күңел» нәшер ителә.
Дәүләт бүләге 2011 елда «Боҗра вә Хөҗрә: шигырьләр, поэмалар» (2002) һәм «Сагынмаклык: истәлекләр, багышламалар» (2005) җыентыклары өчен бирелә.

2011



## ИБРАГИМОВ
*Ильфак Мирзаевич (псевдоним — Мухаммат Мирза)*

**поэт,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2007 г.)**

*1.3.1953, с. Чалманарат Актанышского района ТАССР*

Окончил Казанский институт культуры (1975 г.). В 2001–2005 гг. заместитель министра культуры РТ, в 2005–2016 гг. председатель правления Союза писателей РТ. С 2012 г. главный редактор журнала «Чын мирас» («Настоящее наследие») (с 2013 г. — «Безнең мирас» («Наше наследие»)), в 2014–2017 гг. — журнала «Казан утлары» («Огни Казани»).
Премию получил в 2011 г. за книги «Киек каз юлында» («На Млечном Пути», 2003), «Тере су» («Живая вода», 2007) и за цикл стихотворений «Адәм баласы», вошедший в книгу «Адәм баласы» («Сын Адама», 2009). Эти работы стали знаковыми в его творчестве и отразили глубину философской мысли, мастерство в освоении восточных поэтических традиций и вклад в развитие татарской литературы.

---

## ИБРАҺИМОВ
*Илфак Мирза (Мирзамөхәммәт) улы (псевдонимы — Мөхәммәт Мирза)*

**шагыйрь,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2007)**

*1.3.1953, ТАССРның Актаныш районы Чалманарат авылы*

Казан мәдәният институтын тәмамлый (1975). 2001–2005 елларда — ТР мәдәният министры урынбасары, 2005–2016 елларда — Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе. 2012 елдан «Чын мирас» (2013 елдан — «Безнең мирас») журналының баш мөхәррире, 2014–2017 елларда — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.
Дәүләт бүләге 2011 елда «Киек каз юлында» (2003), «Тере су» (2007) китаплары һәм «Адәм баласы» китабына кергән «Адәм баласы» шигырьләр циклы өчен бирелә. Бу әсәрләр аның иҗатында үзенчәлекле эчтәлеккә ия булып, фәлсәфи фикер тирәнлеген, шәрык шигърият традицияләрен үзләштерү осталыгын һәм татар әдәбияты үсешенә керткән өлешен чагылдыра.

2012



# ГАЛИУЛЛИН
## *Зуфар Шайдуллович*

**религиозный деятель**

*1.1.1957, г. Казань*

Окончил Казанский институт культуры (1981 г.), медресе «Мир-Араб» (г. Бухара, 1992 г.), университет имени Саддама Хусейна (г. Багдад, 1997 г.). Работал в мечетях «Аль-Марджани» (с 1988 г.), «Бурнай» (с 1992 г.), «Кул Шариф» (1997–2010 гг.); с 2013 г. избран муфтием Регионального духовного управления мусульман Кировской области (Вятский муфтият).

Премию получил в 2012 г. за разработку религиозной концепции архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле.

# ГАЛИУЛЛИН
## *Зөфәр Шәйдулла улы*

**дин эшлеклесе**

*1.1.1957, Казан шәһәре*

Казан мәдәният институтын (1981), «Мир-Араб» мәдрәсәсен (Бохара шәһәре, 1992), Саддам Хөсәен исемендәге университетны (Багдад шәһәре, 1997) тәмамлый. Әл-Мәрҗани (1988 елдан), Борнай (1992 елдан), Колшәриф (1997–2010) мәчетләрендә эшли; 2013 елдан Киров өлкәсе мөселманнары төбәк диния нәзарәте (Нократ мөфтияте) мөфтие итеп сайлана.

Дәүләт бүләге 2012 елда Казан Кремлендәге, татар халкының рухи яңарышы символына, Татарстанның төп мәдәни мирас объектларының берсенә әверелгән Колшәриф мәчете архитектура комплексының дини концепциясен эшләгән өчен бирелә.

# ГОЛОВИН
## *Андрей Вячеславович*

**архитектор,**
**заслуженный архитектор РТ (2004 г.)**

*30.4.1951, г. Москва – 22.7.2024, г. Казань*

После окончания Казанского инженерно-строительного института (1973 г.) работал архитектором в Татарском научно-исследовательском и проектном институте («ТатНИПИнефть»), г. Бугульма), с 1981 г. — в «Татинвестгражданпроекте», с 2009 г. — в ООО «ПСО «Казань». По его проектам построены административное здание компании «Татойлгаз» (1991 г.), микрорайоны «1в» и «2в» (2006–2007 гг.) в г. Альметьевске, Дворец водных видов спорта в Казани (2010 г., соавтор) и др.
Премию получил в 2012 г. за вклад в создание архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (соавтор, главный архитектор проекта).

---

# ГОЛОВИН
## *Андрей Вячеславович*

**архитектор,**
**Татарстанның атказанган архитекторы (2004)**

*30.4.1951, Мәскәү – 22.7.2024, Казан шәһәре*

Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлаганнан соң (1973), Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институтында (Бөгелмә шәһәре) архитектор булып эшли, 1981 елдан — «Татинвестгражданпроект»та, 2009 елдан — «Казан» җитештерү-төзелеш берләшмәсе» ҖЧҖдә. Аның проектлары буенча «Татойлгаз»ның административ бинасы (1991), Әлмәт шәһәрендәге «1в» һәм «2в» микрорайоннары (2006–2007), Казандагы Су спорты төрләре сарае (2010, автордаш) һәм башкалар төзелә.
Дәүләт бүләге 2012 елда авторлар коллективы составында Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете архитектура комплексын төзүдә катнашкан өчен (проектның автордашы, баш архитекторы) бирелә.



# ДАИШЕВА
## *Альбина Кеновна*

**архитектор, реставратор, дизайнер**

*26.7.1961, г. Казань*

Окончила Казанский инженерно-строительный институт (1992 г.). С 1996 г. специалист Главного управления архитектуры и градостроительства главы администрации города Казани, с 2001 г. менеджер и проектировщик в Художественном фонде РТ, в 2004–2005 гг. директор ООО «ЗАБИР». С 2005 г. на кафедре интерьера Казанского архитектурно-строительного университета.

Премию получила в 2012 г. за художественное оформление интерьеров мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (разработка витражей, оформление купола, подкупольных парусов, решеток женского уровня и ограждений).

# ДАИШЕВА
## *Альбина Кен кызы*

**архитектор, реставратор, дизайнер**

*26.7.1961, Казан шәһәре*

Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый (1992). 1996 елдан Казан шәһәр хакимияте башлыгының Баш архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе белгече, 2001 елдан — ТР Сәнгать фондында менеджер һәм проектлаучы, 2004–2005 елларда — «ЗАБИР» ҖЧҖ директоры. 2005 елдан — Казан архитектура-төзелеш университетының интерьер кафедрасында.

Дәүләт бүләге 2012 елда Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете интерьерларының сәнгати бизәлешен эшләүдә катнашкан өчен (витражлар, гөмбәз һәм гөмбәз асты «өчпочмаклары», хатын-кызлар өчен билгеләнгән ярус рәшәткәләре һәм бүлемнәре эшләнеше) бирелә.

2012



# ЗАБИРОВ
*Рустем Мухамедович*

**архитектор,**
**заслуженный архитектор РТ (2011 г.)**

*7.6.1961, г. Казань*

После окончания Казанского инженерно-строительного института (1983 г.) архитектор в проектной конторе «Казжилремпроект», в 1986–1994 гг. — в институте «Казгражданпроект», в 1995–1996 гг. главный архитектор ТОО «АССАРТ», с 1996 г. главный архитектор — начальник отдела мониторинга, сохранения и реставрации Музея-заповедника «Казанский Кремль». С 1993 г. также является главным архитектором проектов реставрации в персональной творческой мастерской «Забир».
Премию получил в 2012 г. в составе авторского коллектива за участие в создании архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (осуществлял архитектурный надзор за проектом, участвовал в разработке дизайна входного узла и резных дверей в интерьере).

# ЗӘБИРОВ
*Рөстәм Мөхәммәт улы*

**архитектор,**
**Татарстанның атказанган архитекторы (2011)**

*7.6.1961, Казан шәһәре*

Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлаганнан соң (1983), «Казжилремпроект» проект конторасында архитектор, 1986–1994 елларда — «Казгражданпроект» институтында, 1995–1996 елларда — «АССАРТ» ҖЧҖнең баш архитекторы, 1996 елдан — «Казан Кремле» Музей-тыюлыгының баш архитекторы — мониторинг, саклау һәм реставрация бүлеге башлыгы. 1993 елдан шулай ук «Зәбир» шәхси иҗат остаханәсендә реставрация проектлары баш архитекторы.
Дәүләт бүләге 2012 елда авторлар коллективы составында Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете архитектура комплексын төзүдә катнашкан өчен (проектка архитектура күзәтчелеге алып бару, керү юллары һәм интерьердагы уеплап ясалган ишекләр дизайнын эшләүгә өлеш кертү) бирелә.

2012

# САДЫКОВ
*Зуфар Мазгарович*

**инженер-строитель**

*20.9.1946, г. Казань*

После окончания Казанского инженерно-строительного института (1974 г.) конструктор, главный конструктор архитектурно-планировочной мастерской (1988–2012 гг.) ГУП «Татинвестгражданпроект».
Премию получил в 2012 г. в составе авторского коллектива за участие в создании архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (соавтор и главный конструктор проектного решения).

# САДЫЙКОВ
*Зөфәр Мазһар улы*

**төзүче инженер**

*20.9.1946, Казан шәһәре*

Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлаганнан соң (1974), «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе архитектура-планлаштыру остаханәсендә конструктор, баш конструктор (1988–2012).
Дәүләт бүләге 2012 елда авторлар коллективы составында Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете архитектура комплексын төзүдә катнашкан өчен (автордаш һәм проект чишелешенең баш конструкторы) бирелә.

2012



# САЙФУЛЛИН
## *Искандэр Фуадович*

**архитектор, педагог**

*25.7.1955, г. Казань*

После окончания Московского архитектурного института (1978) работал на кафедре архитектурного проектирования Казанского инженерно-строительного института, руководитель Академической лаборатории социопространственного поиска. В 1997–2002 гг. ведущий архитектор АПМ-2 «Татинвестгражданпроект». С 2007 г. ведущий архитектор ООО «Татстройпроект». Председатель Союза архитекторов РТ (2004–2005 гг.).
Премию получил в 2012 г. в составе творческого коллектива за участие в создании архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (ведущий автор идеи воссоздания мечети и основной разработчик ее объемно-пространственного решения).

# СӘЙФУЛЛИН
## *Искәндәр Фоат улы*

**архитектор, педагог**

*25.7.1955, Казан шәһәре*

Мәскәү архитектура институтын тәмамлаганнан соң (1978), Казан төзүче инженерлар институтының архитектура-проектлау кафедрасында эшли, Академик социо-фәзаи эзләнүләр лабораториясе җитәкчесе. 1997–2002 елларда — «Татинвестгражданпроект»ның 2 нче Архитектура-планлаштыру остаханәсендә (АПМ-2) әйдәп баручы архитектор. 2007 елдан — «Татстройпроект» ҖЧҖнең әйдәп баручы архитекторы. ТР Архитекторлар берлеге рәисе (2004–2005).
Дәүләт бүләге 2012 елда иҗат коллективы составында Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете архитектура комплексын төзүдә катнашкан өчен (мәчетне торгызу идеясе авторларының берсе һәм аның күләм-фәзаи чишелешен — бинаның композициясен, масштабын, пропорцияләрен һәм Казан Кремле тирәлеге белән үзара бәйләнешен билгеләүдә, комплексның архитектур образын төзүдә хәлиткеч роль уйный) бирелә.

2012



# САТТАРОВ
*Айвар Гумарович*

**архитектор, педагог,**
**кандидат архитектуры (1985 г.),**
**заслуженный архитектор РТ (2006 г.)**

*5.5.1956, г. Тобольск Тюменской области*

После окончания Московского архитектурного института (1979 г.) преподавал в Казанском инженерно-строительном институте; в 2000–2010 гг. заведующий кафедрой реставрации и реконструкции архитектурного наследия. Одновременно с 1979 г. руководит архитектурно-проектной мастерской.
Премию получил в 2012 г. в составе творческого коллектива за участие в создании архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (автор градостроительного решения и художественно-декоративного оформления интерьера).

# САТТАРОВ
*Айвар Гомәр улы*

**архитектор, педагог,**
**архитектура фәннәре кандидаты (1985),**
**ТРның атказанган архитекторы (2006)**

*5.5.1956, Төмән өлкәсенең Тобол шәһәре*

Мәскәү архитектура институтын тәмамлаганнан соң (1979), Казан төзүче инженерлар институтында укыта; 2000–2010 елларда архитектура мирасын реставрацияләү һәм реконструкцияләү кафедрасы мөдире. Бер үк вакытта, 1979 елдан, архитектура-проект остаханәсен җитәкли.
Дәүләт бүләге 2012 елда иҗат коллективы составында Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете архитектура комплексын төзүдә катнашкан өчен (мәчетнең шәһәр төзелешендәге чишелеше һәм интерьерларының сәнгати-гамәли бизәлеше авторы) бирелә.

2012



# ШАКУРОВ
## *Сергей Петрович*

**архитектор, дизайнер, реставратор**

*4.1.1957, г. Дрогобыч Львовской области, Украина*

Окончил техническое училище №51 по специальности «Токарь-универсал», работал на заводе «Серп и молот», на стройках. В 1993 г. под эгидой Союза архитекторов РТ создал проектно-строительное предприятие «АССАРТ» — Ассоциацию содействия Союзу архитекторов Республики Татарстан (закрыта в 2014 г.). Среди значимых проектов: Северный корпус Пушечного двора в Казанском кремле (1997–1998 гг.), Белая мечеть в Болгаре (2010–2012 гг.), торговый центр «Кольцо» (2005–2006 гг., соавтор), мечеть «Ирек» (2016–2018 гг., соавтор) в Казани.
Премию получил в 2012 г. за участие в создании архитектурного комплекса мечети «Кул Шариф» в Казанском кремле (автор композиции здания, его пропорций и концепции взаимодействия с окружающим пространством).

# ШАКУРОВ
## *Сергей Петрович*

**архитектор, дизайнер, реставратор**

*4.1.1957, Украина ССРның Львов өлкәсе Дрогобыч шәһәре*

Техник училище тәмамлаганнан соң, заводта һәм төзелешләрдә эшли. 1993 елда ТР Архитекторлар берлеге химаясендә «АССАРТ» проект-төзелеш предприятиесе — Татарстан Республикасы Архитекторлар берлегенә ярдәм итү ассоциациясе оештыра (2014 елда ябыла). Казан Кремлендәге Туп утарының Төньяк корпусы (1997–1998), Болгардагы Ак мәчет (2010–2012), «Кольцо» сәүдә үзәге (2005–2006, автордаш), Казандагы «Ирек» мәчете (2016–2018, автордаш) кебек проектларны тормышка ашыруда катнаша.
Дәүләт бүләге 2012 елда авторлар коллективы составында Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете архитектура комплексын төзүдә катнашкан өчен (бинаның композициясе, пропорцияләре һәм тирәлек белән ярашу концепциясе авторы) бирелә.

2013



# АЙДАРОВ
*Ильяс Сайярович*

**архитектор, художник, действительный член Российской академии художеств (2012 г.), заслуженный деятель искусств РТ (2005 г.), народный художник РТ (2009 г.), заслуженный художник РФ (2013 г.)**

*29.1.1956, г. Казань*

В 1973–1980 гг. обучался в Московском архитектурном институте. В 1984–1994 гг. архитектор-художник в комбинате монументально-декоративного искусства. С 1994 г. художник-оформитель Государственного театра пародий Владимира Винокура.
Премию получил в 2013 г. за цикл художественных произведений, посвященных татарскому поэту Габдулле Тукаю, и за тематические выставки в музеях Тукая в гг. Уральск и Казань.

# АЙДАРОВ
*Ильяс Сәйяр улы*

**архитектор, рәссам, Россия сынлы сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы (2012), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2005), ТРның халык рәссамы (2009), РФнең атказанган рәссамы (2013)**

*29.1.1956, Казан шәһәре*

1973–1980 елларда Мәскәү архитектура институтында укый. 1984–1994 елларда — монументаль-бизәлеш сәнгате комбинатында архитектор-рәссам. 1994 елдан — Владимир Винокурның Пародияләр театрында рәссам-бизәүче.
Дәүләт бүләге 2013 елда татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган сәнгать әсәрләре циклы һәм Уральск, Казан шәһәрләренең Тукай музейларында үткәрелгән тематик күргәзмәләре өчен бирелә.

2013



## ГИМАТДИНОВА (БИКЧУРОВА)
*Набира Минахметовна*

**писательница,
заслуженный работник культуры РТ (1995 г.),
народный писатель РТ (2016 г.)**

*20.10.1956, д. Караса Аксубаевского района ТАССР*

После окончания Казанского университета (1981 г.) руководила литературным объединением при Татарском обкоме ВЛКСМ. С 1989 г. редактор журнала «Идель», в 2006–2009 гг. главный редактор. Первый сборник рассказов — «Су хикәясе» («Сказ о воде», 1981). Автор повестей «Сихерче» («Колдунья», 1993), «Ут күбәләге» («Огненная бабочка», 1990), «Кыргый» («Дикарка», 1996), «Ак торна каргышы» («Заклинание белого журавля», 1997), «Икебезгә дә авыр» («Нам трудно обоим», 2000).
Премию получила в 2013 г. за книги «Мәхәббәттә гонаһ бар» («Любовь грешная», 2008), «Синдә минем хакым бар» («Ты в долгу передо мной», 2011), произведение «Хатыннар сагышы» («Грустить не буду», Казань, 2010).

## ГЫЙМАТДИНОВА (БИКЧУРОВА)
*Нәбирә Миннәхмәт кызы*

**язучы,
ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1995),
ТРның халык язучысы (2016)**

*20.10.1956, ТАССРның Аксубай районы Карасу авылы*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1981), ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршындагы әдәби берләшмәне җитәкли. 1989 елдан — «Идел» журналында бүлек мөхәррире, 2006–2009 елларда — баш мөхәррир. Беренче хикәяләр җыентыгы — «Су хикәясе» (1981). «Сихерче» (1993), «Ут күбәләге» (1990), «Кыргый» (1996), «Ак торна каргышы» (1997), «Икебезгә дә авыр» (2000) повестьлары авторы.
Дәүләт бүләге 2013 елда «Мәхәббәттә гонаһ бар» (2008), «Синдә минем хакым бар» (2011) китаплары һәм «Хатыннар сагышы» (2010) әсәре өчен бирелә.

2013



# ГАЙНУЛЛИНА
*Алсу Аскаровна*

**актриса, народная артистка ТАССР (1986 г.), РФ (1996 г.), лауреат Государственной премии РСФСР им. К. С. Станиславского (1991 г.)**

*24.2.1954, с. Старое Дрожжаное Дрожжановского района ТАССР*

Окончила Казанское театральное училище (1974 г.) и сразу была принята в труппу Татарского академического театра им. Г. Камала. С первых лет работы заняла ведущее положение в театре, сыграв Гульбану («Судьба татарки» Г. Ибрагимова, 1978 г.), Сарби («Беглецы» Н. Исанбета, 1980 г.), Сарвар («Угасшие звезды» К. Тинчурина), Ларису («Бесприданница» А. Н. Островского, 1983 г.) и др.
Премию получила в 2013 г. за создание сценических образов Бyретты в спектакле «Черная бурка» Г. Хугаева, Наташи в спектакле «Кукольная свадьба» М. Гилязова и Р. Хамида, Гайши в спектакле «Женщины 41-го» З. Зайнуллина.

# ГАЙНУЛЛИНА
*Алсу Әскар кызы*

**актриса,
ТАССРның халык артисты (1986),
РФнең халык артисты (1996), К.С.Станиславский исемендәге РСФСР Дәүләт бүләге лауреаты (1991)**

*24.2.1954, ТАССРның Чүпрәле районы Иске Чүпрәле авылы*

Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң (1974), Г. Камал исемендәге Татар академия театры труппасына кабул ителә. Сәхнә эшчәнлегенең беренче елларыннан ук театрда күренекле урын били, Гөлбану («Татар хатыны ниләр күрми» Г. Ибраһимов, 1978), Сәрби («Качкыннар» Н. Исәнбәт, 1980), Сәрвәр («Сүнгән йолдызлар» К. Тинчурин, 1982), Лариса («Бирнәсез кыз» А. Н. Островский, 1983) һ.б. рольләрне башкарып таныла.
Дәүләт бүләге 2013 елда «Кара чикмән» (Г. Хугаев) спектаклендә — Буретта (2002), «Курчак туе» (Г. Исхакый әсәре буенча М. Гыйләҗев һәм Р. Хәмид инсценировкасы) спектаклендә — Наташа (2009), «Кырык беренче ел хатыннары» (З. Зәйнуллин) спектаклендә Гайшә (2010) образларын тудырган өчен бирелә.

2013



# КУЗЬМИНЫХ
## *Софья Даниловна*

художник декоративно-прикладного искусства,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1980 г.),
народный художник РТ (1998 г.),
заслуженный художник РФ (2013 г.)

*19.12.1927, г. Казань*

Окончила техникум швейной промышленности в пгт Кадом Рязанской области (1949 г.), Московский технологический институт (1963 г.). В 1967–1992 гг. главный художник-модельер Казанской кожгалантерейной фабрики. В 1980–1981 гг. преподаватель Казанского института культуры, в 1993–1997 гг. — училища №40 (кожаная мозаика и вышивка).
Премию получила в 2013 г. за цикл посвященных памяти Г. Тукая произведений, выполненных в технике кожаной мозаики.

# КУЗЬМИНЫХ
## *Софья Даниловна*

гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы,
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1980),
ТРның халык рәссамы (1998),
РФнең атказанган рәссамы (2013).

*19.12.1927, Казан шәһәре*

Рязань өлкәсенең Кадом бистәсендә тегү сәнәгате техникумын (1949), Мәскәү технология институтын (1963) тәмамлый. 1967–1992 елларда — Казан күн-галантерея фабрикасы баш рәссам-модельеры. 1980–1981 елларда — Казан мәдәният институты, 1993–1997 елларда — 40 нчы училище (күн мозаикасы һәм чигү) укытучысы.
Дәүләт бүләге 2013 елда Г. Тукай истәлегенә багышланган, күн мозаикасы техникасында эшләнгән әсәрләр циклы (төп әсәре — «Габдулла Тукай истәлегенә багышлау» триптихы) өчен бирелә.

2013



# ТИМЕРБУЛАТОВ
## *Шамиль Харисович*

**композитор, педагог,
заслуженный деятель искусств РТ (1995 г.),
РФ (2005 г.)**

*25.9.1950, г. Казань – 30.5.2013, там же*

В 1978 г. окончил Казанскую консерваторию по классу композиции у А. Б. Луппова. С 1976 г. преподавал в Казанском музыкальном училище, с 1978 г. — в Казанской консерватории, с 1980 г. — в детской музыкальной школе №1. Основные сочинения: симфонические — 6 симфоний (1978, 1994, 2000, 2006–2008 гг.), 2 концерта для фортепиано с оркестром (№1, 2, 2000, 2008 гг.), Концерт для скрипки с оркестром (2009 г.) и др.
Премию получил в 2013 г. за Пятую симфонию «Женский лик Победы», в которой композитор с психологической глубиной, драматизмом и достоверностью воплотил трагическую тему войны.

---

# ТИМЕРБУЛАТОВ
## *Шамил Харис улы*

**композитор, педагог,
ТРның (1995) һәм РФнең (2005) атказанган
сәнгать эшлеклесе**

*25.9.1950, Казан шәһәре – 30.5.2013, шунда ук*

1978 елда Казан консерваториясен (А. Б. Лупповның композиция классы) тәмамлый. 1976 елдан — Казан музыка училищесында, 1978 елдан — Казан консерваториясендә, 1980 елдан — 1 нче балалар музыка мәктәбендә укыта. Төп хезмәтләре — симфоник әсәрләр: 6 симфония (1978, 1994, 2000, 2006, 2007, 2008), фортепиано һәм оркестр өчен 2 концерт (№1, 2, 2000, 2008), скрипка һәм оркестр өчен концерт (2009) һәм башкалар.
Дәүләт бүләге 2013 елда, музыкада сугышның фаҗигале темасы психологик тирәнлек, драматизм һәм тормыш чынлыгы белән чагылдырылган «Җиңүнең хатын-кыз йөзе» Бишенче симфониясе өчен бирелә. Әлеге әсәр композитор иҗатының иң югары ноктасын тәшкил итә, теманы ачу тирәнлеге, башкару осталыгы һәм тарихи хәтерне саклауга керткән өлеше белән аерылып тора.



## ИМАМОВ
### *Вахит Шаихович*

писатель,
заслуженный работник культуры РТ (2002 г.)

*18.3.1954, с. Старое Байсарово Актанышского района ТАССР*

Окончил факультет журналистики Казанского университета (1982 г.). В 1982 г. работал корреспондентом газеты «Светлый путь» Тукаевского района ТАССР. С 1982 г. в г. Набережные Челны: учитель в средней школе, диспетчер на Прессово-рамном заводе ПО «КамАЗ». В 1991–2005 гг. редактор газетно-книжного издательства «КамАЗ». С 1997 г. ответственный секретарь, председатель Набережночелнинской писательской организации Союза писателей РТ.

Автор сборников повестей и рассказов «Ир канаты» («Крылья», 1988), «Нәзер» («Завет», 1991), сборника очерков «Запрятанная история татар» («Яшерелгән тарих», 1993), повести «Сәет батыр» («Сеит-батыр», 1994), романа «Тозлы яра» («Соленая рана», 2002).

Премию получил в 2014 г. за двухтомный исторический роман «Утлы дала» («Огненная степь», 2012).

## ИМАМОВ
### *Вахит Шәех улы*


язучы,
ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2002)

*18.3.1954, ТАССРның Актаныш районы Иске Байсар авылы*

Казан университетының журналистика факультетын тәмамлый (1982). 1982 елда Тукай районының «Якты юл» газетасында хәбәрче булып эшли. 1982 елдан — Чаллы шәһәрендә: урта мәктәптә укытучы, «КамАЗ» ҖБнең «Пресс-рам» заводында диспетчер. 1991–2005 елларда — «КамАЗ» газета-китап нәшриятында мөхәррир. 1997 елдан ТР Язучылар берлегенең Чаллы язучылар оешмасында җаваплы сәркатип, рәис.

«Ир канаты» (1988), «Нәзер» (1991) повесть һәм хикәяләр җыентыклары, «Яшерелгән тарих» очерклар җыентыгы (1993), «Сәет батыр» (1994) повесте, «Утлы дала» тарихи романы (2001–2002, — беренче басма; 2012, — икенче басма), «Тозлы яра» романы (2002) авторы. Дәүләт бүләге 2014 елда ике томлы «Утлы дала» (2012) тарихи романы өчен бирелә.

2014



# ПОПОВ
*Владимир Александрович*

**график, каллиграф, живописец,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1975 г.),
народный художник ТАССР (1986 г.),
заслуженный художник РФ (2003 г.)**

*24.6.1924, г. Мариуполь, Украинская ССР – 27.10.2023, г. Казань*

Участник Великой Отечественной войны. После окончания Казанского художественного училища (1951 г.) в Татарском художественном фонде (1951–1983 гг.). С конца 1950-х гг. работал в области станковой графики в техниках линогравюры, офорта, гравюры на дереве, ксилографии, акварели, рисунка углем, тушью; создавал произведения в жанрах видового, индустриального и архитектурного пейзажей.

Премию получил в 2014 г. за серию каллиграфических композиций в жанрах тугры и шамаиля, посвященных выдающимся деятелям татарской культуры и восточной философии, а также за триптихи «Каллиграфия за Мир», «Наказы Творца», «Аллах Великодушный — Аль-Карим».

# ПОПОВ
*Владимир Александрович*

**график, каллиграф, нәкышьче,
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1975),
ТАССРның халык рәссамы (1986),
РФнең атказанган рәссамы (2003)**

*24.6.1924, Украина ССРның Мариуполь шәһәре – 27.10.2023, Казан шәһәре*

Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң (1951), Татарстан Сәнгать фондында эшли (1951–1983). 1950 еллар ахырыннан станлы графика өлкәсендә линогравюра, офорт, агачка уелган гравюра, ксилография, акварель, күмер һәм тушь белән рәсем төшерү техникаларында эшли; табигать, сәнәгать һәм архитектура пейзажы жанрларындагы әсәрләр иҗат итә.

Дәүләт бүләге 2014 елда тугра һәм шамаил жанрларында татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләренә һәм Шәрык фәлсәфәсенә багышланган каллиграфик композицияләр сериясе, шулай ук «Каллиграфия Тынычлык яклы», «Хак Тәгалә таләпләре», «Аллаһы юмарттыр — Әл-Кәрим» триптихлары өчен бирелә.

2015



## БУЛАТОВА (РАФИГУЛЛИНА)
*Клара Гарифовна*

**поэтесса,
заслуженный работник культуры ТАССР (1986 г.),
народный поэт РТ (2019 г.)**

*18.3.1936, д. Татарские Карамалы
Сармановского района ТАССР –
29.4.2025, с. Новое Надырово Альметьевского района РТ*

После окончания Казанского университета (1969 г.) преподавала в сельских школах. Начала печататься в 1956 г. В 1967 г. вышел ее первый сборник лирических стихов «Язлар алда» («Впереди весна»). Поэзия отличается искренностью, богатством чувств и связью с реальностью.
Премию получила в 2015 г. за книги «Келәү: шигырьләр, повесть, хикәя» («Мольба: стихи, повесть, рассказ»), «Сәяхәтнамәләр: шигырьләр» («Путешествия: стихи») и «К солнцу лицом» (все — 2013).

---

## БУЛАТОВА (РӘФИГУЛЛИНА)
*Клара Гариф кызы*

**шагыйрә,
ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1986),
ТРның халык шагыйре (2019)**

*18.03.1936, ТАССРның Сарман районы
Татар Карамалысы авылы –
29.04.2025, ТРның Әлмәт районы Яңа Нәдер авылы*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1969), авыл мәктәпләрендә укыта. Шигырьләре матбугатта 1956 елдан басыла башлый. «Язлар алда» беренче лирик шигырьләр җыентыгы 1967 елда дөнья күрә. Шигърияте ихласлыгы, хисләр байлыгы һәм тормышчанлыгы белән аерылып тора, бу аны XX йөзнең икенче яртысы — XXI йөз башы татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе итә.
Дәүләт бүләге 2015 елда «Келәү: Шигырьләр, повесть, хикәя», «Сәяхәтнамәләр: Шигырьләр» һәм рус телендә «К солнцу лицом» (барысы да — 2013) китаплары өчен бирелә.

2015



# КОЛМОГОРЦЕВА
## *Ирина Константиновна*

график, художник книги, плакатист,
заслуженный деятель искусств ТАССР (1981 г.),
народный художник РТ (2005 г.)

*5.7.1930, г. Свердловск – 7.11.2015, г. Казань*

Окончила Украинский полиграфический институт им. И. Фёдорова в г. Львове (1955 г.). Была одним из ведущих мастеров гравюры в республике, применяла техники линогравюры, литографии, офорта, монотипии. В станковом рисунке работала карандашом, тушью, акварелью, пастелью.
Премию получила в 2015 г. за графическую серию «Казань и Габдулла Тукай», в которой объединены образ великого татарского поэта и историческое наследие Казани.

# КОЛМОГОРЦЕВА
## *Ирина Константиновна*

график, китап графикасы остасы, плакатчы,
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981),
ТРның халык рәссамы (2005)

*5.7.1930, Свердловск шәһәре – 7.11.2015, Казан шәһәре*

И. Фёдоров исемендәге Украина полиграфия институтын (Львов шәһәре) тәмамлый (1955). Республиканың әйдәп баручы гравюра осталарыннан берсе, линогравюра, литография, офорт, монотипия техникаларында эшли. Станлы рәсем өлкәсендә каләм, тушь, акварель, пастель техникасын куллана.
Дәүләт бүләге 2015 елда «Казан һәм Габдулла Тукай» график сериясе өчен бирелә. Биредә бөек татар шагыйре образы белән Казанның тарихи мирасы берләштерелеп тәкъдим ителә. Детальләштерү һәм экспрессив сурәт тудыру мөмкинлеге бирүче офорт техникасында башкарыла.

2015



# МУХАМЕТЗЯНОВ
*Рауфаль Сабирович*

**музыкально-театральный деятель, заслуженный работник культуры РФ (2002 г.), заслуженный деятель искусств РТ (2014 г.)**

*10.11.1949, г. Казань*

В 1974 г. окончил Казанский химико-технологический институт. Работал там же директором студенческого клуба, секретарем комитета ВЛКСМ Казанского института культуры, заведующим отделом Казанского городского комитета комсомола учащейся молодежи, директором Казанского ТЮЗа. С 1981 г. директор Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля.
Премию получил в 2015 г. в составе творческой группы Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля за участие (автор идеи и художественный руководитель проекта) в создании балета «Золотая Орда» на музыку Р. Ахияровой и либретто Р. Хариса.


# МӨХӘММӘТҖАНОВ
*Рәүфәл Сабир улы*

**музыка-театр эшлеклесе, РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (2002), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2014)**

*10.11.1949, Казан шәһәре*

Казан химия-технология институтын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук студентлар клубы директоры, Казан мәдәният институтының комсомол комитеты секретаре, ВЛКСМның Казан шәһәр комитетында укучы яшьләр бүлеге мөдире, Казан Яшь тамашачылар театры директоры булып эшли. 1981 елдан — М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры директоры.
Дәүләт бүләге 2015 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының иҗат төркеме составында, проектның идея авторы һәм сәнгать җитәкчесе буларак, «Алтын Урда» спектаклен (Р. Ахиярова музыкасы, Р. Харис либреттосы) куюда катнашкан өчен бирелә.

2015



# КОВТУН
*Георгий Анатольевич*

**артист балета, балетмейстер, режиссер музыкального театра, заслуженный деятель искусств РСФСР (1988 г.), народный артист РТ (2010 г.)**

*19.2.1950, г. Одесса*

Окончил Воронежское хореографическое училище (1973 г.), Ленинградскую консерваторию (1988 г.). С 1973 г. артист балета, одновременно с 1975 г. балетмейстер в театрах России и Украины, с 1998 г. преподает в Санкт-Петербургской консерватории. В Казани как режиссер поставил оперы: «Крик кукушки» Р. Калимуллина (1989 г.), «Летучий голландец» Р. Вагнера (1991 г.), «Аида» Дж. Верди (2002 г.), «Кармен» Ж. Бизе (2011 г.); как балетмейстер — балеты: «Сказание о Йусуфе» Л. Любовского (2001 г.), «Пер Гюнт» Э. Грига (2003 г.), «Спартак» А. Хачатуряна (2008 г.), «Золотая Орда» Р. Ахияровой (2013 г.).
Премию получил в 2015 г. в составе творческой группы Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля за участие в качестве балетмейстера-постановщика в создании балета «Золотая Орда» на музыку Р. Ахияровой и либретто Р. Хариса.


# КОВТУН
*Георгий Анатольевич*

**балет артисты, балетмейстер, музыкаль театр режиссеры, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), ТРның халык артисты (2010)**

*19.2.1950, Одесса шәһәре*

Воронеж хореография училищесын (1973), Ленинград консерваториясен (1988) тәмамлый. 1973 елдан балет артисты, бер үк вакытта, 1975 елдан, Россия һәм Украина театрларында балетмейстер, 1998 елдан Санкт-Петербург консерваториясендә укыта. Казанда режиссер буларак Р. Кәлимуллинның «Ерактагы кәккүк авазы» (1989), Р. Вагнерның «Очучы голландец» (1991), Җ. Вердиның «Аида» (2002), Ж. Бизеның «Кармен» (2011) операларын; балетмейстер буларак Л. Любовскийның «Йосыф турында риваять» (2001), Э. Григ музыкасына «Пер Гюнт» (2003), А. Хачатурянның «Спартак» (2008), Р. Ахиярова музыкасына «Алтын Урда» (2013) балетларын куя.
Дәүләт бүләге 2015 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының иҗат төркеме составында, балетмейстер-сәхнәгә куючы буларак, «Алтын Урда» спектаклен (Р. Ахиярова музыкасы, Р. Харис либреттосы) куюда катнашкан өчен бирелә.

2015



# АНДРЕЕВА-ЗАХАРОВА
*Кристина Андреевна*

артистка балета,
заслуженная артистка РТ (2015 г.)

*20.5.1992, г. Красноярск*

После окончания в 2010 г. Красноярского хореографического колледжа принята в балетную труппу Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля. В числе исполняемых партий: Одетта-Одиллия («Лебединое озеро»), Китри («Дон Кихот»), Гамзатти («Баядерка»), а также ведущие партии в балетах современного репертуара, включая постановки «Золотая Орда» и «Спартак».
Премию получила в 2015 г. в составе творческой группы Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля за исполнение партии Джанике в балете «Золотая Орда» на музыку Р. Ахияровой и либретто Р. Хариса.

# АНДРЕЕВА-ЗАХАРОВА
*Кристина Андреевна*

балет артисты,
ТРның атказанган артисты (2015)

*20.5.1992, Красноярск шәһәре*

Красноярск хореография колледжын тәмамлаганнан соң (2010), М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының балет труппасына кабул ителә. Башкарган партияләре арасында Одетта-Одиллия («Аккош күле»), Китри («Дон Кихот»), Гамзатти («Баядерка»), шулай ук заманча репертуардагы балетларда, шул исәптән «Алтын Урда» һәм «Спартак» спектакльләрендә төп партияләре бар.
Дәүләт бүләге 2015 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының иҗат төркеме составында «Алтын Урда» балетында (Р. Ахиярова музыкасы, Р. Харис либреттосы) Җанәкә партиясен башкарган өчен бирелә. Артистның башкару осталыгы образның эчке дөньясын тирән ачуы, камил классик башкару техникасы һәм виртуозлыгы белән аерылып тора.



## ТИМАЕВ
## *Михаил Иванович*

**артист балета,**
**заслуженный артист РТ (2015 г.)**

*31.1.1986, г. Казань*

В 2005 г. окончил Казанское хореографическое училище. В 2004 г. принят в балетную труппу Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля. В репертуаре — сольные и ведущие хореографические партии в балетах зарубежного и русского классического наследия, современных и национальных спектаклях.
Премию получил в 2015 г. в составе творческой группы Татарского академического театра оперы и балета им. М. Джалиля за исполнение роли Духа хана Батыя в балете «Золотая Орда» на музыку Р. Ахияровой и либретто Р. Хариса.

---

## ТИМАЕВ
## *Михаил Иванович*

**балет артисты,**
**ТРның атказанган артисты (2015)**

*31.1.1986, Казан шәһәре*

2005 елда Казан хореография училищесын тәмамлый. 2004 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының балет труппасына кабул ителә. Репертуарында — чит ил һәм рус классик балетларында, заманча һәм милли спектакльләрдә соло һәм төп хореография партияләре.
Дәүләт бүләге 2015 елда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының иҗат төркеме составында «Алтын Урда» балетында (Р. Ахиярова музыкасы, Р. Харис либреттосы) Бату хан Рухы ролен башкарган өчен бирелә. Башкару үзенчәлеге персонажның эчке дөньясын тирән ачуы, техник катлаулылыгы һәм сәнгатьлелегендә чагыла.

2016



# ИСМАГИЛОВ
*Назип Файзрахманович (псевдоним — Нажип Наккаш)*

**литературовед,
художник-каллиграф, график,
заслуженный деятель искусств РТ (1998 г.)**

*30.7.1948, с. Усали Мамадышского района ТАССР*

Основоположник возрождения традиций татарского национального искусства арабской каллиграфии. По окончании в 1979 г. Казанского университета работал в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, в 2000–2006 гг. — в Российском исламском университете. Автор шамаилей, графических и исполненных живописью на стекле, зеркале, тугр и родословных-шеджере, посвященных крупным деятелям культуры, искусства, политикам; оформитель книг.
Премию получил в 2016 г. за цикл шамаилей, ляухэ (арабографичные надписи) со стихотворными строками поэта Г. Тукая и дизайн мечетей (арабская каллиграфия) «Ярдәм» города Казани и села Шингальчи Нижнекамского района Республики Татарстан.

# ИСМӘГЫЙЛЕВ
*Нәҗип Фәйзрахман улы (псевдонимы — Нәҗип Нәкъкаш)*

**әдәбият белгече,
рәссам-каллиграф, график,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1998)**

*30.7.1948, ТАССРның Мамадыш районы Үсәли авылы*

Татар милли гарәп каллиграфиясе сәнгате традицияләрен яңартуга нигез салучы. Казан университетын тәмамлаганнан соң (1979), СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли, 2000–2006 елларда — Россия ислам университетында. Шәмаилләр, шулай ук пыяла һәм көзге өслегендә башкарылган графика һәм нәкышь әсәрләре авторы, мәдәният, сәнгать, сәясәт эшлеклеләренә багышланган тугралар һәм шәҗәрәләр эшләү, китап бизәү остасы.
Дәүләт бүләге 2016 елда Казан шәһәрендәге «Ярдәм» мәчете һәм ТРның Түбән Кама районы Шәңгәлче авылы мәчете интерьерлары өчен шәмаилләр, Г. Тукайның шигырь юллары язылган, сәнгать әсәре булу белән беррәттән, бөек татар шагыйренә ихтирам йөзеннән башкарылган ләүхәләр циклы һәм мәчетләрнең гарәп каллиграфиясе кулланылган дизайны өчен бирелә.



**МУРАТОВ**
*Газинур Васикович (псевдоним — Газинур Мурат)*

**поэт,
заслуженный деятель искусств РТ (2001 г.),
народный поэт РТ (2022 г.)**

*18.8.1959, д. Большой Сардек Кукморского района ТАССР*

После окончания Казанского университета (1981 г.) работал в газете «Татарстан яшьләре» («Молодежь Татарстана»), в 1984–1988 гг. — в журнале «Ялкын» («Пламя»). В 1989–1991 гг. руководитель республиканского литературного объединения при обкоме ВЛКСМ. В 1991–1993 гг. заведующий отделом журнала «Идель». В 1991–1995 гг. главный редактор газеты «Татар иле» («Татарские края»). С 1995 г. заместитель главного редактора газеты «Мәдәни җомга» («Культурная пятница»). Стихи отличаются романтизмом, философской насыщенностью, публицистическим звучанием, широким охватом жизненных явлений.
Премию получил в 2016 г. за книгу «Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» («Птичьи права: стихотворения и поэмы», 2014).

**МОРАТОВ**
*Газинур Васикъ улы (псевдонимы — Газинур Морат)*

**шагыйрь,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001),
ТРның халык шагыйре (2022)**

*18.8.1959, ТАССРның Кукмара районы Зур Сәрдек авылы*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1981), «Татарстан яшьләре» газетасында, 1984–1988 елларда — «Ялкын» журналында бүлек мөхәррире. 1989–1991 елларда — ВЛКСМ өлкә комитеты каршындагы республика әдәби берләшмәсе җитәкчесе. 1991–1993 елларда — «Идел» журналында бүлек мөдире, 1991–1995 елларда — «Татар иле» газетасы баш мөхәррире. 1995 елдан — «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире урынбасары. «Җир хәтере» беренче шигырьләр җыентыгы 1985 елда дөнья күрә. Шигърияте романтизм, фәлсәфи тирәнлек, публицистик аһәң, тормыш күренешләрен киң колачлау һәм аларның әхлакый аспектларына игътибар белән аерылып тора. Шагыйрь иҗтимагый-сәяси лирикага, татар теле һәм мәдәниятен саклау проблемаларына еш мөрәҗәгать итә. Дәүләт бүләге 2016 елда «Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» (2014) китабы өчен бирелә.

2016



# АРТАМОНОВ
*Илья Николаевич*

**художник,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2011 г.)**

*25.4.1960, г. Новосибирск*

Окончил Казанское художественное училище (1979 г.), Ленинградское высшее художественно-промышленное училище им. В. И. Мухиной (1984 г.). Творчество включает дизайн-проектирование музейных экспозиций и различных интерьеров, живопись, графику, работу в смешанных техниках.
Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

# АРТАМОНОВ
*Илья Николаевич*

**рәссам,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2011)**

*25.4.1960, Новосибирск*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1979), В. И. Мухина исемендәге Ленинград югары сәнгать-сәнәгать училищесын (1984) тәмамлый. Иҗаты музей экспозицияләре һәм төрле интерьер дизайн-проектларын эшләүне, нәкышь, графика әсәрләрен, катнаш техника кулланылган хезмәтләрне үз эченә ала.
Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.



## ЛЕУХИН
*Александр Петрович*

**художник,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2011 г.)**

*28.8.1949, г. Казань*

Окончил Казанское художественное училище (1968 г.). Один из авторов экспозиции Музея Салиха Сайдашева в Казани (1993 г.). Автор и исполнитель работ по оформлению потолка купола мечети «Кул Шариф». Один из авторов проекта музеефикации Старо-Татарской слободы и острова-града Свияжск.
Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

## ЛЕУХИН
*Александр Петрович*

**рәссам,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2011)**

*28.8.1949, Казан*

Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1968). Казандагы Салих Сәйдәшев музее экспозициясе авторларыннан берсе (1993). Колшәриф мәчете гөмбәзенең эчке бизәлеше авторы һәм башкаручысы. Иске Татар бистәсе һәм Зөя утрау-шәһәрчеген музейлаштыру проектлары авторларыннан берсе.
Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.

2016



# ВАЛИУЛЛИН
## *Фарит Рашидович*

**художник, живописец, монументалист, мозаист, заслуженный деятель искусств РТ (2014 г.), народный художник РТ (2021 г.)**

*24.2.1959, г. Казань*

Окончил Казанское художественное училище (1978 г.), Московский художественный институт им. В. И. Сурикова (1986 г.). С 2006 г. преподаватель Татарского гуманитарно-педагогического университета, ныне доцент Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского университета. Руководитель творческой группы художников, участвовавшей в реконструкции и воссоздании монументального сграффито «Советская Татария» на фасаде здания железнодорожного вокзала в Казани (авторы В. Бубеннов и В. Федоров, 1966 г.). Один из авторов и исполнителей монументального решения внутренней части купола мечети «Кул Шариф» (совместно с Р. А. Кильдибековым, 2005 г.).
Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

# ВӘЛИУЛЛИН
## *Фәрит Рәшит улы*

**рәссам, нәкышьче, монументалист, мозаика остасы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2014), ТРның халык рәссамы (2021)**

*24.2.1959, Казан*

Казан сынлы сәнгать училищесын (1978), В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын (1986) тәмамлый. 2006 елдан — Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты укытучысы, хәзерге вакытта Казан университетының Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты доценты. Колшәриф мәчете гөмбәзенең эчке монументаль чишелеше авторларыннан һәм башкаручыларыннан берсе (2005, Р. Ә. Килдебәков белән берлектә), Казан тимер юл вокзалы бинасы фасадындагы «Совет Татарстаны» монументаль сграффитосын реконструкцияләүдә катнашкан рәссамнар иҗади төркеме җитәкчесе.
Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.



# ШИГАБУТДИНОВ
## *Рашид Садриевич*

**художник-проектировщик,**
**график, монументалист**

*14.2.1946, Казань*

В 1967 г. окончил Казанское художественное училище. Живет и работает в г. Нижнекамске, в 1973–1979 гг. главный художник города. Основные работы: монументально-декоративная роспись «Татарские мотивы» (1970 г.); проект музея истории Нижнекамска и промышленной зоны (1976 г.); монументально-декоративные росписи в технике сграффито на фасадах Дворца культуры «Театр», «Музыка», «Поэзия», «Живопись и архитектура»; проект Мемориала павшим воинам и Аллеи Героев Советского Союза» (все — в г. Менделеевске, 1989 г.) и др.
Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

# ШИҺАБЕТДИНОВ
## *Рәшит Садри улы*

**проектлаучы-рәссам,**
**график, монументалист**

*14.2.1946, Казан шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1967). Түбән Кама шәһәрендә яши һәм иҗат итә, 1973–1979 елларда — шәһәрнең баш рәссамы. Төп хезмәтләре: «Татар бизәкләре» монументаль-декоратив панносы (1970); Түбән Кама тарихы һәм сәнәгать зонасы музее проекты (1976); Мәдәният сарае фасадларында сграффито техникасында эшләнгән «Татар көйләре», «Театр», «Музыка», «Шигърият», «Нәкышь һәм архитектура» монументаль-декоратив паннолары (1989, Менделеевск шәһәре); Һәлак булган сугышчылар мемориалы һәм Советлар Союзы Геройлары аллеясы проекты (1989, Менделеевск шәһәре) һ.б.
Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.



# ЩЕТИНИН
## *Игорь Васильевич*

**художник-монументалист**

*4.12.1959, г. Казань*

Окончил Казанское художественное училище (1979 г.). В станковом творчестве работает в разных техниках — масло, акварель, гуашь. Натюрморты: «Пионы», «Пивной натюрморт»; пейзажи: «Водопады», «Байкал», «Карлаг».
Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

---

# ЩЕТИНИН
## *Игорь Васильевич*

**рәссам-монументалист**

*4.12.1959, Казан*

Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1979). Станлы иҗатның төрле техникаларын (майлы буяу, акварель, гуашь) кулланып эшли. «Сыра белән натюрморт», «Пионнар» натюрмортлары; «Шарлавыклар», «Байкал», «Карлаг» пейзажлары авторы.
Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.

2016



# СИТДИКОВ
## *Айрат Габитович*

**археолог, доктор исторических наук (2014 г.), действительный член Академии наук Республики Татарстан (2023 г.), заслуженный работник культуры РТ (2014 г.), заслуженный деятель науки РТ (2019 г.)**

*24.1.1973, с. Большая Атня Арского района ТАССР, ныне Атнинский район РТ*

Окончил Казанский педагогический институт (1996 г.). С 1996 г. сотрудник историко-архитектурного и художественного музея-заповедника «Казанский Кремль». В 2001–2005 гг. начальник отдела археологического надзора Управления государственного контроля охраны и использования памятников истории и культуры при Главном управлении архитектуры и градостроительства Казани. С 2008 г. заведующий кафедрой этнографии и археологии Казанского университета и заместитель директора музея-заповедника «Казанский Кремль». С 2014 г. директор Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ.

Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

# СИТДЫЙКОВ
## *Айрат Габит улы*

**археолог, тарих фәннәре докторы (2014), ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (2024), ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2014), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2019)**

*24.1.1973, ТАССРның Арча районы, хәзер ТРның Әтнә районы Олы Әтнә авылы*

Казан педагогика институтын тәмамлаганнан соң (1996), «Казан Кремле» тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы хезмәткәре була. 2001–2005 елларда — Казан шәһәре Баш архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе каршындагы Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм файдалану буенча дәүләт контроле идарәсенең археологик күзәтчелек бүлеге башлыгы. 2008 елдан — Казан университетының этнография һәм археология кафедрасы мөдире һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры урынбасары. 2014 елдан — ТР Фәннәр академиясенең А. Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры.

Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.



# ХАЙРУТДИНОВ
## *Рамиль Равилович*

**историк,**
**кандидат исторических наук (1993 г.)**

*16.6.1964, д. Черки-Кильдуразы Буинского района ТАССР – 20.6.2025, г. Казань*

После окончания Казанского университета (1986 г.) работал в Институте языка, литературы и истории Академии наук Республики Татарстан. С 1997 г. в Институте истории им. Ш. Марджани АН РТ: заведующий отделом Свода памятников истории и культуры, заместитель директора (1998–2011 гг.). Одновременно в 2007–2012 гг. директор музея-заповедника «Казанский Кремль». С 2011 г. директор Института истории, с 2013 г. — Института международных отношений, истории и востоковедения Казанского федерального университета.

Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

# ХӘЙРЕТДИНОВ
## *Рамил Равил улы*

**тарихчы,**
**тарих фәннәре кандидаты (1993)**

*16.6.1964, ТАССРның Буа районы Килдураз авылы – 20.6.2025, Казан*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1986), ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. 1997 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында: Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр җыелмасы бүлеге мөдире, 1998–2011 елларда — директор урынбасары. Бер үк вакытта, 2007–2012 елларда, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры. 2011 елдан — Казан федераль университетының Тарих институты, 2013 елдан — Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты директоры.

Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.

2016



# БУГРОВ
## *Дмитрий Геннадьевич*

**археолог,**
**кандидат исторических наук (2006 г.)**

*22.7.1966, г. Казань*

Окончил Казанский университет (1991 г.). С 1991 г. в отделе истории досоветского периода Государственного музея РТ (с 2001 г. Национальный музей РТ). С 2006 г. в Национальном центре археологических исследований Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, с 2014 г. в Институте археологии им. А. Х. Халикова АН РТ. Сфера научных интересов — археология Поволжья и Прикамья (первая половина первого тысячелетия нашей эры).
Премию получил в 2016 г. в составе авторского коллектива за участие в создании художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Музее болгарской цивилизации (г. Болгар).

# БУГРОВ
## *Дмитрий Геннадьевич*

**археолог,**
**тарих фәннәре кандидаты (2006)**

*22.7.1966, Казан*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1991), ТР Дәүләт музееның (2001 елдан — ТР Милли музее) советларга кадәрге чор тарихы бүлегендә эшли. 2006 елдан — ТР Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли археологик тикшеренүләр үзәгендә, 2014 елдан — ТР Фәннәр академиясенең А. Х. Халиков исемендәге Археология институтында. Фәнни кызыксынулары өлкәсе — Идел һәм Кама буе (безнең эраның беренче меңьеллыгы беренче яртысы) археологиясе.
Дәүләт бүләге 2016 елда авторлар коллективы составында Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музеенда «Болгар цивилизациясе. Меңьеллык юл» сәнгати-фәзаи экспозиция инсталляциясен төзүдә катнашкан өчен бирелә.

2017



# МАЛИКОВА
*Мадина Габдулхаковна*

**журналистка, писательница,**
**заслуженный работник культуры ТАССР (1976 г.),**
**РСФСР (1985 г.)**

*5.8.1935, с. Муфтыш-Тамак Сармановского района ТАССР*

Окончила Казанский педагогический институт (1959 г.). В 1959–1964 гг. в редакции журнала «Чаян» («Скорпион»), в 1964–1987 гг. в журнале «Азат хатын» (Свободная женщина») (с 1978 г. ответственный секретарь). В 1989–1990 гг. заместитель председателя правления Союза писателей РТ. В 1993–2002 гг. президент Всетатарского общества Красного полумесяца. Автор повестей и пьес.
Премию получила в 2017 г. за книгу «Арыш тәме: роман, повесть, хатирәләр» («Вкус ржи», 2014), которая отличается глубокой эмоциональностью, психологической достоверностью и тонким пониманием человеческой природы.

# МАЛИКОВА
*Мәдинә*
*Габделхак кызы*

**журналист, язучы,**
**ТАССРның (1976), РСФСРның (1985) атказанган**
**мәдәният хезмәткәре**

*5.8.1935, ТАССРның Сарман районы Мортыштамак авылы*

Казан педагогия институтын тәмамлый (1959). 1959–1964 елларда — «Чаян» журналы редакциясендә, 1964–1987 елларда — «Азат хатын» журналында (1978 елдан — җаваплы сәркатип). 1989–1990 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. 1993–2002 елларда — Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыяте президенты. Повестьлар һәм пьесалар авторы.
Дәүләт бүләге 2017 елда «Арыш тәме: роман, повесть, хатирәләр» (2014) китабы өчен бирелә. Китапка тупланган әсәрләр эмоциональлек, тормыш чынбарлыгын тасвирлауда психологик тирәнлек һәм кешенең табигатен нечкә тою белән аерылып тора.

2017



# САЛИХОВ
*Харис Салихович (псевдоним — Харис Салихжан)*

**писатель,
религиозный деятель**

*30.7.1927, с. Чутай Арского кантона ТАССР, ныне Балтасинский район РТ*

Участник Великой Отечественной войны. Окончил Высшую партийную школу КПСС (г. Горький, 1962 г.), Казанское высшее мусульманское медресе имени 1000-летия принятия ислама (1993 г.). Более 30 лет прослужил в органах внутренних дел, полковник милиции в отставке. В 1993–1997 гг. секретарь главного мухтасибата, заместитель председателя Духовного управления мусульман РТ. С 2005 г. имам-хатиб мечети «Хәтер» («Память»). Автор работ по истории ислама.

Премию получил в 2017 г. за книги «Светские и духовные мотивы в творчестве А. Пушкина, Г. Тукая и проблемы нравственного воспитания сегодня» (2008) и «Религия и наука (основы мировых религиозных и светских культур)» (2012).

# САЛИХОВ
*Харис Салих улы (псевдонимы — Харис Салихҗан)*

**язучы,
дин эшлеклесе**

*30.7.1927, ТАССРның Арча кантоны, хәзер балтач районы Чутай авылы*

Бөек Ватан сугышында катнаша. Югары партия мәктәбен (1962; Горький шәһәре), Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсен (1993) тәмамлый. Эчке эшләр органнарында 30 елдан артык хезмәт итә, отставкадагы милиция полковнигы. 1993–1997 елларда баш мөхтәсибәт сәркатибе, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары. 2005 елдан — «Хәтер» мәчете имам-хатибы. Ислам тарихы буенча хезмәтләр авторы.

Дәүләт бүләге 2017 елда «А. Пушкин һәм Г. Тукай иҗатында дөньяви һәм рухи мотивлар һәм бүгенге көндә әхлакый тәрбия проблемалары» (2008) һәм «Дин һәм фән (дөньядагы дини һәм дөньяви мәдәният нигезләре)» (2012) китаплары өчен бирелә.



## ШАГЕЕВА
*Розалина Гумеровна*

**поэтесса, переводчик,**
**искусствовед, музейный работник,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1993 г.)**

*28.7.1945, д. Бишня Зеленодольского района ТАССР — 13.5.2024, г. Казань*

Окончила Казанский университет (1968 г.). С 1969 г. работала в Государственном музее изобразительных искусств РТ: заведующая отделом искусства Татарстана (1990–1991 гг.). С 1991 г. в Национальном культурном центре «Казань»: заместитель директора (1994–2008 гг.). Одновременно в 2008–2010 гг. заведующая галереей «Хазинэ». Автор музейных экспозиций, соавтор концепции Музея национальной культуры, музея Б. Урманче.
Премию получила в 2017 г. за книгу «Розы вечности: сборник статей на татарском и русском языках» (2015).

## ШАҺИЕВА
*Розалина Гомәр кызы*

**шагыйрә, тәрҗемәче,**
**сәнгать белгече, музей хезмәткәре,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993)**

*28.7.1945, ТАССРның Зеленодольск районы Бишнә авылы — 13.5.2024, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлый (1968). 1969 елдан Татарстан сынлы сәнгать музеенда эшли: Татарстан сәнгате бүлеге мөдире (1990–1991). 1991 елдан — «Казан» Милли мәдәният үзәгендә, 1994–2008 елларда — директор урынбасары. Бер үк вакытта, 2008–2010 елларда, «Хәзинә» галереясы мөдире. Музей экспозицияләре авторы, Милли мәдәният музее, Б.Урманче музее концепцияләре автордашы, шигъри җыентыклар авторы.
Дәүләт бүләге 2017 елда «Мәңгелек гөлләре: татар һәм рус телләрендә мәкаләләр җыентыгы» («Розы вечности: сборник статей на татарском и русском языках», 2015) китабы өчен бирелә. Китап югары сәнгатьчә осталык белән бәян ителгән тирән мәдәни, тарихи һәм фәлсәфи уйлануларны берләштерә, үзенчәлекле бизәлеше белән җәлеп итә.



# КАРИМОВ
*Камиль Адгамович*

**писатель,**
**заслуженный работник культуры РТ (2000 г.),**
**заслуженный деятель искусств РТ (2011 г.),**
**народный писатель РТ (2024 г.)**

*1.7.1950, с. Шали Пестречинского района ТАССР*

После окончания Казанского института культуры (1980 г.) работал в редакции газеты «Яшь ленинчы» («Юный ленинец»). В 1982–1988 гг. ответственный редактор альманаха «Идель», в 1988–2000 гг. ответственный секретарь журнала «Чаян» («Скорпион»). В 1988–2000 гг. автор и ведущий телевизионных юмористических передач. С 2000 г. редактор отдела прозы журнала «Казан утлары» («Огни Казани»). Автор произведений «Бәхетле кеше» («Счастливый человек», 1984), «Ком сәгате» («Песочные часы», 2000) и др.
Премию получил в 2018 г. за книги «Карурманда кара песи: повестьлар һәм хикәяләр» (2015) и «Игезәкләр йолдызлыгы: романнар» (2016).

# КӘРИМОВ
*Камил Әдһәм улы*

**язучы,**
**ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2000),**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2011),**
**ТРның халык язучысы (2024)**

*1.7.1950, ТАССРның Питрәч районы Шәле авылы*

Казан мәдәният институтын тәмамлаганнан соң (1980), «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли. 1982–1988 елларда — «Идел» альманахының җаваплы мөхәррире, 1988–2000 елларда — «Чаян» журналының җаваплы сәркатибе. 1988–2000 елларда — телевидениедә юмористик тапшыруларның авторы һәм алып баручысы. 2000 елдан — «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире. «Бәхетле кеше» (1984), «Ком сәгате» (2000) һәм башка әсәрләр авторы.
Дәүләт бүләге 2018 елда «Карурманда кара песи: повестьлар һәм хикәяләр» (2015) һәм «Игезәкләр йолдызлыгы: романнар» (2016) китаплары өчен бирелә.

2018



# КУЗНЕЦОВ
## *Михаил Иванович*

**график, живописец,**
**заслуженный деятель искусств РТ (2005 г.),**
**народный художник РТ (2011 г.)**

*23.8.1946, д. Ново-Курманаево*
*Высокогорского района ТАССР*

Окончил Казанское художественное училище (1970 г.). Работал в Ишимбайском народном драматическом театре художником-декоратором. С 1975 г. в Стерлитамакском русском драматическом театре. В 1975–1989 гг. преподавал в Стерлитамакской детской художественной школе. С 1989 г. живет в Казани.
Премию получил в 2018 г. за серию работ «Белые холсты. Народы Поволжья», основанную на тщательных исследованиях этнографии и материальной культуры народов региона.

# КУЗНЕЦОВ
## *Михаил Иванович*

**рәссам, график,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2005),**
**ТРның халык рәссамы (2011)**

*23.8.1946, ТАССРның Биектау районы*
*Яңа Корманай авылы*

Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1970). Ишембай халык драма театрында рәссам-бизәүче булып эшли. 1975 елдан — Стәрлетамак рус драма театрында. 1975–1989 елларда Стәрлетамак балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укыта. 1989 елдан Казанда яши.
Дәүләт бүләге 2018 елда төбәктә яшәүче халыкларның этнографиясе һәм матди мәдәниятен җентекләп өйрәнүгә нигезләнгән «Ак киндерләр. Идел буе халыклары» иҗади хезмәтләре сериясе өчен бирелә.

2018



# ШАФИГУЛЛИН
*Лутфулла Нурисламович*

**административно-хозяйственный деятель,**
**попечитель,**
**заслуженный работник связи РФ (2014 г.)**

*14.5.1955, с. Симетбаш Арского района ТАССР*

Окончил Камышинское Высшее военное командно-строительное училище (1975 г.), Международную академию менеджмента (1992 г.), Челябинский университет (1999 г.). В 1975–1991 гг. в Вооруженных силах СССР. С 1991 г. в производственном объединении «Татмясопром». С 1998 г. первый заместитель председателя Государственного комитета Республики Татарстан по управлению государственным имуществом, с 2001 г. первый заместитель министра земельных и имущественных отношений Республики Татарстан. С 2006 г. генеральный директор АО «Таттелеком».

Премию получил в 2018 г. в составе творческой группы ПАО «Таттелеком» за участие в реализации значимых проектов в сфере культуры и вклад в возрождение духовности, сохранение национальных ценностей и исторического наследия народов, проживающих в Республике Татарстан.

# ШӘФИГУЛЛИН
*Лотфулла Нурислам улы*

**хакимият-хуҗалык эшлеклесе,**
**химаяче,**
**РФнең атказанган элемтә хезмәткәре (2014)**

*14.5.1955, ТАССРның Арча районы Симетбаш авылы*

Камышин Югары хәрби командирлар-төзелеш училищесын (1975), Халыкара менеджмент академиясен (1992), Чиләбе университетын (1999) тәмамлый. 1975–1991 елларда — СССР Кораллы көчләре сафында. 1991 елдан — «Татмясопром» ҖБдә. 1998 елдан — ТР Дәүләт милке белән идарә итү дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары, 2001 елдан — ТР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары. 2006 елдан — «Таттелеком» АҖ генераль директоры.

Дәүләт бүләге 2018 елда «Таттелеком» ГАҖнең иҗат төркеме составында мәдәният өлкәсендәге әһәмиятле проектларны тормышка ашыруга, ТРда яшәүче халыкларның рухи һәм милли кыйммәтләрен һәм тарихи мирасларын саклауга зур өлеш керткән өчен бирелә.



# ЗАКУАНОВ
*Рустам Газизянович*

**журналист, поэт,
заслуженный работник сельского хозяйства РТ (1998 г.),
заслуженный работник культуры РТ (2016 г.)**

*25.5.1957, с. Учалле Азнакаевского района ТАССР — 2.12.2018, г. Казань*

После окончания Казанского университета (1980 г.) заместитель председателя колхоза «Уразман» (1980–1985 гг.), директор совхоза «Янтарь» (1985 г.), заместитель директора управления рабочего снабжения объединения «Татнефть» (2000–2001 гг.). В 2001–2004 гг. заместитель главы Азнакаевского муниципального района. Депутат Государственного Совета РТ (2004–2009 гг.). С 2009 г. руководитель пресс-службы ПАО «Таттелеком». Автор песен для многих звезд татарской эстрады.
Премию получил в 2018 г. в составе творческой группы ПАО «Таттелеком» за участие в реализации значимых проектов в сфере культуры и вклад в возрождение духовности, сохранение национальных ценностей и исторического наследия народов, проживающих в Республике Татарстан.

# ЗӘКУАНОВ
*Рөстәм Газизҗан улы*

**журналист, шагыйрь,
ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре (1998),
ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2016)**

*25.5.1957, ТАССРның Азнакай районы Учәлле авылы — 2.12.2018, Казан шәһәре*

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1980), «Уразман» колхозы рәисе урынбасары (1980–1985), «Янтарь» совхозы директоры (1985), «Татнефть» берләшмәсенең эшчеләрне тәэмин итү идарәсенең директор урынбасары (2000–2001) булып эшли. 2001–2004 елларда — Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары. ТР Дәүләт Советы депутаты (2004–2009). 2009 елдан — «Таттелеком» ГАҖнең матбугат хезмәте җитәкчесе. Күпләгән җыр сүзләре авторы.
Дәүләт бүләге 2018 елда «Таттелеком» ГАҖ иҗат төркеме составында мәдәният өлкәсендә әһәмиятле проектларны гамәлгә ашырган, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли-рухи кыйммәтләрен һәм тарихи мирасларын саклауга зур өлеш керткән өчен бирелә.



# АЛЬМЕЕВ
## *Надир Усманович*

**график,**
**заслуженный деятель искусств РТ (1998 г.)**

*5.8.1946, г. Казань*

Окончил Казанское художественное училище (1965 г.). С 1971 г. художник в Татарском книжном издательстве. Председатель правления Союза художников РТ (1991–1992 гг.). Работает преимущественно в станковой графике (офорт, акварель), в области книжной и журнальной иллюстрации. Основные произведения: цикл гравюр и офортов «Коррида» (1969; 1980 гг.), цикл «Мимы» (1971 г.), «Воспоминания о беге» (1981–1992 гг.), серия акварелей «Страна Алтай» (1996–1997 гг.). Его произведениям присущи философское осмысление бытия, напряженно-динамичная и экспрессивная манера, цельность и сложность композиции.
Премию получил в 2019 г. за серию графических работ: цикл «Колокола Хиросимы», иллюстрации к сборникам татарских поэтов (Дэрдменд, Г. Тукай, С. Хаким, Р. Кутуй), серию пейзажей «Татарстан, Алтай».

# ӘЛМИЕВ
## *Надир Усман улы*

**график,**
**ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1998)**

*5.8.1946, Казан шәһәре*

Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый (1965). 1971 елдан — Татарстан китап нәшриятында рәссам. ТР Рәссамнар берлегенең идарә рәисе (1991–1992). Башлыча станлы графика (офорт, акварель), китаплар һәм журналлар бизәү өлкәсендә эшли. Төп әсәрләре: «Коррида» гравюралар һәм офортлар циклы (1969; 1980), «Мимнар» (1971), «Йөгереш хатирәләре» (1981–1992) офортлар цикллары, «Алтай иле» акварельләр сериясе (1996–1997). Аның хезмәтләренә яшәешне фәлсәфи кабул итү, киеренке-динамик һәм экспрессив манера, бөтен һәм катлаулы композиция хас.
Дәүләт бүләге 2019 елда график эшләр сериясе — «Хиросима чаңнары» циклы, татар шагыйрьләре (Дәрдеманд, Г. Тукай, С. Хәким, Р. Кутуй) җыентыкларына иллюстрацияләр, «Татарстан, Алтай» пейзажлар сериясе өчен бирелә.

2019



# ГАЛИУЛЛИН
*Талгат Набиевич*

**литературовед, писатель,
доктор филологических наук (1981 г.),
член-корреспондент Академии наук РТ (1998 г.),
заслуженный деятель науки РТ (1993 г.),
РФ (1999 г.), народный писатель РТ (2023 г.)**

*22.7.1938, д. Кичкальня Октябрьского района ТАССР,
ныне Нурлатский район РТ*

Окончил Казанский университет (1961 г.). С 1962 г. в Институте языка, литературы и истории КФАН СССР. В 1965–1986 гг. в Елабужском педагогическом институте (с 1971 г. ректор). С 1986 г. в Казанском педагогическом институте, с 1988 г. в Казанском университете (в 1989–2000 гг. декан факультета татарской филологии, истории и восточных языков). Труды по татарской поэзии советского периода, творчеству Х. Туфана, Х. Такташа, С. Хакима, М. Магдеева, Г. Баширова, Р. Файзуллина и др. Автор повестей «Замана балалары» («Дети своего времени», 1993) и др.
